ЯКОБ ГРИММ ВИЛЬҺЕЛЬМ ГРИММ

КҮҢЕЛЛЕ МУЗЫКАНТЛАР

ЯКОБ ГРИММ ВИЛЬҺЕЛЬМ ГРИММ

КҮҢЕЛЛЕ МУЗЫКАНТЛАР



КАЗАН ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ 1982

ББК 83.3 Нем.
Г77

Төзүче һәм немец теленнән тәрҗемә итүче
КАСЫЙМ ФӘСӘХОВ

ОЛЫ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

Якоб Гримм, Вильһельм Гримм
Г77 Күңелле музыкантлар. Әкиятләр. Казан, Тат. кит. нәшр., 1982.

168 бит.

Бу китапка немец фольклорчылары бертуган Гриммнарның утыздан артык әкияте тупланган. Аларның күбесе татар телендә беренче мәртәбә дөнья күрә.

Г $\frac{70803-273}{М132(03)-82}$ **159—82** **3803040300 ББК 83.3 Нем.**

© татарчага тәрҗемә, Татарстан китап нәшрияты, 1982.

ТӘРҖЕМӘЧЕДӘН

Әкият тыңларга, әкият китабы укырга кем генә яратмый икән! Әкиятләр белән бигрәк тә балалар мавыга, чөнки халык иҗатының бу төре төпченергә яратучан нәниләрнең уй-фикерләрен тагын да тирәнәйтә төшә, гади генә нәрсәдә дә гаҗәеп сихри сыйфатлар, шаккатыргыч тылсымнар күрүчән фантазияләрен тагын да үстереп җибәрә. Әкиятләр, телдән-телгә, буыннан-буынга күчеп, үзләренең гадәти булмаган хикмәтләре һәм тылсымнары белән һәр заманда бик күпләрнең күңелен әсир итә. Шулай гасырдан гасырларга күчә-күчә, кайбер әкиятләр төрле халыкларның иң яраткан рухи азыгына әверелә, аларны әле сөйләшергә өйрәнеп кенә килүче нәниләр дә, инде чәчләре агарган олылар да яратып тыңлый, хәтерләренә сеңдерә, балаларына, оныкларына сөйли.

Һәр халыкның үзенә генә хас милли үзенчәлекле һәм аеруча киң таралган, аеруча яратып сөйләнә һәм тыңлана торган әкиятләре була. Ләкин халык иҗаты милли рамкаларда гына кала алмый, чөнки төрле милләт вәкилләре күмәк эш вакытында яки бергәләп ял итәргә туктаганда, я булмаса күңел ачу өчен махсус җыелганда үзара табышмак әйтешү, мәзәк, әкият сөйләү гадәткә кергән. Шундый ял вакытларының берсендә, әйтик, рус халык әкиятләрен татар кешесе тыңлый да күңеленә аеруча хуш килгәнен соңыннан үз иптәшләренә сөйли. Алары икенче берәүгә ирештерә. Шулай итеп, бер халык әкияте икенче халык теленә күчә, бераз үзгәртелеп, ә кайчакта яңа милли геройлар, милли гореф-гадәтләр, сыйфатлар һәм вакыйгалар өстәлеп, тәмам үз булып китә. Аннары бит әле төрле милләт хезмәт ияләренең, телләре һәм гореф-гадәтләре аерым булуга да карамастан, уртак шатлыклары, уртак кайгы-хәсрәтләре, уртак омтылышлары һәм идеаллары, уртак уй-фикерләре дә була. Менә шуңа күрә дә төрле халыкларның авыз иҗатында бертөсле үк яки охшашлыклары, төп вакыйгалары һәм геройлары, идея юнәлешләре ягыннан бер-беренә бик якын булган әкиятләр барлыкка килә. Тора-бара бу әкиятләрнең кайсы халыкныкы икәнен, бу телгә кайдан килеп кергәнен ачыклау да читен була башлый.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң бездә халык авыз иҗатын өйрәнүгә игътибар бик нык артты, җырларны, ри-

ваятьләрне, табышмакларны, экиятләрне һәм халык авыз иҗатының башка төр әсәрләрен язып алу, тикшерү-өйрәнү һәм бастырып чыгару буенча бик зур эшләр башкарылды. Бу исә халык авыз иҗаты әсәрләренең интернациональләшүен тагын да көчәйтә төште. Телевидение исә бу төр әсәрләрне сүз белән генә түгел, бәлки бай сурәтләү чаралары белән дә, ягъни бөтен тылсымнарын күз алдына китереп бастыру юлы белән дә миллионлаган аудиториягә җиткерә башлады. Нәтиҗәдә, төрле халыкларның яраткан бик күп экиятләре, мәзәкләре экият-фильмнарга һәм мультфильмнарга нигез булды. Андый фильмнар барганда телевизор экранына кереп китәрдәй булып утырмаган бер генә бала да калмыйдыр. Андый фильмнар барганда футбол яисә хоккей матчларын һәвәсләнеп караган эти-әниләр дә телевизор яныннан китеп торырга мәҗбүр. Хәер, мультфильмнар олыларны да сихерли, алар да экият геройлары белән бергә куанышып яисә кайгырышып, дөньяларын онытып утыралар. Менә шуңа күрә дә төрле халыкларның бик күп экиятләре кешелек дөньясының уртак рухи хәзинәсенә әверелә, аларны белмәгән бер генә кеше дә юктыр дисәк, мөгаен, хата булмас. «Кар кызы», «Буран патша», «Күңелле музыкантлар», «Йокыга талган гүзәл», «Кызыл калфак», «Көлгенә», «Тукрансакал», «Тере суы», «Чәнтикәй», «Куян белән керпе», «Ак елан», «Бүре белән төлке» һәм башка экиятләр нәкъ менә шундый хәзинәгә керә дә инде. Аларның барысы буенча да диярлек экият-фильмнар, мультфильмнар эшләнгән. Ул экиятләрнең кайсы халыкныкы булуын әйтүе дә кыен, чөнки күпләр аларны үзенеке саный.

Экият яратучылар бертуган Гриммнарны да яхшы белә. Якоб Гримм (1785—1863) һәм Вильһельм Гримм (1786—1859) — күренекле немец галимнәре — филологлар. Аерым алганда, алар борынгы герман кабиләләренең телен һәм әдәбиятын гыйльми өйрәнүне башлап җибәрәләр, фольклор өлкәсендә мифология мәктәбенә нигез салучылардан булалар, ягъни халык иҗатында һәм әдәбият үсешендә мифологиянең зур роль уйнавын күрсәтәләр, әдәбиятның һәм сәнгатьнең халыкчанлыгы мәсьәләсен күтәреп чыгалар, әдәбиятны, халык иҗатын һәм мифологияне чагыштырып өйрәнү кирәклеген яклыйлар. Бу хакта Якоб Гримм «Немец мифологиясе» дигән махсус фәнни хезмәт тә яза һәм ул 1835 елда аерым китап булып басылып чыга.

Шулай да бертуган Гриммнар халык арасында киң таралган экиятләрне язып алу, эшкәртү һәм бастырып чыгару белән аеруча танылганнар. Гомумән, халык авыз иҗаты белән алар бик иртә кызыксына башлыйлар. Мондый мәзәк тә бар: имеештер, Якоб үзенең беренче экиятен бишектә елап яткан һәм үзеннән нибары бер генә яшькә кече энесе Вильһельмне юатыр өчен сөйләгән.

Якоб белән Вильһельм бертуганнар гына түгел, чын мәгънәсендә бер-беренә турылыклы дуслар, бер юлдан атлаучы фикер-

дәшләр дә булалар: икесе дә халык авыз иҗаты белән гомер буе кызыксыналар. Нәкъ менә шушы иҗади дәрт аларны халыкның бәһасез җәүһәрләрен өйрәнергә, берәмтекләп җыярга һәм киләчәк буыннарга җиткерер өчен армый-талмый эшләргә рухландыра, нәкъ менә шушы хезмәтләре бертуган Гриммнарның исемнәрен мәңгеләштерә дә инде.

Якоб һәм Вильһельм Гриммнарның балаларга багышланган беренче әкиятләр китабы укучыларга әле 1812 елда ук тәкъдим ителә. Шул көннән башлап ул иң яратып укыла торган әсәрләрнең берсенә әверелә. 1857 елда аларның бу өлкәдәге күпьеллык хезмәтләре ике томлы китап булып басылып чыга. Шуннан соң инде немец халкының бу әкиятләре күп милләт укучыларының бик яратып укый торган китабына әверелә, дөньядагы барлык телләргә диярлек тәрҗемә ителә. Бертуган Гриммнар җыйган әкиятләр Андерсен әсәрләре, гарәп халкының «Мең дә бер кичә»се кебек үк киң тарала һәм яратып укыла. Соңгы ярты гасырда гына да Якоб һәм Вильһельм Гриммнарның аерым әкиятләре яки тулы җыелмалары төрле телләрдә мең тапкырдан артык дөнья күрә, алар рус телендә дә басылып чыга. Бу үзе генә дә әлеге әкиятләрнең никадәр танылган булуы, төрле халыклар тарафыннан никадәр яратып укылуы турында бик ачык сөйли.

Тулы басмага ике йөз әкият тупланган. Кайберләренең вариантлары да бар. Шунысы кызыклы, җыелмадагы әкиятләрнең күбесе (аерым алганда, «Йокыга талган гүзәл», «Кызыл калфак», «Көлгенә», «Чәнтикәй», «Буран патша», «Тере суы», «Ак елан», «Бүре белән төлке», «Куян белән керпе», «Кар кызы» һ. б.) рус халык әкиятләрендә дә, бүтән халыклар фольклорында да еш очрый, һәр халык аны үз итеп саный, әкиятнең геройлары да милли була. Аерым алганда, бертуган Гриммнарның «Чәнтикәй», «Бүре белән җиде кәҗә бәтие», «Урман иязләре», «Күңелле музыкантлар», «Һәнзил белән Гәрител», «Крестьян белән шайтан», «Мәче белән тычкан», «Көлгенә», «Алтын кош» кебек әкиятләре татар халкының «Өч карт», «Үги кыз», «Аю белән төлке», «Кәҗә белән бүре», «Аю, бабай, төлке», «Дүрт дус», «Песәй», «Кош эзләп йөргән хан улы» әкиятләренә я тулысынча диярлек тәңгәл килә, яисә аерым сюжетлары, вакыйгалары уртак, яки каһарманнары бер үк. Ләкин бу очракта шунысын да әйтү кирәк, әлеге «әкиятләрдә уртаклык никадәр генә зур булмасын, аларда теге яки бу халыкның үзенә генә хас үзенчәлекләре дә чагылмый калмый. Мондый үзенчәлекләр күбесенчә каһарманнарның холык-фигылендә, сөйләмендә, табигать күренешләрендә, көнкүреш детальләрендә ачык күренә».

Шушы хәлне күздә тотканда, бертуган Гриммнарның әкиятләре безнең өчен аеруча зур әһәмияткә ия, чөнки ул бер-береннән ара белән дә, тел һәм культура ягыннан да шактый ерак булган ике халык иҗатындагы бу уртаклыкларның ничек килеп чыгуын

белү, аны аңлау һәм эзләү теләге уята. Ләкин, кызганычка каршы, татар укучысы Якоб һәм Вильһельм Гриммнарның бөтен дөньяга мәшһүр әкиятләрен әлегә бик аз белә, чөнки моңа кадәр аларның бары берничәсе генә татар теленә тәрҗемә ителгән иде.

Менә шуны истә тотып, без бертуган Гриммнарның халык арасында иң киң таралган һәм күп милләтләрнең авыз иҗатында очрый торган яки бөтенләй «үз» булып киткән әкиятләрен генә сайлап алып, татар укучысына да ирештерергә булдык. Бу китапка кергән әкиятләр иң соңгы тулы басмадан сайлап алынды һәм татарчага турыдан-туры немец теленнән тәрҗемә ителде.

Китапны төзегәндә әкиятләрнең асыл нөсхәдәге тәртибе сакланмады, эчтәлекләре буенча яңадан төркемләштереп урнаштырылды. Аерым әкиятләрне сайлап алып биргәндә, шулай урнаштыру кулайрак булыр, дип уйланылды. Турыдан-туры тәрҗемә итеп булмый торган сүз әйләнмәләре, тотрыклы гыйбарәләр, әйтемнәр һәм мәкальләр мәгънәсе ягыннан тәңгәл булган татар халык әйтемнәре, мәкальләре, сүз әйләнмәләре белән бирелде. Башлыча немец теленә генә хас булган кайбер атамалар да татар телендә еш кулланыла торган мәгънәдәш сүзләр белән алмаштырылды.

Безнең уебызча, бу сайланма әкиятләр татар укучыларын немец халык иҗаты белән киңрәк таныштыруга ярдәм итәр, бертуган Гриммнар иҗаты белән кызыксынуын көчәйтер, уй-хыялларын уятыр, күңелләрен тагын да баетыр.

Рәхим итегез, кадерле укучылар, серле, тылсымлы әкиятләр дөньясы сезне көтә!

Касыйм Фәсәхов

КЫЗЫЛ КАЛФАК

Әүвәл-әүвәл заманда ягымлы гына, сөйкемле генә бер кыз яшәгән, ди. Аны һәркем үз итә, ярата, бигрәк тә әбисе иркәли: җаны ни тели, шуны алып бирә икән, ди.

Шулай берзаман әбисе оныгына кызыл бәрхеттән калфак тегеп биргән. Кызыкай калфакны бик-бик ошаткан, аны бер дә башыннан салмый, гел киеп йөри икән. Шуңа күрә кызны тора-бара «Кызыл калфак» дип йөртә башлаганнар, ди.

Көннәрдән беркөнне әнисе кызын чакырып алган да:

— Кызыл калфагым, шушы бөккән белән чүлмәктәге ширбәтне әбиеңә илтеп кайт әле,— дигән.— Бер дә кәефе юк икән, шуларны авыз иткәч бераз хәл кермәсме үзенә. Көн эсселәткәнче китүең хәерле булыр. Тик кара аны, сак бул, сукмактан читкә чыкма, егылып, әбиеңә дигән ширбәтне түгәрсең. Тегендә-монда сугылып, дөньяңны онытып йөрмә. Әбиеңнән исәнлек-саулык сораш,— дигән.

— Һәммәсе дә син әйткәнчә булыр, әнкәем,— дигән Кызыл калфак һәм саубуллашып чыгып та киткән.

Кызның әбисе карурман уртасындагы аланда яши, аның өенә ярты сәгать эчендә барып җитәргә була икән, ди. Урманга керүе булган, кызның каршысына соры бүре килеп чыккан. Кызыл калфак бүренең ерткыч җанвар икәнлеген белмәгән, шуңа күрә бер дә курыкмаган, ди.

— Хәерле көн, Кызыл калфак,— дигән соры җанвар.

— Яхшы сүзең өчен рәхмәт, бүрекәй.

— Иртә таңнан кая ашыгасың болай, Кызыл калфак?

— Әбием янына.

— Алъяпкычыңа нәрсә яшердең?

— Бөккән белән ширбәт. Әбием авырып киткән, бер дә хәле юк икән. Шуңа күчтәнәч илтә баруым әле, чиренә килешмәсме.

— Кай тирәдәрәк тора соң әбиең?

— Шушы урман юлы белән тагын бераз баргач, өч биек имән янына килеп чыгасың. Әбиемнең өе шул имәннәр уртасында. Мөгаен, үзең дә беләсеңдер әле ул җирне,— дип, кызыкай барысын да сөйләп биргән, ди.

«Бик тәмледер бу япь-яшь кызый,— дип уйлап алган, ди, бүре.— Менә дигән ризык булачак бу миңа, әбисеннән мең тапкыр тәмлерәктер әле. Икесен дә эләктерсәң, тагын да шәбрәк булыр иде дә... Ул чагында берәр хәйләсез эш барып чыкмас шул». Шулай уйлана-уйлана, кыз белән бераз янәшә барган да:

— Кызыл калфак,— дигән бүре,— тирә-ягыңдагы аллы-гөлле чәчәкләрне күрәсеңме син? Урман ямена карамыйсың да. Күңелләрне җилкендереп сайраган кошларга да колак салмыйсың, ахры? Бу хозур дөньяны бар дип тә белмисең, мәктәпкә барасың юк ич. Шушы сихри урман кочагында ял итеп алуга ни җитә?!

Бүренең шушы сүзләреннән соң як-ягына күз салса, Кызыл калфак чынлап та хәйран калган, ди. Биек-биек агачларның куе ботаклары арасыннан төшкән кояш нурлары җем-җем килеп күзне чагылдыра, аллы-гөлле чәчәкләр бөтен тирә-юньгә хуш ис тарата, ди. «Әбиемә шушы чәчәкләрне дә җыеп барсам, бигрәк тә сөенер иде. И-и, бик иртә ич әле, өлгерермен», дип уйлаган да Кызыл калфак чәчәк җыярга тотынган. Иң әйбәтен өзеп алдым дигәч кенә тагын да матуррагына күзе төшкән, аннары икенчесенә, өченчесенә... Ул сукмактан читкә чыкканын да, инде шактый узганын да

сизмәгән. Ул арада бүре туп-туры карурман уртасындагы йортка чапкан. Барып җиткән дә ишек шакый, ди, бу.

— Кем бар анда? — дип сорый икән әби.

— Оныгың Кызыл калфак. Әби, мин сиңа тәмле бөккән, татлы ширбәт алып килдем, ишегеңне тизрәк ач,— дигән бүре.

— Келәсенә бассаң, үзе ачылыр,— дигән әби.— Бер дә хәлем юк шул, кызым, кузгала да алмыйм...

Бүре ашыгып келәгә баскан икән, ишек ачылып та киткән. Шуннан соң ерткыч шыпырт кына карават янына килгән, күз ачып йомганчы әбине капкан да йоткан, ди. Үзе аның күлмәкләрен, башлыгын алып кигән. Аннары, чаршауны корып, әбинең караватына менеп яткан, ди.

Кызыл калфак исә әле һаман йөгерә-йөгерә урманда чәчәк җыя икән. Инде җыйган чәчәкләре кочагына да сыймый башлаган, күтәреп кайтырлык та түгел, ди. Менә шунда гына ул авыру әбисен исенә төшергән һәм, сукмакны эзләп табып, юлын дәвам иттергән. Әбисе өенә килеп җитсә, шаккаткан кызыкай: ишеге шар ачык, ди, өй эче дә ничектер сәер тоелган. «Йа, хода,— дигән кызыкай эченнән генә,— нишләптер бик шомлы әле бүген монда, башка чакларда бик күңелле була торган иде».

Шулай да Кызыл калфак:

— Хәерле иртә,— дип кычкырып исәнләшкән, ләкин җавап бирүче булмаган. Кызыкай карават янына килгән. Чаршауны ачып җибәрсә, әбисе түшәктә ята икән. Тик нигә соң әле ул башлыгын битенә кадәр үк төшереп кигән? Үзе дә әллә ничек сәер күренә!

— Әбекәй,— дигән Кызыл калфак,— колакларың нигә шулай зурайган?

— Сине әйбәтрәк ишетер өчен, кызым.

— Әбекәем, күзләрең нигә шундый зур синең?

— Сине әйбәтрәк күрер өчен, кызым.

— Әбекәй, кулларың нигә шундый озын?

— Сине әйбәтләп иләктерер өчен, кызым.

— Әбекәй, әбекәй, ә нигә авызың шундый чамасыз зур?

— Сине тизрәк кабып йотар өчен, кызым.

Шулай дип әйтүгә, бүре караваттан сикереп төшкән дә мескен Кызыл калфакны капкан да йоткан. Шулай карынын бераз тутыргач, комсыз җанвар тагын караватка менеп яткан һәм тирән йокыга талган, ди.

Бүренең иләмсез гырылдавы урман эчендә әллә кайларда ишетелеп тора икән. Әби йорты яныннан узып

барган бер аучы: «Бу карчык нигә бик каты гырлый соң әле? Ул-бу булмагандыр бит?» дип уйлап өйгә керсә, үз күзләренә үзе ышанмый торган, ди: әби караватында бүре йоклап ята имеш.

— Ә-һә-ә, эләктеңме, явыз җан,— дигән аучы,— бик күптәннән эзли идем инде мин сине!

Аучы, атмакчы булып, мылтыгын бүрегә төзәгән икән дә, шунда ук бу уеннан кире кайткан. «Бу ерткычның әбине кабып йоткан булуы да мөмкин ич. Әби әле үлмәгән булса? Коткарып булачак бит аны», дип уйлаган һәм мылтыгын сөяп куйган да, кайчы алып, йоклап яткан җанварның корсагын яра башлаган. Кисеп җибәрүе булган, бүре карынында елкылдап торган кызыл калфак күренгән. Тагын бераз кискән икән, җанвар корсагыннан нәфис кенә бер кызыкай килеп чыккан. Килеп чыгуы булган, кычкырып та җибәргән:

— Ай-һай караңгы икән бүре корсагында, өннәрем алынды!

Шуннан соң аучы бүренең корсагын буеннан-буена ярган да ерткыч карыныннан әбине тартып чыгарган. Чак-чак кына җан бирмәгән, ди, мескен карчык, көч-хәл белән генә сулый, ди.

Кызыл калфак исә тиз генә урманнан ташлар җыеп кергән дә ерткыч җанвар корсагына тутырган. Уянгач, эшнең хәтәр якка борылганын сизеп, бүре тиз генә чыгып ычкынырга уйлаган, тик эченә тутырылган ташлар бик авыр булганлыктан, караваттан егылып төшкән дә шундук җан биргән, ди.

Әбекәй дә, Кызыл калфак белән аучы да бик сөенгәннәр: аучы соры бүренең тиресен тунап алган да өенә кайтып киткән. Әбекәй, Кызыл калфак алып килгән күчтәнәчләр белән сыйлангач, тәмам аягына баскан, ди. Ә Кызыл калфак: «Моннан соң урманда әнием кушканча гына йөрермен»,— дип, үз-үзенә сүз биргән, ди.

Болай дип тә сөйлиләр әле: бу хәлләрдән соң күпмедер вакыт үткәч, Кызыл калфак тагын әбисенә әнисе пешергән сый-нигъмәтне илтә киткән, ди. Юлда аңа янә соры бүре очрап, кызыкайны юмалап, сукмагыннан яздырырга тырышып караган, ди. Тик бу юлы Кызыл калфак үзен адаштырырга, алдарга ирек бирмәгән, тегендә-монда сугылмыйча, юк-бар белән мавыкмыйча, гел алга атлаган. Аннары әбисенә: «Килгәндә нәкъ теге вакыттагы кебек соры бүрегә тап булдым,— дип сөйләгән.— Миңа шундый комсызланып карады, әгәр дә сукмагымнан читкә чыккан булсам, һичшиксез, кабып йотачак иде»,— дигән.

— Алайса ишекне бикләп куйыйк әле,— дигән әбисе.— Бүре монда килә калса, керә алмасын.

Теге бүре чынлап та бераздан килеп җиткән, ишек шакып:

— Әбекәй, ач ишегеңне, мин әле бу — оныгың Кызыл калфак, сиңа тәмле-тәмле күчтәнәчләр китердем,— дигән.

Әбисе дә, Кызыл калфак та ләм-мим эндәшмәгәннәр, ишекне дә ачмаганнар. Соры ерткыч кача-поса йорт тирәли әллә ничә мәртәбә әйләнеп чыкканнан соң, бер уйга килеп, өй түбәсенә менеп яшеренгән, ди. Кызыл калфакның кичен өенә кайтачагын чамалаган да, кайтыр юлында яшертен генә артыннан барып, берәр караңгы җирдә тотып ашарга ниятләгән инде ул. Тик әбекәй бүренең яңа хәйләсен бик тиз сизеп алган, ди. Өй алдында бик зур бер таш кисмәк тора икән. Оныгына шуны күрсәтеп:

— Кызыл калфак, чатлыктагы чиләкне күрәсеңме? — дигән.— Кичә тутырма пешергәч, шулпасын шунда салып куйган идем. Шуны кисмәккә чыгарып түгәрсең әле.

Кызыл калфак башта кисмәккә күп итеп су ташыган, аннары шул суга тутырма пешергән шулпаны чыгарып салган. Тутырма исен сизеп алган бүре түзмәгән, иснәнә-иснәнә аска иелгән. Муенын суза торгач, утырган җиреннән ычкынып та киткән, ди. Берәр нәрсәгә тотынып калырга маташса да, өлгерә алмаган, өй түбәсеннән туп-туры сулы кисмәккә мәтәлеп төшкән! Килеп тә төшкән, шунда тончыгып та үлгән, ди. Ә Кызыл калфак, исән-имин калуына куана-куана, өенә кайтып киткән. Хәзер инде урманда аңа яманлык кылырдай бүреләр дә калмаган, ди.

КӨЛГЕНӘ

Бер байның хатыны авырып киткән, ди. Әҗәле җиткәнне сизеп, караваты янына бердәнбер кызын чакырып китергән дә:

— Сөекле балакаем! — дигән.— Эшчән, игелекле бул, язмыш сиңа шунда гына мәрхәмәт күрсәтер. Мин үзем сиңа бәхиллегемне биреп, матур теләкләремне теләп китәм.

Шулай дигән дә күзләрен мәңгегә йомган, ди, хатын. Кыз моңланып зиратка көн саен килә дә елый, килә дә елый икән, әнисенең васыятен дә онытмаган

үзе. Көн арты көн узган, кыш бабай җиргә ап-ак юрганын япкан. Аннары кояш карый башлаган. Дөньяга яшеллек иңгәч, кызның әтисе яңадан өйләнгән. Яшь хатынга ияреп, аның ике кызы да бай өенә аяк баскан. Төскә-биткә чибәр генә күренсәләр дә, тар күңелле, көнчел һәм явызлар икән, шуңа күрә яңа туганнарын бик тиз җәберли башлаганнар.

— Бу дивана нишләп безнең белән бергә утыра соң әле? — дип тавыш куптарганнар.— Үз тамагын үзе карасын! Үз көнен үзе күрсен!

Шулай дип, явызлар ятимәнең элекке матур киемнәрен салдырып алганнар, алар урынына җыен искемоскыны биргәннәр. Әле җитмәсә, мондый көяз кыз, дөнья гүзәле җир йөзендә дә юктыр, дип авыз ерганнар, аннары көлә-көлә, эткәли-төрткәли ятимәне аш бүлмәсенә куып чыгарганнар. Моннан соң инде ул гел шунда гына кайнашырга — иртәдән кичкә кадәр бөтен авыр эшләрне берүзе эшләргә мәҗбүр булган. Таңнан торып су ташу, мичкә ягу, ашарга пешерү, кер уу моннан соң инде гел аның җилкәсенә төшкән. Шуның өстенә үги туганнары кулларыннан килгән этлекне эшләп кенә торганнар: аны мыскыл итеп көлгәннәр, чистарткан борчак-ясмыкларын көлгә сибеп бутаганнар. Ятимә ярманы көл эченнән тагын чүпләп алырга тиеш булган. Көнозын эшләп хәлдән тайгач, кичен җир идәнгә — мич алдындагы көлгә генә тәгәрәп йоклый икән бичара. Һәрвакыт көлдә аунап, керләнеп, буялып беткәнлектән, аңа берзаман «Көлгенә» кушаматын да ябыштырганнар!

Шулай бервакыт ярминкәгә барырга җыенганда, әтиләре үги кызларыннан:

— Сезгә нәрсә алып кайтыйм? — дип сораган.

— Матур күлмәкләр,— дигән беренчесе.

— Энҗе-мәрҗән, асылташлар,— дигән икенчесе.

— Ә сиңа, Көлгенә? Син нәрсәгә кызыгасың? — дигән әтисе.

— Әткәем,— дигән Көлгенә,— ярминкәдән кайтканда эшләпәң тиеп киткән беренче ботакны сындырып алсаң, шул да ярар миңа.

Бай абзый ярминкәдә үги кызларына матур-матур күлмәкләр, кыйммәтле энҗе-мәрҗәннәр, асылташлар сатып алган. Кайтырга чыккач, куаклар арасыннан узганда, чикләвек ботагы эшләпәсен җиргә сыдырып төшергән. Ах, менә нәрсә сораган икән, дигән ул, кызының үтенечен хәтерләп. Өйгә кайткач, үги балаларына затлы бүләкләрен өләшкән, ә Көлгенәгә исә чикләвек куагыннан сындырып алган әлеге ботакны тоттырган. Көлгенә,

этисенә рәхмәт әйтеп, ботакны әнисе кабере өстенә илтеп утырткан да үксеп-үксеп елый башлаган. Аның күз яшьләре җиргә агып төшеп яңа үсентегә шифалы дым биргән. Шуннан соң ботак бик тиз тамыр җибәреп, матур гына булып үсеп тә киткән. Көлгенә, көненә өчәр тапкыр зиратка килеп, шул куакны карый икән. Ул арада әлеге чикләвек куагына ап-ак бер кош ияләшкән. Көлгенәнең һәр теләген үтәргә әзер икәнлеген дә белдергән бу.

Көннәрнең берендә шушы илнең короле зур бер мәҗлес җыярга боерган, ди. Өч көн дәвам итәчәк тантанага илнең бөтен чибәр, сылу кызлары чакырылган. Буй җиткән улы үзенә ошаган берәр кәләш сайлап алсын дип тырышкан, ди, король. Мәҗлес хәбәре үги ана кызларын да аякка бастырган. Алар берсеннән-берсе уздырып бизәнергә тотынганнар. Көлгенәне чакырып китергәннәр дә:

— Чәчләребезне тара! Туфлиләребезне чистарт та каптырмаларын әйбәтләп каптыр. Король сараена кәләш күзләү мәҗлесенә барабыз, кара аны! — ди-ди, тәмам аптыратып бетергәннәр.

Көлгенә аларны киендерә-ясандыра арып беткән. Үзен чакырмауларына күңеле тулып елап та алган. Аннары үги анасына:

— Минем дә биисем килә, алып барыгызсана! — дип ялварган, ди.

— Син нәрсә, Көлгенә,— дигән үги анасы,— көлгә тузанга баткан шушы кыяфәтең белән сарайга бармакчы буласыңмы? Матур күлмәгең дә, туфлиләрең дә юк бит, анда ничек биемәк кирәк?!

Кыз һаман ялваруыннан туктамагач, үги анасы:

— Менә көлгә бер коштабак ясмык аралаштырам, шуны ике сәгатьтә чүпләп бетерсәң, карап карарбыз,— дигән.

Кызыкай арткы ишектән бакчага чыккан да:

— Әй, сез, ак күгәрченнәр, әй, сез, күк күгәрченнәр, әй, сез, һавадагы кошкайлар! — дип эндәшкән.— Монда килегез, ясмык чүпләргә ярдәм итегез... Яхшыларын — табакка, начарларын — тамакка!

Шулай дию булган, бүлмә тәрәзәсеннән ике ак күгәрчен очып кергән, аннары күк күгәрченнәр дә килеп җиткән, тиздән һавадагы барлык кошлар бөтерелеп оча-оча көлгә төшеп кунганнар. Кунулары булган, күгәрченнәр тук-тук тукылдатырга да керешкән, бүтән кошлар да алардан калышмаган — әйбәтрәк, туграк бөртекләрне табакка чүпли башлаганнар. Бер сәгать үтәр-үтмәс

эш тә беткән. Кыз, ясмык тулы табакны сөенә-сөенә анасына китереп биргәч, хәзер инде кәләш күзләү мәҗлесенә алып барырлар дип өметләнгән. Тик үги анасы:

— Рәтле күлмәгең дә юк, Көлгенә, бии дә белмисең, көлкегә генә калырсың, йөрмә әле,— дип кырт кискән.

Кызыкай бик кимсенгән, бик хурланган. Аннары тагын елый, ялвара башлаган. Шуннан соң үги анасы:

— Әгәр дә көлгә сибелгән тагын ике табак ясмыкны бер сәгатьтә чүпләп өлгерсәң, барырсың,— дигән.

Бу эшне бер сәгатьтә түгел, көне буена да бетерә алмас дип уйлаган инде ул. Шулай уйлаган да ясмыкны көлгә сибеп аралаштырган.

Кызыкай бу юлы да арткы ишектән бакчага чыгып дусларын ярдәмгә чакырган:

— Әй, сез, ак күгәрченнәр, әй, сез, күк күгәрченнәр, әй, сез, һавадагы кошкайлар! Килегез монда, килегез, ясмык чүпләргә ярдәм итегез: яхшыларын — табакка, начарларын — тамакка!

Шулай дию булган, бүлмә тәрәзәсеннән ике ак күгәрчен очып кергән, аннары күк күгәрченнәр дә килеп җиткән, тиздән һавадагы барлык кошлар бөтерелеп оча-оча көлгә төшеп кунганнар. Кунулары булган, күгәрченнәр тук-тук эшкә дә керешкән, бүтән кошлар да алардан калышмаган, тук бөртекләрне табакка чүпли башлаганнар. Ярты сәгать үтәр-үтмәс эш тә беткән.

Кыз ясмык тулы коштабакларны сөенә-сөенә анасына китереп биргән, хәзер инде кәләш күзләү мәҗлесенә мин дә бара алырмын дип өметләнгән. Тик үги анасы бу юлы да аны сөендермәгән.

— Мәҗлес турында уйлама да. Ни рәтле күлмәгең юк, ни бии белмисең, безне хур итеп йөрмә әле,— дигән дә, тәкәббер кызларын ияртеп, король сараена китеп барган.

Өйдә ялгызы гына калгач, Көлгенә әнисе каберенә утырткан чикләвек куагы янына килгән дә:

— Куаккай, ботакларың селке әле:
Өстемә алтын-көмеш сирпе әле! —

дип эндәшкән.

Шулай дип әйтүе булган, куакка килеп кунган тылсымлы кош аңа алтын-көмеш белән бизәлгән күлмәк, ука белән чигелгән туфли китереп биргән. Көлгенә шул затлы киемнәрне кигән дә кәләш күзләү мәҗлесенә юнәлгән. Аны туганнары да, үги анасы да танымаганнар, берәр чит мәмләкәт короленең кызыдыр бу, дип уйлаганнар. Күз явын алырдай алтын-көмеш белән бизәл-

гән матур киемле бу чибәркәй көлдән ясмык чүпләп утырган күрексез кызга бөтенләй охшамаган! Король улы, Көлгенәне күреп алгач, бүтән беркем белән дә биергә теләмәгән, кызны җитәкләп мәйдан уртасына чыккан да бергә күңел ача башлаган. Берәрсе Көлгенәне биергә чакырырга теләсә: «Ул тагын минем белән бии»,— ди икән. Көлгенә менә шулай кичкә хәтле бары король улы белән генә биегән. Караңгы төшкәч, өйгә кайтырга җыенган. Чибәркәйнең кем кызы икәнен беләсе килгән король улы:

— Мин сине үзем озатып куярмын,— дигән.

Тик кыз, аңардан качып котылыр өчен, тиз генә күгәрченнәр кетәгенә сикергән.

Әтисе килеп җиткәч, король улы, аңа гүзәл кызның күгәрченнәр кетәгенә сикереп менеп, күздән югалуын әйткән. Атасы: «Көлгенә түгелме икән ул?» дип уйлаган. Аннары балта белән багор алып, күгәрчен кетәген җимереп ташлаган. Тик анда бер генә җан иясе дә күренмәгән.

Көлгенә күгәрчен кетәгенең арткы ягыннан тиз генә сикереп төшкән дә зираттагы чикләвек куагы янына йөгергән. Анда тиз генә матур киемнәрен салып куйган. Тылсымлы кош аларны ничек барлыкка китерсә, шулай юкка да чыгарган. Кызыкай исә, иске киемнәрен киеп, мәҗлестәгеләр кайтып җиткәнче учак янына тәгәрәргә дә өлгергән.

Үги аналары өйгә кайтып кергәндә, Көлгенә инде шалама күлмәген кигән килеш көл өстендә йоклап ята икән. Мич каршында майлы лампа пыскып утыра, ди.

Мәҗлес икенче көнне дә дәвам иткән. Әти-әнисе белән туганнары шунда киткәч, Көлгенә янә чикләвек куагы янына барып:

— Куаккай, ботакларың селке әле:
Өстемә алтын-көмеш сирпе әле! —

дип такмаклаган.

Тылсымлы кош кичәгегә караганда да матуррак, купшырак киемнәр барлыкка китергән. Шуларны киеп мәҗлескә килгәч, барысы да Көлгенәнең гүзәллегенә таң калганнар. Король улы аның күренүен зарыгып көтеп торган икән, шунда ук каршысына йөгереп килгән. Егетләрнең берәрсе Көлгенәне чакырырга теләсә: «Ул минем белән генә бии»,— ди икән. Кич җиткәч,

Көлгенә китәргә җыенган. Король улы аны бу юлы да озата чыккан, кызның кайсы йортка кайтуын беләсе килгән. Тик Көлгенә, аңардан кинәт кенә аерылып, сарай тирәсендәге бакчада күздән югалган. Сусыл җимешләре асылынып торган бик биек, бик юан груша агачына тиен җитезлеге белән үрмәләп менеп киткән. Король малае аның кая качканын тагын күрми калган. Әтисе килеп җиткәч: «Гүзәл кыз бүген дә качты бит, груша агачына менеп яшеренде бугай»,— дигән. Әтисе: «Мөгаен, Көлгенәдер бу», дип уйлап алган. Балта китерткән дә груша агачын кисеп аударган, әмма анда беркем дә юк икән.

Ә Көлгенә инде әллә кайчан груша агачыннан сикереп төшеп, зиратка барып җитәргә, матур киемнәрен чикләвек куагындагы тылсымлы кошка кайтарып бирергә, үз иске-москысын киеп, учаклары алдына тәгәрәргә дә өлгергән була. Үги аналары кайтканда Көлгенә инде, гадәттәгечә, көлгә чумып изелеп йоклап ята, ди.

Өченче көнне дә әти-әниләре белән туганнары король сараена киткәч, Көлгенә зиратка юнәлгән. Монда ул чикләвек куагына тагын:

— Куаккай, ботакларың селке әле:
Өстемә алтын-көмеш сирпе әле! —

дип такмаклаган.

Тылсымлы кош бу юлы кызга җем-җем килеп елкылдап торган искиткеч матур киемнәр биргән. Мондый асыл күлмәк, саф алтыннан коелган туфлиләр моңа кадәр берәүдә дә булмаган, ди. Шул киемнәрне киеп мәҗлескә килгәч, сарай халкы тәмам өнсез калган, ә король улы Көлгенәдән бер генә минутка да аерылырга теләмәгән, ди. Кем дә булса кызны биергә чакырса: «Ул минем белән генә бии»,— дип, арага керә икән, ди.

Караңгы төшкәч, Көлгенә янә китәргә җыенган. Король малае озата барырга теләгән. Әмма кыз бу юлы да бик оста аерылган — егет тагын берни эшләргә өлгерә алмый калган. Тик бу юлы король улы алдан ук хәйлә корган — бөтен баскычларга ябышкак сумала сылатып куйган икән. Баскычтан йөгереп төшкәндә кызның сул аягындагы туфлие сумалага ябышкан да калган. Кеп-кечкенә, ди, туфли, искиткеч матур, ди, саф алтыннан, ди.

Иртәгесен таң атуга король улы Көлгенәләргә килеп кергән дә:

— Шушы алтын туфли кем аягына таман килсә, шул кыз минем кәләшем булачак, бүтән берәүгә дә өйләнмәячәкмен,— дигән.

Үги ананың кызлары моңа бик сөенгәннәр. Аяклары коеп куйган кебек матур икән аларның. Туфлине башта кызларның олысы киеп караган. Тик ничек кенә тырышса да, ярамый, бармаклары сыймый, ди. Моны күреп торган әнисе кызына пычак сузган да:

— Кис тә ташла сыймаган бармакларыңны, король хатыны булгач, барыбер җәяү йөрмәячәксең,— дигән.

Кисеп ташлаган кыз бармакларын, ничек кирәк алай кигән туфлине. Король улы, кәләшем булырсың дип, авыртудан иреннәрен тешләгән кызны атына утырткан да китеп барган. Юл зират яныннан үтә икән. Әлеге чикләвек куагына кунган пар күгәрчен:

Гөр-гөр-гөр, бел-бел-бел:
Чын кәләш бит бу түгел.
Туфли аңа кечкенә,
Каны тулган эченә,—

дип гөлдерәшәләр, ди.

Король улы иелеп караса, кәләшенең туфлиеннән чынлап та кан саркып тора икән. Егет шунда ук атын кире борган, ялганчы кызны өенә китергән дә:

— Минем кәләшем түгел бу. Туфлине сеңелесе киеп карасын әле,— дигән.

Икенче кыз туфлине алган да шулай ук бүлмәгә кергән. Бармаклары сыйган сыюын, тик үкчәсе зуррак булып чыккан. Моны күреп торган әнисе кызына пычак сузган да:

— Үкчәңнең сыймаган җирен кис тә ташла, король хатыны булгач, барыбер җәяү йөрмәячәксең ич,— дип әйткән, ди.

Кисеп ташлаган кыз үкчәсенең сыймаган җирен, ничек кирәк алай кигән туфлине. Король улы, кәләшем булырсың дип, авыртудан иреннәрен тешләгән кызны атына утырткан да китеп барган. Зират яныннан узганда теге чикләвек куагына кунган пар күгәрчен:

Гөр-гөр-гөр, бел-бел-бел:
Чын кәләш бит бу түгел.
Туфли аңа кечкенә,
Каны тулган эченә,—

дип гөлдерәшә, ди.

Король малае иелеп караса, кәләшенең туфлиеннән чынлап та кан саркып тора икән, кызның ап-ак оегы да кып-кызыл булган, ди. Егет шунда ук атын кире борган, алдакчы кызны өенә китергән дә:

— Монысы да минем кәләшем түгел. Тагын берәр кызыгыз бармы? — дигән.

2 У-432

БИБЛИОТЕКА
ТАТКНИГОИЗДАТА
Инв. № 3130

— Мәрхүмә хатынымнан туган Көлгенәдән башка кызым юк,— дигән эти кеше.— Тик ул кечкенә әле, бернәрсә дә аңламый. Кая инде аңа король улына кияүгә чыгу!

Король малае шулай да кызны чакырырга кушкан. Үги ана:

— Үзе шапшак, үзе күрексез, кирәкмәс лә,— дип каршы төшкән.

Ләкин егет кызны барыбер күрергә теләгән, үги ана, шулай итеп, Көлгенәне чакырып чыгарырга мәҗбүр булган. Ятимә битен-кулын әйбәтләп юган да король улына килеп баш игән. Егет аңа алтын туфлине сузган. Көлгенә эскәмиягә утырып авыр агач башмакларын салып ташлаган да алтын туфлине кигән, ул аңа үлчәп тегелгәндәй таман гына булган, ди. Кыз күтәрелеп карагач, король улы аны шундук танып алган, Көлгенәнең үзе белән биегән гүзәл кыз икәнлеген күреп, сөенеченнән:

— Менә бу чыннан да минем кәләшем! — дип кычкырып җибәргән.

Үги ананың да, кызларының да моңа бик каты ачуы чыккан, төсләре үк үзгәргән. Тик король улы аларга игътибар итмәгән, Көлгенәне атына утырткан да үз юлына киткән. Зират яныннан узганда теге чикләвек куагына кунган пар күгәрчен бу юлы:

Гөр-гөр-гөр, күр-күр-күр,
Чын кәләш ич бу, шөкер.
Туфлие чак үзенә,
Килешеп тора йөзенә! —

дип гөлдерәшә икән, ди.

Күгәрченнәр шулай гөлдерәшә-гөлдерәшә очып килгән дә берсе Көлгенәнең уң иңбашына, икенчесе сул иңбашына кунган, ди.

Король улы белән Көлгенәнең туена кызларын ияртеп үги ана да килгән. Алар, ялагайланып, Көлгенәне юмаларга, аннан файда күреп калырга теләгәннәр. Кияү белән кәләш никах укытырга барганда, кыз туганнарның олысы Көлгенәнең уң ягына, кечесе сул ягына утырган, ди. Көлгенә иңбашына кунган күгәрченнәр исә юлда аларның берәр күзен чукып алган. Кайтканда кызларның олысы Көлгенәнең сул ягына, кечесе уң ягына утырган, ди. Күгәрченнәр бу юлы инде аларның соңгы күзләрен дә чукып алган. Шулай итеп, явызлыклары, алдашулары өчен яман кызлар тиешле җәзаларын алганнар, гомерлеккә сукыр калганнар, ди.

БУРАН ПАТША

Бер тол хатынның ике кызы булган, ди. Аларның берсе бик матур, бик тырыш, икенчесе үзе килбәтсез, үзе ялкау икән. Тик хатын, үзенеке булганга, кызларының әнә шул килбәтсезен, ялкавын күбрәк яраткан. Ә икенчесе үги кыз икән, өйдәге бөтен эшне бер үзе эшләсә дә, гел кимлек-хурлык күреп яшәгән, ди. Мескен кыз олы урамдагы кое янына чыгып утыра да бармаклары суелып, канап беткәнче көне буе җеп эрли икән.

Шулай беркөнне орчыгы тәмам канга буялып беткәч, үги кыз аны юып алмакчы булып коега иелгән. Авырткан башка тимер тарак дигәндәй, орчыгы кинәт кенә кулыннан ычкынып коега төшеп киткән. Кыз елый-елый үги анасы янына йөгереп кергән, үзенең нинди бәлагә таруын сөйләп биргән. Әй эрләгән, әй кызның йөрәк итен талаган, ди анасы!

— Төшерә белгәнсең икән, аны алып чыгу әмәлен дә тап инде,— дигән ул, җенләнеп.

Кыз ирексездән кире кое янына чыккан, беравык нишләргә дә белми аптырап торган. Аннары, үги анасының канга тоз салуыннан ярсып, алып чыгыймсана шул орчыкны дип, токкан да коега сикергән, ди. Сикерүе булган, һушыннан да язган. Бераздан аңына килеп, күзен ачса, бик матур бер болында ята икән. Күктә нурлы кояш елмая, ә тирә-ягында күз явын алырлык аллыгөлле чәчәк диңгезе, ди. Үги кыз сикереп торган да хәтфә болын буйлап киткән. Бара-бара бер мичкә тап булган, аның эче тулы калач икән. Калачларның берсе телгә килеп:

— Апакай, мин күптән пешеп җиттем инде, алсана мичтән мине, алсана, көйдереп әрәм итмәсәнә! — дип ялына башлаган, ди.

Үги кыз, үтенечкә колак салып, калачларның барысын да мичтән алган. Аннары юлын дәвам иттергән. Бара торгач, ялгыз бер алмагачка юлыккан. Кып-кызыл булып пешкән алмаларын көчкә күтәреп тора икән агач. Бусы да, телгә килеп:

— Апакай, алмаларым тәмам өлгерде, койсана шуларны, койсана! — дип ялына башлаган, ди.

Үги кыз аның да сүзен тыңлаган — алмалар шыбыр-шыбыр җиргә коелып беткәнче куакны селкетеп торган. Аннары җимешләрне бер урынга өеп куйган да үз юлына киткән. Бара торгач, кечкенә генә бер өй янына килеп чыккан. Өйнең тәрәзәсеннән көрәк-көрәк тешле бер

ямьсез карчык карап тора икән. Үги кыз шомлана, әллә кире йөгерим микән, дип икеләнә калган, ди. Шулвакыт карчык:

— Нигә өректең, балакаем? — дип эндәшкән, ди.— Курыкма, кал минем янда, кызым булырсың. Эшкә уңган булсаң, өйне җыйнак тотсаң, рәхәт күреп кенә яшәрсең. Эш белән дә әллә ни йончытмам: көн саен пөхтә итеп урынымны җыйсаң, мамык-йоннары очарлык итеп әйбәтләп ястыгымны каксаң, бүтән берни дә кирәкми. Ул чагында җиргә мамык карлар явар — Буран патша бит мин.

Карчык шулай ягымлы сөйләшкәч, үги кыз тынычланган, Буран патшаны тыңлап, тиздән эшкә дә керешкән, аның һәр йомышын җиренә җиткереп үтәгән. Ул ястык-мендәрләрне какканда, җиргә ишелеп-ишелеп мамык карлар яуган. Үги кыз Буран патша өендә бик рәхәт яшәгән, бер генә сукрану сүзе дә ишетмәгән, тәмле-тәмле ашлар белән җаны теләгәнчә сыйланган, ди.

Байтак гомер иткән ди ул шулай Буран патша янында. Әмма, никадәр генә рәхәттә яшәсә дә, тора-бара йөрәген сагыш телә башлаган. Нилектән шулай булуын башта үзе дә аңламаган, тик соңрак кына үз нигезен сагынудан шулай ямансулавын төшенгән. Буран патша өендә ничек кенә рәхәт булмасын, барыбер үз нигезеңне сагынасың икән шул! Көннәрдән бер көнне үги кыз Буран патшага:

— Өемә кайтасым килә, туганнарымны бик сагындым,— дигән.— Монда миңа бик рәхәт, тик шулай да түзәрлегем калмады. Җир өстенә чыгасым, үзебезнекеләр белән күрешәсем килә!

— Кайтасың киләмени, кызым? — дигән Буран патша.— Ярар, бик әйбәт, бер сүзем дә юк. Тырыш, тыңлаучан, уңган бала икәнсең, шуңа күрә үзем үк кайтарып та куярмын.

Шуннан соң карчык үги кызны бер капка янына җитәкләп алып килгән, ди. Капка үзеннән-үзе ачылып киткән. Капка турысына җиткәндә генә, күктән алтын яңгыры ява башлаган. Алтын тәңкәләрнең яуган бере үги кызга ябыша бара икән. Бераздан ул саф алтын белән капланган, ди. Буран патша коега төшкән орчыкны кайтарып биргәндә:

— Монысы тырышлыгың, уңганлыгың өчен бүләгем! — дигән.

Капка ябылуга, үги кыз җир өстенә, үз өйләре янына килеп чыккан, ди. Шулвакыт кое бурасына менеп кунаклаган этәч:

— Ки-ке-ри-күк, ки-ке-ри-күк,
Безнең апай алтын күк! —

дип кычкырып җибәргән, ди.

Кыз өйгә, үги әнисе янына йөгереп кергән. Бөтен җире саф алтын белән капланган булгач, аны ягымлы кыланып каршылаганнар. Кызыкай башыннан кичкәннәрнең барысын да түкми-чәчми туганнарына сөйләп биргән. Үги ана бик тә көнләшкән. Үзенең килбәтсез, ялкау кызын да шулай баетып кайтармакчы булган һәм аңа, кое янына чыгып утырып, җеп эрләргә кушкан.

Ялкау кыз, орчыгы тизрәк канга буялсын өчен, кулын чәнечкеле куаклар арасына тыгып, бармакларын канаткан, ди. Шуннан соң орчыгын коега төшереп җибәргән, артыннан үзе дә сикергән. Үги сеңелесе кебек, ул да шул ук матур болынга килеп чыккан, шул ук сукмак буйлап киткән. Юл буендагы мич янына килеп җиткәч, калачларның берсе телгә килгән:

— Апакай, мин күптән пешеп җиттем инде, алсана мичтән мине, алсана, көйдереп әрәм итмәсәнә! — дип ялынган, ди.

Тик ялкау кыз үтенечкә колак салмаган.

— Шул гына җитмәгән иде, сезнең аркада өс-башымны пычратыр хәлем юк әле! — дигән дә китеп тә барган. Бара-бара бер алмагач янына килеп чыккан. Бусы да, телгә килеп:

— Апакай, алмаларым тәмам өлгерде, койсана шуларны, койсана! — дип ялына башлаган.

Тик ялкау кыз аның үтенечен дә тыңламаган.

— Шул гына җитмәгән иде, алмаларыңа башымны тиштерер хәлем юк әле,— дигән дә китеп тә барган.

Берзаман ул Буран патша өенә дә килеп җиткән, көрәк-көрәк тешле ямьсез карчык турында инде ишеткән булганлыктан, ялкау кыз тамчы да курыкмаган, кечкенә өйгә кыю гына килеп кергән. Беренче көнне көчен дә кызганмаган бу, карчык кушкан бөтен эшләрне төгәл үтәргә тырышкан, Буран патшага ошап кына алтынлы була алачагын онытмаган. Әмма икенче көнне иренә башлаган, өченче көнне инде тәмам ялкауланган, иртән урыныннан да кузгалмаган. Буран патшаның урын-җирен дә җыештырмаган, мамык-йоннары очарлык итеп ястык-мендәрләрен дә какмаган. Чиксез ялкаулыгын күреп, Буран патша аңардан бик тиз туйган, кызны күрәсе дә килми башлаган. Ә ялкау моңа шатланган гына, менә хәзер өстемә алтын яңгыры яудырыр да өемә кайтарып җибәрер дип уйлаган.

Буран патша аны да әлеге капка янына алып килгән.

Тик капка турысына җитү белән, ялкау кыз өстенә алтын урынына бер казан сумала яудырган. Буран патша:

— Хезмәт хакың менә шул булыр,— дигән дә капкасын шартлатып ябып та куйган.

Күтәрелеп караса, ялкау кыз өйләре янында басып тора, ди, үзенең бөтен җире чем-кара сумала белән капланган, ди. Кое бурасына менеп кунаклаган әтәч, аны күрүгә:

Ки-ке-ри-кук, ки-ке-ри-кук,
Безнең апай пәри кук! —

дип кычкырып җибәргән.

Сумала исә ялкау кыз тәненә шулкадәр нык ябышкан, ди, гомере буе юып та, кырып та бетерерлек булмаган, ди.

ЧӘНТИКӘЙ

Әүвәл-әүвәл заманда бер ярлы кеше яшәгән, ди. Кичләрен кисәү агачы белән кызган күмерләрне бутый-бутый учак яга, хатыны, янына утырып, җеп эрли икән, ди. Бервакыт ул хатынына:

— Бала-чагасыз бигрәк күңелсез инде. Кешедә уен да көлке, бездә генә тып-тын,— дигән.

Хатын, авыр сулап:

— Әйе шул,— ди икән.— Берәү генә булса да, кеп-кечтеки, чәнти бармак тикле генә булса да, шатлыгыбыз чигеннән ашар иде дә бит, үлеп яратыр идек тә бит үзен...

Ни хикмәттер, җиде айдан хатын бер ир бала тапкан. Бөтен җире килгән, ди баланың, тик менә буе гына чәнти бармактан ашмаган, ди.

— Теләгебез кабул килде, күз генә тимәсен нарасыебызга,— дип сөенешкәннәр ир белән хатын. Исеме җисеменә туры килсен дип, бәбигә Чәнтикәй дип ат кушканнар, ди.

Ни генә ашатмаганнар балакайга! Тик Чәнтикәй бер дә буйга үсмәгән, туганда ничек булса, һаман шул килеш кала биргән, ди. Шулай да акылга зирәклеге, иртә шәйләнгән үткенлегенә тора-бара хәйран калырлык булган, ди, нинди генә эшкә тотынса да, кулыннан килә икән, ди, моның.

Шулай бер көнне бу ир урманга барып кышлык утын хәстәрләргә җыенган. Үзалдына:

— Кискән утыныңны алырга ат җигеп килүче булса, ни әйтер иде́ң дә бит! — дип сөйләнә икән. Моны ишетеп торган Чәнтикәй:

— Әткәй,— дигән,— бер дә хафаланма, үзем барырмын яныңа. Ышан, нәкъ сөйләшенгән вакытка килеп җитәрмен.

— Булдыра алырсыңмы икән соң, улым? — дип көлгән, ди, этисе,— бу буең белән дилбегә тотулары, ай-һай!..

— Бер дә исең китмәсен, әткәй. Әни җигеп бирсә, атның колагына кереп утырырмын да кая барасын әйтеп торырмын үзенә...

— Карап карыйк соң алайса,— дигән этисе.

Барыр вакыт җиткәч, әнисе ат җигеп биргән, малайны бахбайның колагына кертеп утырткан. Чәнтикәй әледән-әле: «На-а! На-а! Сулгарак! Кыймылда инде!» — дип кычкырына, ди. Эшләр шәптән малайның, гомер буе ат җигеп йөргән диярсең! Урман юлыннан тайпылмыйча бара да бара икән бахбай. Чәнтикәй борылышларда аны: «Сулгарак, малкай! Сулгарак!» — дип куалаганда, каршыга ике кеше килеп чыккан.

— Кара әле, кара, ниткән әкәмәт бу? — дигән берсе.— Ат җилдерепме җилдерә, хуҗасының куалаган тавышы да ишетелә кебек, тик арбасында беркем күренми.

— Берәр хикмәте бардыр моның,— дигән икенчесе,— әйдә, артыннан калмыйк әле, кайда нәрсә эшләр икән?

Җигүле ат исә урманга кереп киткән дә бераздан кисеп аударылган агачлар янына килеп туктаган. Әтисен күрү белән, Чәнтикәй:

— Менә, килеп тә җиттем, әткәй. Йә, төшер инде мине җиргә,— дип кычкырып җибәргән.

Сул кулы белән йөгәнне тоткан этисе, уңы белән ат колагыннан Чәнтикәйне күтәреп алган. Кәефе әйбәт, ди, малайның, бер зуррак үлән яфрагына менгән дә кунаклаган, ди. Теге кешеләр, Чәнтикәйне күргәч, шаккатудан телсез калганнар. Аннары берсе иптәшен читкәрәк алып киткән дә әйткән, ди:

— Беләсеңме, бу бәләкәч безгә бәхет чишмәсен ача ала бит. Берәр зур шәһәргә алып барып, тамаша корып җибәрсәк, рәхәтләнеп акча сугар идек. Әйдә, сатып алыйк әле үзен.— Шулай киңәшкәннәр дә малайның атасы янына килгәннәр.

— Абзый, сат әле бәләкәчеңне, иркәләп кенә тотарбыз үзен,— дигәннәр.

Чәнтикәйнең этисе:

— Юк, юк, күтеп алган бердәнберебез ул, йөрәк парәбез, дөньяда булган барлык алтын-көмешкә дә сатасым юк,— дип кырт кискән.

Бу сатулашуны Чәнтикәй дә тыңлап тора икән. Күлмәк чабуына ябышып үрмәли-үрмәли этисенең җилкәсенә менгән дә колагына:

— Курыкма, эткәй, сат мине син,— дип пышылдаган.— Күр дә тор, ялт итеп әйләнеп тә кайтырмын.

Шуннан соң этисе ризалашкан, Чәнтикәйне әлеге кешеләргә ярыйсы гына бәягә сатып та җибәргән.

— Кая утыртып алып кайтыйк икән соң үзеңне? — дип сораган, ди, тегеләр малайдан.

Чәнтикәй, бер дә исе китми генә:

— Эшләпә читенә,— дигән.— Иркен дә, дөнья күрергә дә шәп булыр. Егылып төшәр дип шикләнмәгез, мин күнеккән инде.

Тыңлаганнар бәләкәчне. Эти кеше белән тиз-тиз генә саубуллашып китеп тә барганнар. Баралар, баралар, ди, болар, инде караңгы төшеп күз дә бәйләнә башлаган, ди. Чәнтикәй яңа хуҗаларыннан:

— Йомышым бар иде, бер генә минутка җиргә төшерегез әле,— дип сораган.

— Әй, йомышла инде шунда гына,— дигән бәләкәчне эшләпәсенә утырткан ир,— юк-бар өчен төшеп торма, аның хәтле генә кошлар да юешләтеп китә.

— Юк-юк, алай ярамый, әдәпсезлек була,— дигән Чәнтикәй.— Төшерегез тизрәк җиргә!

Абзый кеше, эшләпәсен салып, юл читендәге буразнага куярга мәҗбүр булган. Чәнтикәй тиз генә эшләпәдән җиргә сикереп төшкән, бераз камыллар арасында йөренгән. Аннары, бер тычкан оясын күреп алып, елдам гына шунда кереп качкан. Ышанычлы җиргә кереп яшеренгәч, бәләкәч тегеләрдән рәхәтләнеп көләкөлә:

— Йә, әфәнделәр, хәерле төн сезгә! Хәзер инде юлыгызны миннән башка гына дәвам итегез. Алдыгыздан артыгыз матур! — дип кычкырган.

Әле тегендә, әле монда сугылганнар ачыкавызлар, таяклары белән тычкан ояларына төрткәләгәннәр, тик берни дә барып чыкмаган: Чәнтикәй һаман тирәнгәрәк кенә качкан. Ул арада күзгә төртсәң күренмәслек караңгылык төшкән. Зур табыш алырга өметләнгән җилкуарлар, тәмам кәефләре кырылып, буш кул белән үз юлларына китеп барганнар. Аяк тавышлары ерагайгач, Чәнтикәй дә тычкан оясыннан чыккан. Үзе: «Мондый

карацгыда басуда йөрүдән ни мәгънә, аягыңны гына түгел, муеныңны да сындырырсың монда»,— дип сөйләнә, ди. Бәхете бар икән тагын, ерак та китмәгән, шактый зур әкәм-төкәм кабырчыгына юлыккан.

— Кунып чыгарга урын да табылды,— дип сөенгән малай.

Бәләкәч, кабырчык эченә кереп, йокыга китәм дигәндә генә аяк тавышлары ишетелгән. Ул да булмаган, үзара сөйләшә-сөйләшә кабырчыкка ике кеше якынлашкан.

— Теге попның алтын-көмешләрен чәлдерәсе иде бит,— ди икән берсе.

— Ярар иде дә, тик нинди әмәлен табарга соң? — дигән икенчесе.

— Әмәлен табабыз аның,— дип кычкырган Чәнтикәй кабырчык эченнән.

Каракларның берсе, өне алынып:

— Бу ни галәмәт? — дигән.— Кемдер кычкырды түгелме?

Икесе дә туктальш, бер мәл тын да алмый тыңлап торганнар. Чәнтикәй исә янә:

— Мине дә ияртегез, булышырмын үзегезгә,— дип эндәшкән.

— Кем соң син, әй? Кайда кычкырып ятасың?

— Җирдән эзләгез, җирдән, тавыш килгән якны карагыз,— дигән малай.

Караклар, шунда гына әкәм-төкәм кабырчыгын күреп, аны кулларына алганнар.

— Ничек булышырсың икән соң син безгә, бәләкәч? — дигәннәр алар.

— Ә менә ничек,— дип җавап биргән малай,— тимер рәшәткәләр арасыннан чоланга керермен дә сораган нәрсәләрегезне алып бирермен.

— Ни эшкә яраганыңны сынап карыйк алайса,— дигән караклар.

Килеп җиткәннәр болар поп йортына. Чәнтикәй чоланга кергән дә шәрран ярып кычкыра башлаган:

— Мондагы хәзинәнең барысын да аласызмы, әллә сайлап кына биримме?

Караклар шүрли калган, малайны кисәтеп:

— Шыпырт! Нәрсә бугаз ертасың, тавышыңны ишетеп хуҗалар уяныр,— дигәннәр.

Чәнтикәй исә, берни аңламагандай, һаман үзенекен иткән, тагын кычкыра башлаган:

— Нәрсәләр бирим соң сезгә? Мондагы малның барысын да аласызмы, әллә...

Чоландагы шау-шуга күрше бүлмәдәге хезмәтче кыз уянган, колагын торгызып көтә башлаган. Караклар куркып качмакчы булганнар, тик бераздан тагын гайрәтләнгәннәр, бу бәләкәч безне юри шулай үчеклидер дип уйлап, кире борылып килгәннәр.

— Шаяртып торма, әйдә, тизрәк алып бир асылташларны!

Чәнтикәй исә бу юлы баягыдан да катырак кычкырган:

— Бирәм, бирәм, барысын да бирәм, кая, кулыгызны сузыгыз,— дигән.

Хезмәтче кыз бу сүзләрне ап-ачык ишеткән. Шунда ук караватыннан сикереп төшкән дә абына-сөртенә ишеккә ташланган. Артларыннан ерткыч җанвар кугандай, караклар җан-фәрман чыгып качкан. Хезмәтче кыз караңгыда берни дә күрмәгән, ут кабызыйм әле дип, кухняга кереп киткән. Шул арада Чәнтикәй амбарга качып өлгергән. Хезмәтче кыз чоланның бөтен почмакларын кат-кат тикшереп чыкса да, бернинди дә җан иясен тапмаган. Кире кереп түшәгенә яткач, төшләнәм, ахрысы, дип уйлаган. Чәнтикәй исә амбардагы печән өстенә үрмәләп менгән дә йоклар өчен җайлы гына урын әзерләгән. Шушында ял итеп алыйм да таң аткач әти-әни янына кайтып китәрмен, дип ниятләгән.

Ләкин күрәселәре алда булган икән әле аның! Дөньяда кайгы-хәсрәт шатлыктан күбрәк ич!

Хезмәтче кыз, таң беленер-беленмәс йокысыннан торып, йөгерә-йөгерә терлекләрне ашатырга чыккан. Иң элек амбарга кереп бер кочак печән алган. Нәкъ шушы печән өемендә мескен Чәнтикәй изрәп йоклап ята икән. Бик каты йоклаган булган бәләкәч, кыштырдауларны да, кызның печәнне сыер алдына салуын да сизмәгән. Үзен печән белән бергә сыер кабып йоткач кына уянган, ди, Чәнтикәй.

Алай да бәхете бар икән, чәйнәлгән печән белән бергә зыян күрми-нитми генә сыерның ашказанына ук төшеп киткән. Бу нәни бүлмәгә тәрәзә куярга да онытканнар, ахры: кояш та күренми, ут кабызырга да җыенмыйлар сыман, дип уйлаган ул башта. Турысын әйткәндә, бу яңа фатиры бер дә ошамаган малайга. Җитмәсә, уйламаганда-көтмәгәндә яңа бәла якынлашкан: сыер ашказанына чәйнәлгән печән бертуктаусыз өстәлә тора, буш урын һаман кими бара икән. Бераздан ни буласын уйлап, Чәнтикәйнең коты алынган, бар көченә:

— Әй, җитте сезгә, бүтән ашатмагыз хайванны! Бер уч үлән дә бирмәгез,— дип кычкыра башлаган.

Хезмәтче кыз сыерны савып маташа икән. Сәер тавышны ишеткәч, як-ягына каранган, тик берәүне дә күрмәгән. Төнлә чоланда ишетелгәнгә охшаган тавыш исә һаман килә, ди. Кызның өне алынган, эскәмиясе-ние белән мәтәлеп китеп, сауган сөтен җиргә түккән. Аннары, уңга-сулга карамастан, хуҗасы янына йөгергән. Тотлыга-тотлыга:

— Хуҗа әфәнде, сыерыбыз кеше кебек сөйләшә,— дигән.

— Акылыңнан яздыңмы әллә? — дигән хуҗа.

Шулай да кыз артыннан ияреп чыккан, абзардагы әкәмәтне үз күзләре белән күрәсе килгән. Поп абзар ишеген ачып җибәрүгә, Чәнтикәй яңадан сөрән салган, ди:

— Әй, җитте сезгә, бүтән ашатмагыз хайванны! Бер генә уч үлән дә каптырмагыз!!

Моны ишеткәч, поп та өнсез калган. Мөгаен, җенфәлән ияләшкәндер малкайга, дип уйлаган, аны хәзер үк суярга кушкан. Сыерны суйганнар да Чәнтикәй яткан ашказанын тирес өеменә чыгарып ташлаганнар. Монда аңа сыер карыныннан чыгар өчен бик озак маташырга туры килгән. Инде чыгып җиттем дигәндә генә яңа бәлагә тарган: шул тирәдән үтеп барган бер ач бүре эчендә бәләкәч яткан ашказанны чәйнәми-нитми бер кабуда йоткан да җибәргән.

Тик Чәнтикәй бу юлы да күңелен төшермәгән. Бүре белән дә килешеп булмас микән, дип уйлаган.

— Кадерле бүре әфәнде,— дигән ул,— телеңне йотардай бик тәмле майлы калҗа ашыйсың киләме?

— Тизрәк әйт: кайда ул калҗа? — дигән комсыз бүре.

— Ә-ә-әнә теге йортта. Су агып торган чокырны күрәсеңме? Калҗалы йортка менә шул чокыр буйлап барасы. Амбарларына керсәң, бөккән дисеңме, дуңгыз мае, казылык дисеңме — җаның теләгән кадәр сыйлан!

Бәләкәч үз йортларын мактаган икән бүрегә.

Комсыз бүре ике әйткәнне көтмәгән, төн җитүгә, чокыр буйлатып әлеге йортка таба шуышкан, исән-имин амбарга кереп, шартлаганчы тыгынган. Ашап туйгач, амбардан чыкмакчы булган икән дә, комсызның корсагы шулкадәр күбенгән, ди, кергән тишеккә берничек тә сыя алмый икән, ди. Чәнтикәй аның нәкъ менә шул чамасыз нәфесенә исәп тоткан да инде. Ерткычның тозакка эләгүе була, бүре корсагындагы бәләкәч тиберчеңә, бар көченә шәрран яра башлый.

— Туктыйсыңмы, юкмы? — дигән бүре.— Адәм балаларын уятасың лабаса!

— Менә кызык,— дигән Чәнтикәй,— син тамагыңны туйдырдың, күңелеңне күрдең. Миңа да кәсеп итәргә вакыттыр!

Шуннан соң ул янә бар көченә кычкыра башлаган. Тавышка әти-әнисе уянган, нәрсә бар икән дип амбар янына килгәннәр дә ярыктан күзәтә башлаганнар, ди. Анда комагай бүре кергәнлеген күргәч, икесе ике якка йөгергән: ире — балта, хатыны чалгы эләктергән. Абзый кеше, амбар ишеген ача-ача, хатынына:

— Син менә шушында тор,— дигән.— Мин хәзер аңа берне тондырырмын. Тик бер сугудан гына дөмекмәстер, аңына килгәнче корсагын ярып җибәрерсең мәлгуньнең.

Чәнтикәй, атасының тавышын ишетеп, хәбәр биргән:

— Кадерле әткәем, мин монда, бүре корсагында,— дигән.

— Аллага мең шөкер, сөекле бәләкәчебез табылды ич,— дигән атасы шатланып.— Хатын, ташла чалгыңны, Чәнтикәйне имгәтүебез бар.

Аннары киерелеп торып кизәнгән дә балтасы белән бүренең башына кундырган. Ерткыч «әһ» диярга дә өлгермәгән, дөмегеп җиргә тәгәрәгән. Шуннан соң пычак белән кайчы алып чыкканнар да бүренең корсагын ярганнар. Чәнтикәй «тып» итеп якты дөньяга килеп чыккан.

— Уф, синең аркада күпме кайгы-хәсрәт кичердек,— дигән атасы.

— Шулайдыр шул, әткәй, шулайдыр,— дигән малай.— Сәяхәттә үзем дә хәтсез йончыдым. Тик ахыры хәерле булды, менә хәзер тагын саф һавада рәхәтләнәм.

— Кайларда булдың соң, улым?

— Әй, әткәй, булдым инде. Тычкан оясына да төштем, сыер ашказанына да эләктем, бүре корсагында да җәфа чиктем. Моннан соң инде сезне ташлап беркая да йөрмәм.

— Без дә сине моннан соң читкә чыгармабыз, әллә нинди алтын-көмешләргә дә алыштырмабыз.

Әти-әнисе кадерле Чәнтикәйләрен иркәләгәннәр, назлаганнар, туйганчы ашатканнар-эчергәннәр. Маҗаралы сәяхәте вакытында элеккеләре тәмам ертылып-тузып беткәнлектән, аңа өр-яңа матур киемнәр теккәннәр, ди.

ЙОКЫГА ТАЛГАН ГҮЗӘЛ

Борын-борын заманда бер король яшәгән, ди. Бик тә бала үстерәсе килә икән моның. Хатынына көн дә:

— Их, бер бәби табып бирсәң! — дип уфтана икән.

Хатыны да бик теләгән дә бит, тик ни хәл итсен?

Шулай беркөнне король хатыны су коена икән. Көтмәгәндә яр башына бер бака үрмәләп менгән дә:

— Теләгегез кабул булыр: бер ел да үтмәс, кыз бала табарсың,— дигән.

Бер ел үтәр-үтмәс король хатыны чыннан да бер кыз бала тапкан. Шундый матур, ди, бәби, король сөенеченнән нишләргә дә белмәгән. Аннары кызы туу хөрмәтенә бәйрәм ясарга — зур мәҗлес уздырырга ниятләгән. Мәҗлескә туганнарын, дусларын, таныш-белешләрен генә түгел, мәмләкәтендәге тылсым ияләрен дә чакырган. Кызына мәрхәмәтле булуларын, аны бәла-казалардан саклауларын өмет иткән инде король.

Мәмләкәтендә тылсым ияләре унөч икән. Ләкин хәзинәдә алтын савыт-саба тагын унике кешегә җитәрлек кенә калган икән. Байлыгы чамалы булуын корольнең бер дә кешегә сиздерәсе килмәгән. Шуңа күрә тылсым ияләренең берсен чакырмаска әмер биргән.

Бик бай, бик купшы итеп хәстәрләгәннәр мәҗлесне. Ашаган-эчкәннән соң тылсым ияләре кызга матур теләкләрен белдерә башлаганнар. Берсе — саф күңел, икенчесе — гүзәллек, өченчесе — байлык, кыскасы, дөньяда кадерле саналган нәрсәләрнең барысын да юраганнар. Унберенче тылсым иясе сүзен тәмамлаганда гына, уйламаганда-көтмәгәндә, мәҗлескә чакырылмаган унөченче күрәзәче килеп кергән, ди. Үзен санга сукмаган өчен үч алырга уйлаган, ди, ул. Берәү белән дә исәнләшмәгән, һичкемгә күтәрелеп карамаган, ди, сихерче. Керү уңаена дорфа тавыш белән сөрән салган, ди:

— Король кызы унбиш яшенә җиткәч орчыкка кадалып үлсен!

Шулай дигән дә, бүтән бер сүз дә әйтмәстән, чыгып та киткән.

Бу шомлы теләк барысын да куркуга төшергән. Шулчак тылсым ияләренең әле үз сүзен әйтергә, бүләген бирергә өлгермәгән уникенчесе торып баскан. Ләкин аның явыз сихерче каргышын бөтенләй юкка чыгарырга кодрәте җитмәгән, ул каргыш тәэсирен бары тик җиңеләйтә генә ала икән. Шуңа күрә уникенче тылсым иясе:

— Король кызы үлмәсен, йөз еллык йокыга гына талсын,— дип теләгән, ди.

Король сөекле кызын очраклы бәхетсезлектән коткарырга теләп: «Мәмләкәттәге бөтен орчыклар яндырылсын!» дигән фәрман чыгарган.

Тылсым ияләренең теләкләре барысы да үтәлгән: кыз шундый гүзәл, шундый тыйнак, шундый ягымлы һәм шундый акыллы булган, ди, кем генә күрсә дә, аңа сокланып туя алмый икән, ди.

Ничек туры килгәндер, әмма нәкъ унбиш яше тулган көнне кыз сарайда берүзе генә калган, ди. Король хатыны белән каядыр китеп барган икән. Кыз бөтен сарайны айкап йөри башлаган: бүлмәләрне, болдырларны тикшерә, күңеле ни теләсә, шуны эшләп йөри икән, ди. Менә ул шулай иске манара янына килеп чыккан, аның бормалы тар баскычларыннан өскә күтәрелгән. Менеп җиткәндә генә кечкенә бер ишеккә тап булган ул. Ишектә, гомер буена бер тапкыр да ачылмаганлыктан, күгәреп беткән йозак, ди, ачкычы исә шунда гына асылынып тора икән, ди. Кызның ачкычны борып җибәрүе булган, ишек ачылып та киткән. Караса, нәни генә бер бүлмә икән, ди, йон кабасы артында бер карчык утыра, ди, тырышып-тырышып җеп эрли, ди.

— Хәерле көн, әбекәй,— дигән король кызы,— нишләп утырасың монда?

Карчык кабага башын иеп:

— Җеп эрлим,— дигән.

— Ә бу нәрсә соң? Кара әле, кара, ничек күңелле зырылдап бөтерелә,— дип кызыксынган кыз.

Ул, орчыкны кулына алып, үзе дә эрләп карамакчы булган. Менә шул вакыт аңа теге унөченче күрәзәченең каргышы төшкән дә инде: кагылуга, орчык бармагына кадалган, шул мизгелдә үк король кызы, караватка авып, тирән йокыга талган. Ул гына да түгел, бу сихерле йокы бөтен сарайны басып алган. Әле генә кайтып кергән король дә, аның хатыны да, галиҗәнапләрне озата йөрүче хезмәтчеләр дә — барысы, барысы берьюлы йокыга киткән. Абзарлардагы атлар да, ишегалдындагы этләр дә, сарай түбәсендәге күгәрченнәр дә, диварларга кунган чебеннәр дә, хәтта, учакта дөрләп янган ут та, әйе, әйе, һәммәсе дә хәрәкәтсез калып, йокыга чумган. Табада кыздырыла торган ит тә чыжылдавыннан туктаган, нәрсәнедер карап җиткермәгәне өчен ярдәмчесен чәченнән элэктергән аш пешерүче дә шул хәлендә йокыга талган, хәтта искән җил дә кинәт

тынып калган, сарай бакчасындагы агачларның яфраклары да лепердәшми башлаган.

Шул көннән алып король сарае тирәсендә чәнечкеле гөлҗимеш куаклары котырынып үсәргә керешкән. Алар елдан-ел югарырак үрләгәннәр, берзаман сарайдан да биегрәк калкып, тирә-якны бөтенләй каплап алганнар. Чәнечкеле куаклар аша берни дә күренмәс булган, хәтта сарай түбәсендәге байрак та күздән югалган. Бөтен дөньяда йокыга талган гүзәл турында төрле-төрле имеш-мимешләр таралган, аны «Гөлҗимеш» дип йөртә башлаганнар.

Вакыт-вакыт сихерләнгән сарай янына төрле илләрнең асыл егетләре килеп, чәнечкеле гөлҗимеш киртәсе аша сарайга үтеп керергә тырышып караган. Ләкин аларның берсе дә максатына ирешә алмаган, ди, чөнки гөлҗимеш чәнечкеләре үзара калкан кебек укмашалар да һичкемне үткәрмиләр, ди, кияү егетләре чәнечкеләр арасында чәбәләнеп калалар, аннары, мәкерле тозактан котыла алмыйча, көтелмәгән үлемгә дучар булалар икән.

Бик күп еллар үткәч, бу якларга ерак илдән тагын бер король малае килеп чыккан, ди. Ул, бер чал картның сөйләве буенча, чәнечкеле яшел койма артында мәһабәт сарай булырга тиешлеген, шул сарайда Гөлҗимеш исемле искиткеч гүзәл король кызының моннан нәкъ йөз ел элек йокыга талганын белгән. Гүзәлкәй белән бергә король үзе дә, аның хатыны да, сарайдагы бөтен хезмәтчеләр дә тирән йокыга чумганнар, имеш. Ул карт, бабасыннан ишетеп, бу сихерләнгән сарайга бик күп король малайлары килүе, аларның чәнечкеле куаклар аша шунда үтеп керергә маташулары, ләкин барысының да гөлҗимеш ботакларына эләгеп ярты юлда калулары, сәер тозактан ычкына алмыйча, мескеннәрчә һәлак булулары турында да белә икән. Бу сүзләрне ишеткәч, егет гайрәтләнеп:

— Ә мин барыбер курыкмыйм, сихерләнгән сарайга үтеп кермичә, гүзәл Гөлҗимешне күрмичә, моннан китмәячәкмен! — дигән, ди.

Аксакал егетне анда барып йөрмәскә үгетләп тә караган, тик король малае аның сүзен тыңламаган. Ә бу вакытта сарай сихерләнгән минуттан соң нәкъ йөз ел гомер узып киткән, Гөлҗимешнең яңадан уяныр көне дә җиткән икән. Егет якынлашу белән, чәнечкеле куаклар искиткеч матур чәчәкләргә әверелгәннәр, ди, ә үзләре кунак якынлашкан саен як-якка тайпылалар, аны

зарарламый-нитми генә үткәреп җибәрәләр, ди. Артыннан исә, яшел койма булып, яңадан ябыла баралар, ди.

Сарай ишегалдына килеп кергәч, егет тагын да гаҗәбрәк хәлләргә тап булган: алмачуар атлар, озын сыйраклы ау этләре аягүрә йоклыйлар, ди. Каралты түбәләрендә, башларын канат астына тыгып, күгәрченнәр дә катып калганнар, ди.

Сарайга кергәч, диварларга кунган чебеннәрне, аш пешерүченең ярдәмчесен чәченнән эләктерергә чамалагандай кулын сузган килеш кухняда басып торуын, хезмәтче хатынның кара тавыкны йолкырга җыенган килеш хәрәкәтсез калганын күргән.

Ерак илдән килгән кияү-егет, хәйран калып, ары узган. Олы залга керсә, ни күрсен, мондагы бөтен аксөякләр мәрткә киткәннәр, ди, ә өстәрәк тәхеткә утырырга өлгермәгән король белән аның хатыны бик уңайсыз хәлдә йокыга оеганнар, ди. Бөтен нәрсә тынлык кочагында эрегән, кунак егет үзенең сулыш алуын да ап-ачык ишетеп тора икән.

Шуннан соң ул иске манара янына барып чыккан, аның баскычлары буйлап югарыга менгән дә Гөлҗимеш йокыга талган кечкенә бүлмә ишеген ачып җибәргән. Анда гүзәлләрдән дә гүзәл кыз йокыга талып ята икән, ди. Егет аңардан күзен ала алмаган, үз-үзен онытып, иелгән дә кызның иреннәренә иренен тидергән. Үбүе булган, Гөлҗимеш күзләрен ачкан, аннары тәмам уянып, ят егеткә гаҗәпләнеп карап тора башлаган.

Җитәкләшеп манарадан төшкәннәр, ди, болар. Шул мизгелдә король белән аның хатыны да, сарайдагы аксөякләр дә уянганнар, бер-берләренә гаҗәпсенеп, сәерсенеп карашып алганнар. Ишегалдындагы атлар да кешнәп җибәргән, аучы этләр дә койрыкларын болгый-болгый сикерешә башлаган. Каралты түбәсендәге күгәрченнәр, башларын канат астыннан чыгарып, кагына-кагына як-якларына каранганнар да басуга таба очып киткәннәр. Дивардагы чебеннәргә дә җан кергән. Кухня учагында яңадан дөрләп ут кабынган, казанда аш кайнарга, табада ит чыжылдарга тотынган, ди. Аш пешерүче ярдәмчесенең яңагына чалтыратып алган, ә тегесе кычкырып елап җибәргән. Хезмәтче хатын да тавыгын йолкып бетергән.

Менә шуннан соң, дөньяны таң калдырып, ерак илдән килгән кыю егет белән Гөлҗимешнең туен иткәннәр, ди. Алар бик тату, бик бәхетле тормыш корып җибәргәннәр, ди.

ТУКРАНСАКАЛ

Бер корольнең бердәнбер кызы булган, ди. Аның бер дә килмәгән җире юк, шундый чибәр, шундый сөйкемле икән, ди. Тик ул бик тәкәббер, бик масаючан булган, бер генә егетне дә үзенә тиң күрмәгән, ди. Кодалап килгәннәрне кире борып җибәргән, өстәвенә әле мыскыл итеп калган.

Шулай берзаман король бик зур мәҗлес җыйдырган. Кызын яучылаган егетләрнең якын-тирәдәгеләрен дә, ерактагыларын да — барысын-барысын да чакырткан, ди. Аларны табынга дәрәҗәләренә карап утыртканнар, ди. Түрдә корольләр, алар янәшәсендә — герцоглар, князьләр, графлар, бароннар, ишек катына таба дворяннар тезелгән, ди.

Үзенә ошаганын сайлап алсын өчен, король кызын шул саф алдыннан уздырганнар, ди. Ләкин кыз егетләрнең һәркайсыннан нинди дә булса җитешсезлек тапкан, ди. Гәүдәгә тулырак булганыннан: «Сыра мичкәсе!» — дип көлгән, буйга озынрагын: «Урманда үскәнмени, шөкәтсез колга!» — дип гаеп иткән. Тәбәнәгенә: «Үзе карсак, үзе юан, кайдан килгән пәһлеван»,— дигән, аксыл чырайлысын: «Гүрдән чыккан өрәк!» — дип мәсхәрәләгән, ди. Алсу йөзлесен: «Горур күркә»,— дип мыскыллаган, бераз бөкрәебрәк утырганын: «Мич башында киптерелгән утын агачы»,— дип кимсеткән, ди. Шулай итеп, егетләрнең барысыннан да бер җитешсез як тапкан, ди. Бүтәннәргә караганда күреклерәк булган, әмма сакалы очлаеп торган яшь корольдән дә: «Карагыз әле моның сакалына, тукран томшыгымыни!» — дип рәхәтләнеп көлгән әле ул. Шуннан соң әлеге корольгә «Тукрансакал» дигән кушамат тагылып калган, ди.

Кызының, шулай барысын да үчекләп, мәҗлеснең ямен җибәрүенә, егетләрне үзеннән биздерүенә корольнең яман да ачуы чыккан, мин ул тәкәбберне ишектән кергән беренче хәерчегә кияүгә бирәчәкмен, дип ант иткән, ди.

Шушы хәлләрдән соң берничә көн үткәч, сарай тәрәзәсе каршына бер йолкыш җырчы килеп баскан да, бераз хәер-садака бирмәсләрме икән, дип җырлый башлаган, ди. Урам җырчысының тавышын ишеткәч, король хезмәтчеләренә:

— Әйтегез әле шул хәерчегә, монда керсен,— дигән, ди.

Бүлмәгә кием-салымы теткәләнеп, пычранып беткән

БИБЛИОТЕКА
ТАТКНИГОИЗДАТА
Инв. № 3130

әлеге җырчы килеп кергән. Ул корольгә, аның кызына атап бер җыр җырлаган. Аннары:

— Мәрхәмәтле галиҗәнаплар, хәер-шәфкать күрсәтсәгез лә! — дип үтенгән, ди.

Король:

— Җырлавың бик тә ошады, шуңа күрә сиңа садака урынына кызымны бирәм, киявем булырсың,— дигән, ди.

Кыз өнсез калган, карышып та маташкан, билгеле. Ләкин атасы:

— Король сүзе бер булыр, антымны боза алмыйм инде хәзер,— дип кырт кискән, ди.

Тиз генә попны чакырып китергәннәр дә шул минутта ук урам җырчысы белән кызына никах укырга кушканнар. Никах укылгач, атасы:

— Хәзер хәерче хатыны булдың инде син, король сараенда яшәү килешмәгәнен үзең дә аңлыйсыңдыр. Менә ирең, үз куышыгызда гомер итегез, хәерле юл! — дигән, ди.

Хәерче, никахлы хатынын җитәкләп, сарайдан чыгып киткән. Король кызына язмыш иркенә буйсынудан бүтән чара калмаган.

Бер карурман буена якынлашкач, кияү белән кәләш болай сөйләшеп алганнар:

— Кем байлыгы икән бу урман?
— Ия аңа борын-борыннан
Тукрансакал дигән бер олан.
— Аһ, назланып нигә карыштым,
Мыскыл итеп бигрәк ялгыштым.

Күпмедер юл үткәч, бер ямьле болын аша узарга туры килгән боларга. Кыз тагын сораган, ди:

— Кем байлыгы соң бу болыннар?
— Алар инде борын-борыннан
Тукрансакал абзаң кулында.
— Аһ, нигә мин аңа карыштым,
Мыскыл итеп бигрәк ялгыштым!

Бара-бара бер бик матур шәһәргә дә килеп кергәннәр, ди, болар. Кыз янә дә сораган, ди:

— Кем байлыгы икән бу кала?
— Ия аңа инде күп заман
Тукрансакал дигән бүз бала.
— Аһ, мин, мескен, нигә карыштым,
Мыскыл итеп бигрәк ялгыштым.

Ире тыңлап барган-барган да моны, түзмәгән:

— Синең нәрсәгәдер үкенүең миңа бер дә ошамый,— дигән.— Әллә күзләгән берәр кешең бар идеме синең?

Шулвакыт кыйшаеп беткән бер кечкенә алачык янына килеп туктаган, ди, болар. Кыз яңадан сораган, ди:

— Кем өе бу, кысан, кечкенә,
Бик кыендыр монда мескенгә?

— Үз куышыбыз инде бу, юрганыңа күрә аягыңны сузып, тарсынмый гына яшик,— дигән ире.

Ишеге тәбәнәк булганлыктан, моңа кадәр берәүгә дә баш ияргә теләмәгән тәкәббер кыз өйгә кергәндә яхшы ук бөгелергә мәҗбүр булган.

Ире йортына аяк баскач, король кызы:

— Хезмәтчеләрең кая соң? — дип сораган, ди.

— Нинди хезмәтчеләр? — дип гаҗәпсенгән ире.— Хәерченең хезмәтчесе булмый, бар эшне дә үзеңә эшләргә туры киләчәк. Менә хәзер тиз генә учак кабызып җибәр дә ашарга пешер, юкса тәмам хәлдән тайдым, карыным ачты.

Ләкин иркәләнеп-назланып кына үскән король кызы учак та кабыза алмаган, ашарга да пешерә белмәгән. Хатыны бер эш тә булдыра алмагач, ирнең үзенә җиң сызганырга туры килгән. Аннары туяр-туймас ашаганнар да йокларга ятканнар, ди, болар.

Иртәгәсен хатынын таң беленер-беленмәс үк уяткан, ди, ир, өй эшләрен карарга кушкан, ди. Менә шулай берничә көн узып та киткән, ди. Яхшы дисәң — мактарлык түгел, начар дисәң — түзәрлек, ди, шунда. Әмма тиздән ашар ризыклары беткән, ди, боларның. Ире хатынына:

— Ачтан үлмәс өчен кәсеп итәргә кирәк бит, югыйсә, ашавын ашыйбыз, берни дә эшләмибез. Болай ярамый, кәрзин үрә башласак, ничек булыр икән? — дигән.

Шулай дип чыгып киткән дә бераздан бер кочак тал чыбыгы күтәреп алып кайткан, ди, бу. Хатыны кәрзин үрергә тотынган, тик ярты сәгатьтән үк нәзберек кулларын җәрәхәтләп бетергән, ди. Ире, пошынып:

— Хәлеңнән килә торган эш булмады ла бу,— дигән.— Җеп эрләп кара әле, шунысыннан уңмабызмы?

Хатыны бер төргәк җитен алган да җеп эрләргә тотынган, ләкин, җаен белмәгәнлектән, бик тиз бармакларын суйдырып, сөялләндереп бетергән, хәтта җәрәхәтләреннән кан саркый башлаган, ди.

— Кара инде,— дигән ире, кәефе кырылып,— бер генә эшкә дә кулың бармый лабаса! Ай-һай, авырга туры киләчәк миңа синең белән! Чүлмәк-чынаяк, савыт-саба белән сәүдә итүне сынап карарга кирәк. Мин ясармын, син шуларны базарда сатарсың.

Ире чыгып киткәч, король кызы:

— Бар икән күрәселәрем,— дип уфтанган, ди.— Базарга туган илем кешеләре килеп чыкса, хәерче хатыны кебек чүлмәкләр сатып утырганымны күрсәләр?! Рәхәтләнеп көләчәк бит алар миннән, туйганчы мыскыл итәчәкләр.

Тик нишлисең, язмыштан узмыш юк, ачтан үләргә теләмәсәң, барысына да түзәсең.

Башта сәүдәләре ярыйсы гына барган моның. Чибәрлегенә сокланып, йөзенә бер карар өчен киләләр дә тегесен-монысын алалар икән. Ни бәя сораса, сатулашыпнитеп тормый, шуны биргәннәр, ди, кайберләре, хәтта, акчасын түләсә дә, чүлмәкләрен үзенә калдырып киткән, ди. Савыт-саба сатудан килгән акчага хәтсез генә яшәгәннәр, ди, болар. Бер әзерләгәне сатылып беткәч, тагын бик күп савыт-саба юнәткән, ди, ире.

Бу юлы хатын базарда уртагарак утырган, ди. Кеше күп йөри торган мәйданга савытларын саф-саф тезеп куйган да сәүдә итә башлаган, ди. Шул чак көтмәгәндә әллә кайдан бер исерек җайдак килеп чыккан да аты белән чүлмәкләрне таптатып узган, бөтен савыт-сабаларын чәлпәрәмә китергән, ди. Хатын гарьләнүеннән елый башлаган, куркуыннан нишләргә дә белмәгән.

— Күрәселәрем генә бар икән,— дип үксегән, ди, ул,— бу зыяннан ничек кенә котылырбыз?!

Өенә кайткач, елый-елый иренә нинди бәлагә очравын сөйләп биргән. Ире, ачуланып:

— Йә, әйт әле, кем инде мәйдан уртасында савыт-саба тезеп куя? — дигән.— Чөй өстенә тукмак дигәндәй, елап әч пошырма әле. Бу кадәр дә бер эшкә дә ярамассың икән! Кара әле, бүген мин король сараенда булган идем, анда савыт-саба юучы кирәк икән. Әйдә, шунда урнаш әле син, тамак ялыннан булыр дип килештек.

Шулай итеп корольнең назлы кызы савыт-саба юып көн күрә башлаган. Иртә таңнан кухняга килә дә иң авыр эшләрне башкара икән. Башыңа төшсә — башмакчы булырсың дигәндәй, король кызы да әкренләп әрсезләнә башлаган. Бер чүпрәк капчык әмәлләгән дә аңа ике чүлмәк утырткан, аннары шул чүлмәкләргә калдык-постык ашларны тутырып өенә алып кайта башлаган. Байтак вакыт ирле-хатынлы тамакларын әнә шулай туйдырганнар, ди, болар.

Көннәрдән бер көнне король малае туй мәҗлесе ясаган, ди. Хәерче хатыны туй барган залга менгән дә ишек артыннан гына мәҗлесне күзәтмәкче булган. Берзаман ялт итеп утлар кабынган, туй булачак залга бер-

сеннән-берсе баерак, берсеннән-берсе купшырак киенгән кунаклар җыела башлаган, ди. Ялчы хатын, йөрәге әрнеп, үзенең авыр язмышы турында уйлаган, ди. Шушындый мескенлеккә төшергән, шушындый түбәнлеккә тәгәрәткән масаючанлыгын, тәкәбберлеген каһәрләгән, ди.

Өстәлләргә берсеннән-берсе тәмлерәк ашлар китерелгәч, алардан авыз суларыңны агызырлык хуш исләр таралган, ди. Аш өләшүчеләр ара-тирә хезмәтче хатынга да калдык-постык сыныклар биргәләгән, ди. Хатын аларны чүлмәкләренә сала барган, өенә алып кайтырга җыенган, ди.

Мәҗлес кызып барганда залга король малае килеп кергән. Өстендәге киемнәре бәрхеттән дә ефәктән, ди, түшендә зиннәтле алтын чылбыр, ди. Король малае ишек артында басып торган чибәр хатынны күргән дә, аны кулларыннан эләктереп алып, биергә теләгән. Ләкин ялчы хатын, өнсез калып, биюдән баш тарткан, чөнки егетнең кайчандыр үзенә өйләнергә теләгән Тукрансакал икәнлеген таныган. Теге чакта егетне мыскыл итүен, аңа кияүгә чыгудан баш тартуын исенә төшергән.

Ләкин король малае, карышуына да карамастан, ялчы хатынны бию залына алып кергән, ди. Шул чак хатынның алъяпкыч астына яшергән капчык баулары өзелеп киткән дә чүлмәкләре идәнгә тәгәрәгән. Чүлмәктәге ашлары, ит кисәкләре, ипи сыныклары идәнгә түгелгән, ди. Моны күргән кунаклар эчләре катып көлә башлаганнар. Король кызы бу хурлыктан шулхәтле гарьләнгән, ди, җир убылса, бик рәхәтләнеп шунда төшеп юкка чыгарга риза икән, ди. Ул ишеккә ташланган, минуты белән качып котылмакчы булган, ләкин баскычтан төшеп барганда кемдер аны куып тоткан да яңадан залга җитәкләп алып кергән. Күтәрелеп караса, бу һаман шул Тукрансакал икән, ди.

Король малае:

— Курыкма, синең белән җимерек алачыкта яшәүче урам җырчысы мин ич инде ул,— дигән.— Сине үлеп яратканга, юри хәерче булып кыландым лабаса. Әтиеңнең, «беренче кергән хәерчегә кияүгә бирәм», дигән сүзләрен ишетеп калган идем. Базарда чүлмәкләреңне чәлпәрәмә китергән исерек җайдак та мин идем. Боларның барысын да масаюыңны җуяр өчен эшләдем, тәкәбберлегең өчен үртәдем.

Кыз үксеп елый башлаган.

— Бик зур әдәпсезлек күрсәткәнмен мин, шуңа күрә хатының булырга да лаек түгелмен,— дигән.

Тукрансакал, якты йөзен балкытып:

— Йә, тынычлан, кайгы-хәсрәтле көннәребез узды инде. Дөнья шаулатып туй итәбез хәзер. Әйе, әйе, үз туебызны,— дип хатынын юаткан, ди.

Шул минутта король кызы янына Тукрансакалның кәнизәкләре йөгерешеп килгәннәр, аңа матур-матур киемнәр кидергәннәр, ди. Ул да түгел, кызның ата-анасы, туганнары, дус-ишләре дә килеп җиткән, ди. Барысы да Тукрансакал белән король кызының өйләнешүләрен котлаганнар, аларга куанычлы, бәхетле гомер теләгәннәр, ди.

Кызның чын бәхете, ямьле тормышы нәкъ менә шул минутлардан башланган, ди.

Мондый туйларга әләгеп күңел ачу сиңа да, миңа да насыйп булсын!

БАЛЫКЧЫ ҺӘМ АНЫҢ ХАТЫНЫ

Борын-борын заманда бер балыкчы яшәгән, ди. Хатыны белән яр буендагы мескен алачыкта гомер кичерәләр икән болар. Балыкчы үзе көн саен диңгезгә чыгып балык тота, шуның белән көн күрәләр, тамакларын туйдыралар икән.

Беркөнне балыкчы яр буенда кармак салган, көзгедәй ялтырап торган су өстеннән бер дә күзен алмый икән. Бик озак утырган бу шулай. Ахырда калкавычы суга чумган да бик тирәнгә, диңгез төбенә үк төшеп киткән. Тарта икән бу кармагын, тарта икән, берзаман караса — кармагына зур гына бер камбала эләгеп чыккан, ди. Чыккан да телгә килеп:

— Әй, балыкчы, балыкчы, кире диңгезгә җибәрсәнә мине! Гади камбала түгел, тылсымлы принц мин. Мине пешереп ашаудан әллә ни файда күрә алмассың. Итем тәмсез, барыбер ошатмассың. Җибәрсәнә мине дәрья суыма! — дип ялынган, ди.

Балыкчы:

— Ярар, ярар, бик өзгәләнмә! Кешеләрчә сөйләшә торган балыкны мин болай да харап итмәгән булыр идем әле,— дигән.

Аннары камбаланы чыннан да суга җибәргән. Балык тирәнгә-тирәнгә, диңгез төбенә үк төшеп киткән, озын тасмадай булып артыннан канлы эз генә сызылып калган, ди. Балыкчы бу хәлгә хәйран калган, тизрәк өенә— хатыны янына кайтып киткән.

Иренең буш кул кайтып килүен күреп, хатыны:

— Бүген берни дә тота алмадыңмыни? — дип сораган.

— Бер камбала капкан иде кабуын, тик ул телгә килде дә: «Кире җибәрсәнә, мин гади балык түгел, тылсымлы принц»,— дип ялынды. Шуннан соң кире суга җибәрдем мин аны, әйдә, рәхәтләнеп йөзә бирсен диңгездә,— дип җавап биргән балыкчы.

— Үзеннән берни дә сорамадыңмыни? — дигән хатыны.

— Юк,— дигән ире,— ә нәрсә сорарга кирәк иде соң?

— Юләр дә инде син,— дигән хатыны,— хәерче алачыгында яшибез ләбаса: ни һавасы сасы, ни утырырга идәне юк. Юньлерәк бер өй сорарга иде ичмасам. Бар, хәзер үк диңгез буена йөгер, тизрәк тылсымлы камбаланы чакырып ал. Гозереңне әйт үзенә, үтенечеңне мөгаен кире какмас.

— Ай-һай,— дигән балыкчы,— тагын диңгез буена бар дисең инде, ә?

— Ах, җебегән! — дигән хатыны.— Тоткан балыкны кем кире җибәрә инде? Җәтрәк атла да соравыңны бел инде хәзер. Бар, юлыңа ак җәймә!

Бер дә аягы тартмаган балыкчының өйдән чыгып китәргә. Әмма хатынына каршы әйтергә дә йөрәге җитмәгән, тагын киткән диңгез буена.

Килеп баскан балыкчы яр буена, ә диңгез яшькелтсоры төскә кергән, кара-кучкылланып дулкынлана башлаган, элеккеге матур җемелдәвенең эзе дә калмаган, ди.

Яр буена ук килеп баскан да балыкчы болай дип такмаклаган:

> — Әй, син, дәрья солтаны Диңгизир,
> Камбалакай, тыңлачы сүземне.
> Әйтмәс идем — хатыным Илзәбил
> Ирексезләп җибәрде үземне.

Камбала яр буена йөзеп килгән дә:

— Йә, нәрсә тели соң хатының? — дигән.

— Әй,— дигән балыкчы,— сине тотуым турында сөйләгән идем, берәр нәрсә сорамадыңмы, ди. Бу хәерче алачыгында яшисем килми, әйбәт өйдә торырга телим, ди.

— Ярар, бар, кайт,— дигән камбала,— теләгәне булыр.

Кайтып керсә, үз күзләренә үзе ышанмаган балыкчы.

Ишелергә торган иске алачык урынында өр-яңа бик әйбәт йорт пәйда булган, ә хатыны капка төбендәге эскәмиядә аны көтеп утыра, ди.

— Әйдә, яңа өйгә керик әле. Менә кара, монда барысы да нинди әйбәт,— дигән ул.

Өйгә керсәләр, аның эче чынлап та алачыкныкына бер дә охшамаган: алгы бүлмәсе дә матур, ди, түр бүлмәсе инде бигрәк тә пөхтәләп җыештырылган, ди, караватларда өр-яңа чыбылдыклар, күпереп торган мамык мендәрләр дә юрганнар, ди. Иркен болдыры, аш бүлмәсе дә бар, ди. Стеналарга матур-матур шүрлекләр элеңгән, ә аларга нинди генә савыт-саба тезеп куелмаган: бакыры дисеңме, җизе дисеңме — җаның ниндиен тели, һәммәсе дә бар, ди. Өй артына җыйнак кына каралты-кура салынган, аның тирәсендә тавык-чебеш кытаклап, үрдәк-казлар каңгылдашып, бакылдашып йөри, ди. Йорт тирәсендәге бакчада төрле-төрле җиләк-җимеш, яшелчәләр үсеп утыра, ди. Хатын иренә:

— Менә күрдеңме инде, мәшәкатьләнүең бушка булмады бит! — дигән, ди.

— Әйе,— дигән балыкчы,— хәзер инде мохтаҗлыкның ни икәнен дә белми тыныч кына яшәргә дә була.

Хатын, серле генә итеп:

— Анысын күз күрер әле,— дигән, ди.

Тәмләп кенә ашаганнар-эчкәннәр дә йокларга ятканнар, ди, болар. Бер атна үтеп китсән шулай, ике атна. Менә хатыны беркөнне балыкчыга:

— Кара әле, атасы, өебез бик кысан — борылырлык чама да юк. Ишегалдыбыз да тар, әйләнерлек-тулганырлык җире дә юк, бакчабыз да кечкенә — иркенләп йөреп тә булмый. Камбала безгә йорт-җирнең зуррагын, әйбәтрәген дә бирә алыр иде. Кыскасы, иркен ташпулатта яшисем килә минем. Бар әле, сора әле шуңардан,— дигән.

— Әй, хатын, хатын,— дигән, ди, балыкчы,— бу өебез дә бик әйбәт ич инде, ташпулат нәрсәгә инде безгә?

— Син нәрсә беләсең соң? — дигән хатыны.— Тизрәк балыгың янына бар да соравыңны кара, калганы синең эш түгел.

— Яңадан камбала янына барырга тамчы да теләгем юк,— дигән балыкчы,— әле генә нинди әйбәт йорт бүләк итте, һаман-һаман йөдәтеп йөрсәң, ачуы да чыгар.

— Күп сөйләнеп торма,— дигән хатыны,— камбаланың кодрәте аңа гына җитә, үтенечеңне бик шатланып үтәр.

Барасы килмәгән балыкчының, күңелен шомлы уй-

лар баскан, эченнән, болай бер дә әйбәт түгел инде, дип сөйләнгән, шулай да киткән бу камбала янына.

Яр буена килеп җитсә, диңгез ачулы дулкынлана, кара-кучкылланып үкерә, электәге ачык-зәңгәр төсенең әсәре дә юк, ди. Әмма бераздан ул тынып калган, шул чак балыкчы су буена ук төшеп:

— Әй, син, дәрья солтаны Диңгизир,
Камбалакай, тыңлачы сүземне.
Әйтмәс идем,— хатыным Илзәбил
Ирексезләп җибәрде үземне,—

дип эндәшкән, ди.

Яр буена йөзеп килгән камбала:

— Йә, хатының тагын нәрсә тели? — дип сораган, ди.

— Әй, шул карчыкны! — дигән балыкчы, уңайсызланып.— Хәзер инде ул кечкенә өйдә түгел, зур ташпулатта яшәргә телим, ди.

— Ярар, тынычлан, кайт өеңә,— дигән камбала,— хатының сине, әнә, ташпулат болдырында көтеп утыра инде.

Балыкчы ышанырга да, ышанмаска да белми икән. Берзаман башын күтәреп караса, баягы өй урынында зур ташпулат калкып тора, аның болдыр баскычына чыннан да хатыны чыгып баскан, ди. Ирен җитәкләп алган да:

— Әйдә, керик, күрик әле ташпулатыбызны,— дигән, ди.

Сарайның эченә кергәч, балыкчы хәйран калган. Бүлмәләрнең идәннәре мәрмәрдән, ди, теләкләреңне үтәргә әзер булып адым саен хезмәтчеләр тора, килеп җитүеңә зур-зур ишекләрне ачып җибәрәләр, ди. Стеналарга төшерелгән искиткеч матур бизәкләр, ялт-йолт килеп, нур сибәләр, ди. Бүлмәләрдә саф алтыннан урындыклар, өстәлләр тезелгән, түшәмнәргә бәллүр кәндилләр эленгән, идәннәргә кыйммәтле паласлар, келәмнәр җәелгән, ди. Ә өстәлләрдә тәмле-тәмле ризыкларның, кыйммәтле шәрабләрнең исәбе-хисабы юк, кашык куярлык та урын таба торган түгел, ди. Сарай артында зур-зур терлектуар абзарлары, каралтылар, ишегалдында әйбәт тарантаслар, затлы фаэтоннар тезелгән, ди. Ташпулат тирәсендә зур гына бакча, анда искиткеч матур чәчәкләр, җиләк-җимеш куаклары үсеп утыра, ди. Бу бакчага тоташып киткән паркның озынлыгы чакрымнан да артык булып, анда боланнар, газәлләр, куяннар, тагын бүтән киекләр йөгерешеп йөри, ди. Кыскасы, яңа биләмәдә җаның ни тели, шул бар, ди.

— Йә,— дигән хатыны,— сиңа ошыймы болар?

— Әйе, әйе,— дигән, ди, ире сокланып,— барысы да бик әйбәт. Рәхәтебезнең кадерен белеп, барына канәгать кылып шушы мәһабәт ташпулатта озак гомер итәргә язсын инде безгә.

— Озак туры килерме, уйлашырбыз әле, киңәшербез соңыннан,— дигән хатын.

Ашаганнар-эчкәннәр дә йокларга ятканнар болар. Иртәгесен хатын таң беленә башлаганда ук йокысыннан уянган, ди. Ята, ди, бу караватында байларча, тирә-яктагы хозурлыкны күзәтә, ди. Ире йоклый икән әле. Хатын терсәге белән төрткәләп аны уяткан да:

— Тор әле, атасы, тәрәзәгә күз сал әле. Шушы мәмләкәтнең короле булсак, дөньяларыбыз тагын да түгәрәкләнә төшәр иде сыман. Бар әле камбалаң янына, король булырга телибез, диген әле!

— Куйчы, хатын,— дигән балыкчы,— безгә король булу нәрсәгә инде? Юк, юк, бер дә король буласым килми.

— Синең килмәсә, минем килә,— дигән хатын.— Тизрәк бар да әйт балыгыңа: хатыным король булырга кызыга, диген.

— Ташласана, хатын, сиңа король булу нәрсәгә хаҗәт? Бу хакта авыз ачарга да кыймыйм мин,— дигән балыкчы.

— Кара әле моны,— дип ачуланган хатын,— тиз бул диләр ич сиңа. Башымны катырма, король буласым килә минем, бетте-китте!

Нишләсен, бик уңайсызланса да, балыкчы диңгез буена теркелдәргә мәҗбүр булган. Үзе, юлда барганда, аңа король булу нигә инде, дип уйлана икән. Һич тә ярый торган эш түгел бу, ай-һай, бер дә ярый торган эш түгел, дип кабатлый, ди.

Су буена килеп җиткәч, бичара карт курка калган: диңгез ярсынып шаулый, тау-тау дулкыннар бер-бер артлы ишелеп киләләр дә ярга ташланалар, аннары ухылдап кире тәгәриләр икән.

Балыкчы кыяр-кыймас кына килгән дә:

— Әй, син, дәрья солтаны Диңгизир,
Камбалакай, тыңлачы сүземне.
Әйтмәс идем, хатыным Илзәбил
Ирексезләп җибәрде үземне,—

дип такмаклаган, ди.

Тылсымлы балык шунда ук яр читенә килеп җиткән:

— Йә, хатының тагын нәрсә тели? — дип сораган.

— У-у-уф,— дигән, ди, балыкчы,— король булырга тели ул хәзер.

— Ярар, тынычлан, кайт өеңә, барлык теләкләрегез дә үтәлер,— дигән, ди, камбала.

Балыкчы өенә кайтса, хәйран калган: сарай тагын да зурая төшкән, ди, манаралары да биегрәк, ди, аларның бизәлеше дә матуррак, ди. Капка төбендә бер төркем сакчы, әллә нихәтле солдат быргылар кычкыртып, барабан кагып, дөнья яңгырата, ди.

Балыкчы сарайга килеп кергән. Караса, бөтен җирдә алтын да көмеш, идәннәрдә, стеналарда бәрхеттән тукылган келәмнәр, ди. Балыкчы килгән уңайга бер зур ишек ачылып киткән. Ул залда бөтен сарай әһелләре җыелган, ди. Саф алтыннан эшләнгән, кыйммәтле асылташлар белән бизәлгән биек тәхеттә, башына зур алтын таҗ киеп, кулына саф алтыннан коелган, асылташлар белән бизәлгән таяк тотып, хатыны утыра, ди. Аның ике ягына да берсеннән-берсе матуррак алтышар кыз тезелешеп баскан, ди.

Балыкчы, тәхет янына килеп, хатынына:

— Әллә король дә булгансың инде? — дигән, ди.

— Күрмисеңмени, булдым шул,— дигән, ди, хатын.

Балыкчы беравык ни әйтергә дә белми аптырап торган, аннары тәхет тирәли әйләнеп чыккан да:

— Анасы, сиңа бу дөньяда моннан артык дәрәҗә юктыр инде, хәзер сиңа бүтән берни дә кирәкмидер инде? — дип әйткән, ди.

Хатынның күңелен ниндидер билгесез бер шомлы хис көйдереп алгандай булган, ди.

— Юк, король булу күңелсез икән, тәмам туйдым, бүтән түзәр хәлем калмады. Яңадан камбалаң янына бар да, хатыным король булудан туйды, император булырга тели, диген.

— Син нәрсә, хатын? — дигән балыкчы,— император булу нигә хаҗәт инде тагын?

— Тизрәк кыймылда! Камбалаңа теләгемне белдер, калганы синең эш түгел,— дигән хатыны, түземсезләнеп.

— Ай-һай, хатын,— дигән балыкчы,— сине император итә алмас ул, бу хакта үтенергә дә оялам. Император ничәмә-ничә илгә бер генә бит ул. Юк, император итә алмас сине камбала.

— Нәрсә? — дигән хатын, ачуланып. — Мин — король, ә син минем ирем генә. Исән-имин чагыңда яхшылык белән барасыңмы, юкмы? Мине король итә алган

тылсым иясе император да итә ала. Тизрәк кыймылдадиләр ич сиңа. Аһ, император буласым килә, император!

Нишләсен, яңадан теркелдәргә туры килгән бичара балыкчыга. Диңгез буена килеп җиткәч тә: «Эшләр яманга китте ич әле. Чама дигән нәрсә дә юк бит үзендә, император буласы килә имеш, оятсыз. Тора-бара камбала да туяр мондый комсыздан»,— дип, бер мәл шомланып, тылсым иясен чакырырга базмый торган, ди.

Ә бу вакыт диңгез бигрәк тә ачулы күренгән. Тирәюнь караңгыланган, дәрья күбекләнә-күбекләнә төбенә кадәр актарылган, тау-тау дулкыннар чабыша, дулап җил ыжгыра, ди. Балыкчы куркуыннан өнсез калган. Шулай да яр буена килгәч, үтенечен кабатламый булдыра алмаган. Тагын:

— Әй, син, дәрья солтаны Диңгизир,
Камбалакай, тыңлачы сүземне.
Әйтмәс идем, хатыным Илзәбил
Ирексезләп җибәрде үземне,—

дигән.

Яр буена йөзеп килгән тылсымлы диңгез принцы:

— Йә, хатының тагын нәрсә тели? — дип сораган, ди.

— И-и-их! — дигән балыкчы авыр сулап.— Хатыным хәзер, император буласым килә, дип, тынгы бирми.

— Ярар, тынычлан, кайт өеңә, теләгенә ирешер ул,— дигән балык.

Балыкчы өенә кайтса, үз күзләренә үзе ышанмый, ди. Сарайның бөтен стеналары шомартылган мәрмәрдән. Бар җирдә матур-матур сыннар тора, кая карама, алтын бизәкләр, ди. Капка алдында солдатлар марш басарга өйрәнә, берөзлексез быргы кычкырталар, барабан кагалар, ди. Ә сарайда император хатын алдында корольләр, герцоглар, графлар, бароннар, дворяннар, кара халык сыман, бөтерелепме бөтереләләр, ди. Хатын кузгалуга, йөгереп барып ишекләрне ачалар, ди, ә ишекләре барысы да алтыннан, ди.

Балыкчы менә шул зур залга килеп керсә, хатыны саф алтыннан коелган тәхеттә утыра икән. Тәхетнең биеклеге өч чакрымга җитәрлек, ди. Император башына зур алтын таҗ кигән, асылташлар белән бизәлгән ул таҗның биеклеге өч аршын икән, ди. Хатын бер кулына алтыннан коелган чукмар башлы император таягы тоткан, ди. Тәхет тирәли икешәр саф булып императорның җан сакчылары тезелешкәннәр, ди. Алар берсеннән-берсе мәһабәтләр, пәһлеван кебекләр, ди. Өч чакрым буйлы пәһлеваннан алып чәнти бармак зурлыгындагы кәрләгә

кадәр саф-саф булып басканнар, ди. Хатын алдында князьләр дә герцоглар бил бөгеп торалар, ди.

Балыкчы тәхет янынарак килгән дә:

— Ай-яй, анасы, император да булгансың икән! — дигән, ди.

— Әйе, император да булдым шул,— дип җавап биргән хатыны эре генә.

Балыкчы беравык ни дияргә дә белми хәйран калып хатынына карап торган, аның шундый дәрәҗәгә күтәрелүенә сокланган. Торган-торган да, тагын бер карап алып:

— Йа, хода, император булгач, бигрәк матурлангансың син, анасы,— дигән.

— Йә, нәрсә чекрәеп торасың? — дип кычкырган аңа хатыны. — Әйе, император мин. Ләкин бүгеннән үк Рим папасы булырга телим. Тизрәк камбалаң янына бар да теләгемне ирештер.

— Син нәрсә, анасы,— дигән балыкчы, аптырап,— нинди бетмәгән нәфес инде ул? Ничек итеп Рим папасы буласың ди инде?! Папа бөтен христиан өммәтенә бер генә бит ул. Юк, бу теләгеңне тылсымлы балык та үти алмаячак.

— Ишетсен колагың,— дигән хатыны, ачуланып,— бүгеннән Рим папасы булырга телим. Бетте-китте! Камбалаң янына бар да: хатынымның бүгеннән үк папа буласы килә, диген.

Ире тагын:

— Юк, анасы, бу турыда балыкка авыз ачарга да куркам. Юк, юк, болай килешми дә, ярамый да. Камбала берничек тә сине папа итә алмаячак,— дип карышып караган.

— Син әле миңа каршы сөйләргә дә җөрьәт итәсеңмени? — дигән хатыны.— Император итә алган икән, Рим папасы да итәр. Баруыңны бел дә әйтүеңне кара. Минем — император, үзеңнең нибары бер балыкчы гына икәнлегеңне оныттыңмы әллә? Яхшылык белән барасыңмы, я булмаса?..

Өреккән балыкчы, теләмәсә дә киткән диңгез буена, тик, шомлы уйлардан, тез аслары дер-дер калтыраудан интегеп, көчкә-көчкә генә атлый икән, ди.

Шул вакыт бар дөньяны давыл каплаган, күктә кап-кара болытлар агыла башлаган, кояш баешы ягы дөм караңгылыкка чумган, ди. Агач ботаклары сынган, яфраклары коелган, диңгез ярсый-ярсый кайнаган, тау-тау дулкыннар ухылдап, шапылдап ярга килеп бәрелгәннәр, ди. Давыл диңгездәге корабларны йомычкадай чөя-чөя

әле бер якка, әле икенче якка алып сылаган, ди. Баш түбәсендә күк йөзе бераз гына зәңгәрләнеп күренсә дә, көн ягындагы офык, туфан алдыннан булгандагы кебек, карасу-кызгылт төскә кергән, ди.

Балыкчы диңгез ярына килеп баскан да куркуыннан калтырана-калтырана:

— Әй, син, дәрья солтаны Диңгизир,
Камбалакай, тыңлачы сүземне.
Әйтмәс идем, хатыным Илзәбил
Ирексезләп җибәрде үземне,—

дип такмаклаган, ди.

— Йә, хатының тагын нәрсә тели? — дип сораган камбала.

— У-у-уф! — дигән балыкчы,— тәмам котырды хатыным, хәзер инде Рим папасы буласы килә.

— Ярар, тынычлан, кайт өеңә, ул дигәнчә булыр,— дигән, ди, балык.

Балыкчы кайтса, ни күрсен: өе урынында сарайлар белән уратып алынган зур чиркәү тора, ди. Аның алдындагы мәйданга халык килеп тулган, балыкчы чиркәүгә көчкә-көчкә генә керә алган, ди. Чиркәү эчендәге күренеш тагын да таң калырлыграк — алтын-көмеш шәмдәлләрдә меңләгән, йөз меңләгән шәм янып тора, ди. Балыкчы хатыны, парчага төренеп, зур-зур өч алтын таҗ киеп, күкләргә тиярлек биек тәхеттә утыра, ди. Тирә-ягында дин әһелләре кайнаша, ди. Тәхетнең ике ягында да саф-саф булып шәмнәр янып тора, аларның иң олысы биек манара сыман озын, юан икән, ди, иң нәние исә күзгә дә күренмәслек кечкенә, ди. Дөньядагы бөтен корольләр, бөтен христиан патшалары папа алдына тезләнгәннәр дә аның туфлиен үбәләр, ди.

Балыкчы исе китеп карап торган-торган да:

— Күрәм, анасы, син папа да булгансың икән! — дип әйткән, ди.

Хатыны горур гына:

— Әйе, булдым шул,— дип җавап биргән, ди.

Балыкчы хәйран калып хатынына бакканда үзен күз нурын ала торган кояшка караган шикелле хис иткән, ди. Тагын бер тапкыр хатынына төбәлгәч, балыкчы:

— Әт-тә-тә, анасы, папа булу сиңа килешкән ләбаса! — дигән, ди.

Ә хатыны ире каршында уклау йоткан кебек селкенми дә, кыймылдамый да утыра икән.

— Йә, анасы, күңелең тынычландымы инде? Папа да булдың менә, бу фани дөньяда шуннан да артыграк дәрәҗә юк ич инде! — дип янә эндәшкән аңа ире.

— Яшәп карыйк әле, аннары күз күрер,— дип җавап биргән, ди, хатыны.

Шуннан соң йокларга ятканнар болар. Ләкин хатын һаман да тормышыннан канәгать түгел, ди, комсыз нәфесе аңа әле дә булса йокларга ирек бирми, ди. Миннән өстенрәк тагын кем бар икән? дип уйланып ята, ди. Ә ире, бөтен дөньясын онытып, рәхәтләнеп изрәгән дә киткән. Көне буе ары-бире чаба-чаба тәмам хәлдән тайган булган, күрәсең. Яңа пешеп чыккан папа исә әле бер ягына, әле икенче ягына боргаланып яткан, тагын нәрсә сорыйм икән, ничек итеп пападан да өстенрәк булырга икән, дип баш ваткан. Төне буе шулай боргаланып ятса да, төпле генә бер фикергә килә алмаган, ди.

Бүлмәгә иртәнге таң нурлары төшкәч, караватъ читенә үк килеп яткан да кояш чыгуын тәрәзәдән күзәтә башлаган, ди, хатын. Аннары башына: ай белән кояшка хуҗа булу ярар иде, теләгән чакта чыгарасың, теләмәгәндә — юк, дигән уй килгән, ди. Шундук терсәге белән кабыргасына төртеп ирен уяткан да әйткән:

— Син нәрсә йоклыйсың да йоклыйсың? Тиз генә тор да камбалаң янына элдерт әле. Хатынымның алла буласы килә, диген!

Балыкчы йокы аралаш хатынының сәер сүзләрен ишеткәч бик-бик курыккан, сискәнеп караватыннан ук егылып төшкән. Күзләрен уа-уа, ялгыш ишеткәнмендер, мөгаен, дип уйлаган бичара. Шулай да хатынына:

— Син шулай сөйләнәсеңме, анасы, әллә мин төш күрәмме? — дигән, ди.

Хатыны, җенләнеп:

— Ай-кояшка кодрәтем җитми икән ләбаса, ничек чыкканнарын, ничек батканнарын гына карап торам. Шуларга хуҗа булмыйча, җаным барыбер тынычлана алмаячак. Күз ачып йомганчы диңгез буена барып җит тә камбалаңа алла булырга теләвемне ирештер,— дигән.

Аннары иренә шундый усал итеп акаеп караган, ди, тегесенең шүрләвеннән җаны чыга язган, ди. Шулай да бераздан йөрәкләнеп, хатыны алдына тезләнгән дә:

— Анасы, зинһар, дим, акылыңа килсәнә,— дип ялвара башлаган.— Император итә алды камбала үзеңне, папа да итте, ләкин алла итәргә аның инде кодрәтеннән килмәячәк. Папа булып калсаң да бик җиткән ич инде. Зинһар, акылыңа килсәнә!

Хатынның моңа җен ачулары чыккан, башындагы чәчләренә кадәр үрә торган, ди. Иренә аяк тибеп:

— Әле каршы әйтергә батырчылык итәсеңмени?

Сабырлыгымны җуйдырма: яхшылык белән барасыңмы, юкмы? — дип кычкырган, ди.

Балыкчы мескен нишләсен инде, җәһәт кенә сикереп торган да, җилдән дә җитезрәк булып, диңгез буена йөгергән. Килеп җитсә, ни күрсен: монда аяктан егарлык өермәле давыл котыра, зур-зур йортлар җимерелә, колач җитмәс юан-юан агачлар төпләре-тамырлары белән йолкынып җиргә ава, кыя-ташлар убылып диңгезгә очып төшә, күк йөзе исә корым яккандай дөм-караңгы, ди. Дөбер-шатыр күк күкри, ялт-йолт яшен яшьни, чиркәү гөмбәзеннән дә биегрәк дулкыннар ишелеп килә, хәтта, болытлардан да ашкан биек тауларның түбәләре ап-ак күбек белән каплана башлаган, ди. Балыкчы бу мәхшәрдән бик курыккан, тик шулай да бөтен гайрәтен җыеп:

— Әй, син, дәрья солтаны Диңгизир,
Камбалакай, тыңлачы сүземне.
Әйтмәс идем, хатыным Йлзәбил
Ирексезләп җибәрде үземне,—

дип такмаклаган, ди.

Бик каты кычкырып такмакласа да, үз тавышы үзенә дә ишетелмәгән, ди. Әмма нинди тылсым аркасында сизгәндер, диңгез принцы яр буена йөзеп килеп:

— Йә, хатының тагын нәрсә тели? — дип сораган, ди.

Балыкчы, телен көчкә әйләндереп:

— У-у-уф! Ул тинтәкнең хәзер алла буласы килә,— дигән.

Камбала:

— Алайса, бар, кайт инде өеңә, хатының да, әнә, хәерче алачыгы бусагасында көтеп утыра үзеңне,— дигән дә диңгезгә чумып күздән югалган, ди.

Балыкчы белән аның хатыны әле һаман ишелергә торган шул ук иске алачыкта гомер итәләр, ди.

КАР КЫЗЫ

Кыш урталарында булган, ди, бу хәл. Күктән каз мамыгыдай кар бөртекләре явып тора икән. Карагач рамлы тәрәзә янында король хатыны нәрсәдер тегеп утыра, ди. Мамыктай ап-ак бөртекләргә карап уйга талганлыктан, король хатынының кулына энәсе кадалган да кар өстенә өч тамчы алсу каны тамган, ди. Ак кар өстендәге алсу тамчылар бик матур булып күренгән. Хатын: «Кардай ак тәнле, кандай алсу йөзле, шомырттай

кара чәчле бала тапсам, нинди бәхетле булыр идем», дип хыяллана башлаган.

Көннәр әкрен генә уза торган. Король хатыны беркөнне нәни генә бер кыз бала тапкан. Кардай ак тәнле, кандай алсу йөзле, шомырттай кара чәчле булганга, аңа Кар кызы дип исем кушканнар.

Хатын үзе, баласын тапкач, аякка баса алмаган, үлеп киткән. Бер ел узгач, король тагын өйләнгән. Аның яшь хатыны бик чибәр, әмма бик тәкәббер, көнче булган, ди. Матурлыкта кемнең дә үзеннән өстен чыгуын кичерә алмаган, ди. Чибәркәйнең сихерле көзгесе бар икән, үзенең шунда чагылган буй-сынына соклана-соклана:

— Син, көзгекәй, әйт бер сүз, яле:
Илдә кем гүзәлләр гүзәле? —

дип сорый икән.

Көзге аңа:

— Галиҗәнап ханым, дөньяда иң гүзәл кеше син генә! — дип җавап бирә икән.

Яшь хатын моңа бик канәгать була, чөнки көзгенең һәрвакыт бары тик турысын гына әйтүен яхшы белә.

Кар кызы да үскән саен чибәрләнә барган. Җиде яше тулганда бер бите айга, бер бите кояшка охшап, үги анасыннан да матуррак булып киткән, ди. Шулай беркөнне яшь хатын үзенең сихерле көзгесеннән:

— Син, көзгекәй, әйт бер сүз, яле:
Илдә кем гүзәлләр гүзәле? —

дип сораган, ди.

Бу юлы көзге:

— Галиҗәнап ханым, син бик чибәр,
Тик Кар кызын матуррак, диләр,—

дип җавап биргән, ди.

Көнче хатын ярсуыннан калтыранырга тотынган, гарьлегеннән яшелле-күкле булган, ди. Шул минуттан алып, Кар кызын күрде исә, аның бәгырьләре өзгәләнә икән. Күңелендәге көнчелек, тәкәбберлек хисләре чүп үләнедәй котырынып үсә башлаган, җаны көндез дә, төнлә дә тынгылык таба алмаган, ди. Тора-бара түзәр хәле калмаган, ди, моның, аучыларыннан берәүне чакырып алган да:

— Шул үксезне урманга алып бар да бүтән күземә күренмәслек ит... Үпкәсе белән бавырын миңа алып кайтып бирерсең! — дигән, ди.

Аучы король хатынының боерыгына каршы килә алмаган, Кар кызын урманга алып киткән. Үзенең ау пычагын алган да гөнаһсыз кызның йөрәгенә кадарга җыенган. Шул чак кыз, елый-елый:

— Әй, мәрхәмәтле абзыкай, ятим баланы үтермәсәнә, мин гел шушы карурманда гына яшәр идем, беркайчан да өйгә кайтмас идем,— дип, аучыга ялвара башлаган, ди.

Кызыкайның матурлыгына, ягымлылыгына хәйран калып торган да, күңеле йомшап:

— Ярар инде алайса, йөгер, мескенкәем,— дигән аучы.

Үзе эченнән генә, барыбер ерткычлар тотып ботарлаячак инде аны, дип уйлаган. Шулай да, үз кулы белән үтермәгәч, өстеннән авыр бер йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйган. Аннары шул тирәдән чабып барган бер боланны тотып суйган да, кызны үтерүен раслар өчен, малкайның үпкә-бавырын көнче король хатынына алып кайтып биргән. Явыз хатын үпкә-бавырны пешерткән дә, Кар кызыныкы дип, бик тәмләп ашаган, ди.

Кар кызы исә япа-ялгызы карурман уртасында калгач бик курыккан, нишләргә дә белмичә тирә-ягына каранган, агач яфраклары шыбырдауга да сискәнеп киткән, ди. Аннары, кая икәнен белмәсә дә, йөгерә башлаган: очлы ташларга басып, чәнечкеле куаклар арасыннан чаба да чаба, юлында очраган ерткыч җанварларның берсе дә аңа тими икән, ди. Аягында басып тора алмаслык хәлгә килгәнче йөгергән кыз. Инде эңгер-меңгер дә төшкән. Шул чак Кар кызы карурман уртасындагы аланда кечкенә генә бер йорт күреп алган да, азрак ял итеп алырмын дип, шунда юнәлгән, ди.

Өй эчендәге бар әйбер дә кеп-кечкенә, ди, әмма алар шулхәтле матурлар, шулхәтле чисталар, тел белән сөйләп, сүз белән аңлатып бирерлек түгел икән, ди. Бүлмә уртасында ап-ак эскәтер ябылган өстәл тора, ди, ә өстәлдә җиде нәни тәлинкә, һәр тәлинкә янында нәни генә кашык, нәни пычак, нәни чәнечке, нәни бокал тора, ди. Стена буенда бер-берсенә терәп куелган җиде кечкенә караватлар булып, аларның һәркайсына кардай ап-ак япма ябылган, ди.

Кар кызы бик нык ачыккан, сусаган икән, һәр тәлинкәдән аз-азлап ипи, җимеш алып капкан, һәр бокалдан берәр тамчы ширбәт эчкән, чөнки, берсеннән генә сыйлансам, комагайлыгым беленер, дип уйлаган. Кызыкай бик нык арыган да икән, караватларның берсенә менеп, бераз ял итәргә җыенган, тик аларның яраклы-

сын таба алмый аптыраган: кайсы артык зур, кайсы, киресенчә, бик кечкенә икән. Әмма җиденчесе таман булып чыккан. Кар кызы шунысына менеп яткан да, алдагысын күз күрер әле дип, изелеп йоклап та киткән.

Тәмам караңгы төшкәч кенә йортның хуҗалары кайтып кергән, ди. Тау казып тимер чыгаручы җиде кәрлә икән, ди, болар. Җидесе дә үзенең кеп-кечкенә лампасын кабызгач, өй эче гөлт итеп яктырып киткән.

Кайбер әйберләре иртән үзләре куеп калдырганча тормаганлыктан, кәрләләр аптырашка төшкәннәр. Аларга өйдә кемдер булган сыман күренгән. Шул чак кәрләләрнең берсе:

— Минем урындыгыма кем утырды? — дип кычкырып җибәргән, ди.

Икенчесе:

— Тәлинкәмдәге ашыма кем кашык тыкты икән? — дигән, ди.

Өченчесе:

— Ә минем ипине кем тешләп алган? — дип сүзгә кушылган, ди.

Дүртенчесе:

— Ә минем яшелчә-җимешләремне кем ашаган икән? — дип гаҗәпләнгән.

Бишенче кәрлә дә:

— Чәнечкеләремә кем кагылган соң? — дип ризасызлык белдергән.

Алтынчысы:

— Минем пычагыма кайсыгыз орынды? — дигән.

Җиденче кәрлә:

— Ә кем минем ширбәтне эчкән икән? — дип сораган.

Шуннан соң кәрләләрнең беренчесе як-ягына каранган да, караватындагы япмасының бераз бөгәрләнгәнен күреп:

— Минем урында кем аунады икән? — дип сораган.

Бүтән кәрләләр дә караватлары янына йөгерешеп килеп:

— Минем караватта да кемдер яткан.

— Минем түшәгем дә бөгәрләнгән.

— Минеке дә...— дип шаулаша башлаганнар.

Җиденче кәрлә, ятагы янына килүгә, караватында йоклап яткан Кар кызын күреп алган да иптәшләрен үз янына чакырган. Барысы да, аның тирәсенә җыелып, гаҗәпләнүләреннән кычкырып ук җибәргәннәр, ди. Җидесе дә лампасын алып килеп, ут яктысында Кар кызын күзәтә башлаганнар.

— Йа, алла! Йа, хода! — дип сокланганнар, ди, кәрләләр.— Карасана, нинди чибәр кыз!

Алар кызыкайны күреп шулкадәр куанганнар, ди, чакырылмаган кунакны уятырга да кыймаганнар, «Әйдә, йокласын инде!» — дигәннәр, ди. Җиденче кәрлә исә һәр иптәше янында берәр сәгать йоклап алган, шулай итеп төн узганын да сизмәгән, ди.

Иртән йокысыннан уянгач, җиде кәрләне күреп, Кар кызы бик курыккан, ләкин кәрләләр аңа бик ягымлы булганнар, җайлап кына:

— Ни исемле син? — дип сораганнар.

— Кар кызы,— дип җавап биргән кунак.

— Безнең өйгә ничек килеп чыктың соң син? — дип кызыксынган кәрләләр.

Кыз хуҗаларга үги әнисенең аны үтерергә теләвен, әмма аучының кызганып исән калдыруын, үзенең көне буе урманда адашып йөрүен, караңгы төшкәндә генә менә шушы өйгә килеп юлыгуын сөйләп биргән. Кәрләләр аңа:

— Өебезне караштырып торырга, ашарга пешерергә, урын-җирләребезне җыештырырга, керләребезне юарга, тегесен-монысын тегәргә-ямарга, кыскасы, барысын да тәртипле-чиста тотарга риза булсаң, безнең янда гына кал, мохтаҗлык, җәбер-фәләм күрмәссең, бергә яшәрбез,— дигәннәр.

Кунак:

— Ярар, мин бик риза,— дигән.

Менә шуннан соң Кар кызы кәрләләр белән яши башлаган. Кәрләләр иртә таңнан торып тау казырга китәләр, көне буе тимер, алтын-фәләм эзлиләр икән. Кызыкай көндез өй җыештырган, кичен, алар кайтыр вакыт җиткәндә, ашарга әзерләп торган.

Шулай әйбәт кенә гомер итә башлаган болар. Хуҗалар бик кайгыртучан кешеләр булып чыккан, көнозын өйдә ялгызы кала торган кызыкайны:

— Үги анаңнан саклана күр. Монда икәнлегеңне аның тиздән белеп алуы ихтимал. Без югында өйгә беркемне дә кертмә,— дип кисәткәннәр.

Үги ана исә Кар кызының үпкә-бавырын ашавына тәмам ышанган, хәзер инде дөньяда беренчеләрнең дә беренчесе, матурларның да матуры мин генә, дип уйлаган, ди. Шулай беркөнне сихерле көзгесе алдына килеп баскан да, янә:

— Син, көзгекәй, әйт бер сүз, яле:
Илдә кем гүзәлләр гүзәле? —

дип сораган, ди.

Көзге бу юлы:

— Галиҗәнап ханым, сарайда
Юктыр сиңа җиткән бер чибәр.
Тик кәрләләр белән бергәләп
Урман аланында яшәүче
Бер Кар кызын матуррак, диләр,—

дип җавап кайтарган.

Тылсымлы көзгенең беркайчан да ялган сөйләмәгәнен белгән көнче хатын акылыннан шаша язган. Димәк, аучы аны алдаган, Кар кызын үтермәгән!

Хәзер инде ул яңадан көне-төне бары тик бер нәрсә — кызны ничек үтерү турында гына хыяллана башлаган. Дөньяда иң матур, иң гүзәл кеше буласы килү теләге тилерткән аны, көнчелек уты йөрәген көйдергән. Уйлый торгач, битен-йөзен газиз анасы да танымаслык итеп буяган да кырык тартмачы хатын булып киенгән бу. Аннары шул кыяфәтендә җиде тау аша үтеп, җиде кәрлә яши торган җиргә килеп җиткән. Аларның өй ишеген шакып:

— Кирәк-ярак сатам! Асыл маллар сатам! — дип кычкырган.

Кар кызы, тәрәзәдән башын тыгып:

— Хәерле көн, әбекәй! Нәрсәләр сатасың соң? — дип сораган.

— Кырык төрле кирәк-ярак, асыл маллар, берсеннән-берсе матур билбаулар,— дип җавап биргән «сәүдәгәр».

Шулай дигән дә капчыгыннан каюлап тегелгән бик матур бер ефәк билбау чыгарган. Кар кызы: «Бу сөйкемле әбине өйгә кертсәм дә ярыйдыр», дип уйлап, ишеген ачкан. Аннары иң матурын сайлап кына үзенә бер билбау сатып алган.

— Бигрәк килешеп тора инде үзеңә, балакаем! Әйдә, әйбәтләп бәйләп тә бирим әле,— дигән сәүдәгәр.

Кар кызы бер дә яманлык-фәлән көтмәгән, карчык алдына килеп баскан да билбавын әйбәтләп бәйләп бирергә кушкан. Карчыкка шул гына кирәк икән, кызыкайның билен шулкадәр кысып бәйләгән, Кар кызы тын да ала алмаган, көлтә кебек идәнгә ауган, ди. Явыз карчык исә:

— Бу сиңа миннән дә матуррак булганың өчен,— дигән дә ашыга-ашыга бүлмәдән чыгып сызган.

Кич җиткән, кәрләләр өйләренә кайтып кергән. Кар кызының сәер бер хәлдә идәндә аунап ятуын күргәч, яман курыкканнар. Кыз тын да алмый, селкенми дә икән, әйтерсең мәңгегә күзен йомган. Идәннән күтәреп

алганда кәрләләр кызның биле ефәк билбау белән бик нык кысып бәйләнүен күргәннәр дә билбауны тиз генә кисеп җибәргәннәр. Кыз әкрен генә сулый башлаган, бераздан тәмам аңына килгән. Кызданниләр булганны сөйләткәннән соң кәрләләр барын да аңлап алганнар.

— Ул хатын кырык тартмачы да, әби дә булмаган, үги анаң шундый кыяфәткә кереп килгән ләбаса. Киләчәктә саграк була күр, без югында өйгә беркемне дә кертмә,— дигәннәр.

Явыз хатын өенә кайту белән яңадан сихерле көзгесе алдына барып баскан.

— Син, көзгекәй, әйт бер сүз, яле:
Илдә кем гүзәлләр гүзәле? —

дигән.

Ә көзге нәкъ баягыча:

— Галиҗәнап ханым, сарайда
Юктыр сиңа җиткән бер чибәр.
Тик кәрләләр белән бергәләп
Урман аланында яшәүче
Бер Кар кызын матуррак, диләр,—

дип җавап биргән.

Бу сүзләрне ишеткәч, явыз хатынның йөрәге шартларга җиткән, җен ачулары чыккан, ди. Кар кызы яңадан терелсен әле!

— Син шулаймыни әле? — дигән ул үртәлеп.— Юк, кинәнергә ашыкма, адәм фетнәсе, үзеңне мәңгегә дөмектерерлек бер әмәл тапмый калмам!

Тырыша торгач, үзе белгән бер сихерчедән күрмәкче, бер агулы тарак ясаган. Аннары икенче бер карчык кыяфәтенә кереп киенгән дә, җиде тау сырты аша үтеп, җиде кәрлә яшәгән әлеге аланга барып җиткән. Таныш ишекне шакый-шакый:

— Кирәк-ярак сатам! Асыл маллар сатам! — дип кычкыра башлаган, ди.

Кар кызы, аны тәрәзәдән күреп:

— Бар, бар, юлыңда бул, бүген берәүне дә өйгә кертмәячәкмен,— дигән.

Карчык:

— Күрсәтергә генә ярыйдыр ич? — дигән дә агулы тарагын чыгарып тәрәзә каршысында уйнаткан. Тарак кызның күңеленә бик хуш килгән, шунлыктан ул бу юлы да алданган — ишеген ачкан. Бәясен килешкәч, карчык:

— Әйдә, чәчеңне бер тапкыр әйбәтләп тарап та бирим инде,— дигән.

Кар кызы, явызлык-яманлык кылыр дип башына да китермәгәнлектән, карчыкка чәчен тарарга ирек биргән. Явыз хатын тарагы белән чәченә кагылуга, агу шунда ук кызыкайның бөтен тәненә таралган, ул шунда ук һушыннан язып идәнгә егылган.

— Йә, гүзәлләрнең гүзәле,— дип көлгән көнче хатын,— дөмектеңме? Бу якты дөньяны бүтән күрә алмассың инде!

Шулай дигән дә ашыгып чыгып киткән. Кызның бәхетенә каршы, тиздән кич җиткән, җиде кәрлә дә өйләренә кайткан. Кар кызының идәндә тагын һушсыз ятуын күргәч, кәрләләр шунда ук явыз үги анадан шикләнгәннәр, берәр эзе калырга тиеш аның, дип эзләнә башлаганнар. Чәчендәге агулы таракны алып ташлаулары булган, Кар кызы әкренләп һушына килгән, бу юлы өйдә нинди-нинди хәлләр булганлыгын сөйләп биргән. Кәрләләр кызны тагын да ныклабрак кисәткәннәр, саграк булырга, берәүгә дә ишек ачмаска кушканнар.

Ә король хатыны янә көзгесе алдына баскан да:

— Син, көзгекәй, әйт бер сүз, яле:
Илдә кем гүзәлләр гүзәле? —

дип сораган.

Көзге исә, нәкъ элеккечә:

— Галиҗәнап ханым, сарайда
Юктыр сиңа җиткән бер чибәр.
Тик кәрләләр белән бергәләп
Урман аланында яшәүче
Бер Кар кызын матуррак, диләр,—

дип җавап биргән.

Көзгенең бу сүзләрен ишеткәч, явыз хатын ярсуыннан калтырана башлаган, тәмам буылыр дәрәҗәгә җиткән. «Кар кызы дөмегергә тиеш, үзем үлсәм үләрмен, тик аны да исән калдырмам»,— дип тузынган.

Шуннан соң әлегә кадәр һичкем аяк басмаган бер аулак бүлмәгә бикләнгән дә, зәһәрдән дә зәһәррәк агулар кушып, бер алма ясаган. Алсу төсенә караганда бик матур, бик тәмле күренгән ул, күз салган кешенең ирексездән ашап карыйсы килерлек, ди, тик аның бер генә телемен капкан кеше дә шунда ук җан бирәчәк икән, ди. Алма әзер булгач, король хатыны танымаслык итеп битләрен буяган, төсен үзгәрткән дә, авылча киенеп, җиде тау сыртын кичеп, җиде кәрлә яши торган урман аланына барып җиткән. Барып җитүгә, ишекләрен шакыган. Кар кызы тәрәзәдән караган да:

— Өйгә беркемне дә кертмәячәкмен, җиде кәрлә мине бик каты кисәтте инде,— дигән.

— Шулаен шулайдыр да бит,— дигән «авыл хатыны»,— мин соң алмаларымны кая илтим икән инде хәзер? Булмаса, берәрсен сиңа бүләк итим әле!

— Кирәкми,— дигән Кар кызы,— ят кешедән бер әйбер дә алмыйм мин.

— Агулы булыр дип шикләнәсеңме әллә? — дигән сатучы хатын,— менә кара алайса, алманы урталай бүләм дә алсуланып торган ягын сиңа бирәм, икенче яртысын үзем ашыйм.

Король хатыны агуны алманың алсуланып торган ягына гына сеңдергән икән. Кар кызының алмага бик тә күңеле төшкән, авыз итеп карыйсы килгән. «Сатучының» алманы рәхәтләнеп ашап торуын күргәч, нәфесен тыя алмаган, тәрәзәдән кулын сузып, алманың агулы яртысын алган. Бер телемен капкан икән, шунда ук һушы китеп идәнгә егылган.

Көнче хатын аңа рәхимсез караш ташлаган да шаркылдап көлеп җибәргән.

— Кардай ак тәнле, кандай алсу йөзле, шомырттай кара чәчле, имеш! Бу юлы сине мәңгелек йокыдан кәрләләрең дә уята алмас инде,— дип сөйләнгән.

Өенә кайткач, яңадан сихерле көзгесе алдына барып баскан да:

— Син, көзгекәй, әйт бер сүз, яле:
Илдә кем гүзәлләр гүзәле? —

дип сораган.

Бу юлы көзге аңа:

— Галиҗәнап ханым, дөньяда иң гүзәл кеше син генә! — дип тансык җавабын биргән, ди.

Шуннан соң шәфкатьсез үги ананың көнче йөрәге, зәһәр йөрәкләр булдыра алганча, тынычланган, ди.

Кичен өйгә кайткач, кәрләләр Кар кызының идәндә җансыз тәгәрәп ятканын күргәннәр. Тын да алмый, күзләре дә йомык, ди. Алар кызны караватка күтәреп салганнар, берәр агулы әйбер зәхмәте түгелме икән тагын дип, тикшерә, эзли башлаганнар. Иснәп тә караганнар, чәчләрен дә тараганнар, су, татлы шәраб йоттырырга да тырышканнар, ләкин аңа бер нәрсә дә ярдәм итмәгән — сөйкемле кызга җан кермәгән, ди. Кәрләләр кызны табутка салганнар да, җидесе дә шуның тирәсенә утырып, өч көн буе елаганнар, ди. Башта кызны кабер казып күмәргә уйлаганнар, ләкин ул һаман исән кешедәй саф, таза күренгән, хәтта битләре дә элеккечә — алма кебек алсу, төсен бер дә үзгәртмәгән, ди. Кәрләләр, шушындый кызны ничек итеп җиргә күмәсең инде, дип

уйлаганнар да, пыяладан табут ясап, Кар кызының гәүдәсен шунда салганнар. Кайсы яктан карасаң да, табут эчендәге гәүдә ап-ачык күренеп тора икән. Табутка алтын хәрефләр белән Кар кызының исемен, король кызы икәнлеген язганнар да якындагы тау башына менгереп куйганнар. Кәрләләрнең берсе табут янында һәрвакыт сакта тора икән. Табут янына төрле-төрле җанварлар, киек кошлар килгән, барысы да Кар кызын кызганып елаганнар, кайгырганнар, ди. Мәче башлы ябалак та, ала карга да, күгәрчен дә хәл белешкән, ди.

Кар кызы озак, бик күп гомерләр шулай табутта яткан, ләкин тамчы да бозылмаган, үзгәрмәгән, ди. Вакытлыча гына йокыга талган сыман, тәне элеккечә кардай ак, йөзе кандай алсу, чәчләре шомырттай чем-кара, ди.

Шулай беркөнне әлеге урманга бер король малае ауга килгән дә куныл чыгарга дип кәрләләр өенә юнәлгән, ди. Юл уңаенда тау башындагы пыяла табутта яткан Кар кызының гәүдәсен дә күргән, алтын хәрефләр белән язылган язуны да укыган. Өйгә кергәч король малае кәрләләрдән:

— Миңа ул табутны биреп җибәрегезче, аның өчен ни генә сорасагыз да, бәхилләтермен,— дип үтенгән, ди.

Кәрләләр:

— Дөньядагы барлык алтын-көмешне вәгъдә итсәң дә бирмибез,— дигәннәр.

Егет янә дә:

— Алайса бүләк итегез. Моннан соң Кар кызын күрмичә яши алмаячакмын. Иң кадерле кешем сыман яратыр, кадерләр идем мин аны,— дип ялынган.

Король малаеның өзгәләнүе кәрләләрнең нечкә күңелен йомшарткан, алар уйлашканнар-уйлашканнар да пыяла табуттагы Кар кызын егеткә бирергә риза булганнар.

Гашыйк егет хезмәтчеләренә табутны җилкәләренә күтәреп сараена алып кайтырга кушкан.

Шулай кайтып барганда хезмәтчеләрнең берсе аяк астындагы бер төпкә абынган да егылып китә язган. Табутның кинәт селкенеп куюыннан Кар кызының авызындагы агулы алма телеме җиргә төшеп киткән. Шуннан соң күп тә үтмәгән, Кар кызы күзләрен ачкан, табутының капкачын күтәреп, торып та утырган.

Торып утыруына:

— Абау, кайда соң әле мин? — дип эндәшкән, ди.

Куанычы эченә сыймаган король малае:

— Минем янымда син,— дигән дә ниләр булганын

кызга бәйнә-бәйнә сөйләп биргән. Аннары: — Син миңа бар нәрсәдән дә кадерлерәк. Әйдә, этием сараена барыйк әле, риза булсаң, алар безне өйләндерерләр, моннан соң бергә-бергә гомер итәрбез,— дигән.

Кар кызы бик шатланып риза булган, король малаена ияреп сарайга киткән. Бик зурлап, дөнья шаулатып туй иткәннәр. Туй мәҗлесенә Кар кызының үги анасын да чакырганнар. Көнче хатын, иң матур, иң затлы күлмәкләрен кигәч, тылсымлы көзгесе алдына барып баскан да тагын:

— Син, көзгекәй, әйт бер сүз, яле:
Илдә кем гүзәлләр гүзәле? —

дип сораган.

Көзге:

Галиҗәнап ханым, син бик чибәр,
Тик ерак бер илнең король улы
Хатынын мең кат матуррак, диләр,—

дип җавап биргән.

Моны ишеткәч явыз хатын бар дөньяны каһәрләргә тотынган. Ул шундый тузынган, шундый көнләшкән, ачуыннан нишләргә дә белмәгән. Башта туй мәҗлесенә барудан да баш тарткан, тик көнчелеге аңа һич кенә дә тынгылык бирмәгән, ни генә булса да, ерактагы король улының яшь кәләшен күрәсе килгән.

Сарайга килеп керү белән, мәрхәмәтсез үги ана Кар кызын танып алган да куркуыннан баскан урынында тораташтай катып калган, авыз ачып бер сүз дә әйтә алмаган, ди.

Сарайда исә аның өчен әзерләнгән тимер туфлине дөрләп торган күмер өстенә «җылытырга» куйган булганнар. Шуларны тимер кыскыч белән каптырып алганнар да явыз хатын алдына китергәннәр, ут булып кызган әнә шул тимер туфлине киеп биергә мәҗбүр иткәннәр. Бии-бии хәлдән таеп идәнгә тәгәрәгәнче, җан биргәнче биеткәннәр, ди, явыз хатынны.

ТЕРЕ СУЫ

Яшәгән, ди, бер король. Бик каты чирләп киткән, ди, бу берзаманны. Аның озак яши алырына ерәү дә ышанмаган, ди. Ә корольнең өч малае булган икән. Этиләре үлем түшәгендә ятуга бик кайгырышканнар алар, сарай бакчасына чыкканнар да өчәүләп елый башлаганнар. Шул чак яннарына бер карт килеп туктаган да ни сәбәп-

тән болай хәсрәтләнүләрен сорашырга керешкән. Малайлар әтиләренең хәле бик авыр булуын, озакламый якты дөнья белән саубуллашуы да ихтимал икәнлеген, аның хәлен җиңеләйтер өчен берни дә эшли алмауларын бик кыенсынып сөйләп биргәннәр. Карт тыңлап-тыңлап торган да малайларга:

— Бер әмәл бар-барын: тере суы табарга кирәк. Шуны эчсә, нинди генә авырудан да кеше шунда ук савыга. Тик аны табуы бик кыен,— дигән.

Олы малай:

— Мин ул суны барыбер табармын,— дигән.

Аннары авыру атасы янына килгән дә тере суы эзләр өчен сәфәр чыгарга хәер-фатиха сораган, «сине дәвалый алырлык бердәнбер дару шул гына»,— дигән.

Ләкин король:

— Бик хәтәр сәфәр икән, улым. Сине андый хәвефле юлга чыгарып җибәргәнче, дөнья куюым хәерлерәк,— дип каршы төшкән.

Улы кат-кат ялынгач, ялваргач, король барыбер хәерфатихасын бирергә мәҗбүр булган, ди. Ә малай эченнән генә, әгәр тере суын алып кайтсам, әти мине энеләремнән артыграк яратыр, үз урынына король итеп калдырыр, дип уйлый икән.

Шундый уйлар белән олы малай сәфәр чыгып киткән. Бара, ди бу, бара, ди, бер заман моңа бер кәрлә очраган, ди.

— Кая шулай ашыгасың? — дип сораган аңардан кәрлә.

Король малае:

— Минә тинтәк, минем кая ашыгуымда синең ни эшең бар? — дигән дә атын чаптырып узып та киткән.

Кәрләнең тәкәббер егеткә бик нык ачуы чыккан, олы малайның авыр казага юлыгуын теләгән.

Король малае, бара торгач, биек таулар арасындагы тарлавыкка килеп кергән. Атлаган саен кыя-таулар берберсенә ныграк якынлаша, юл тарайганнан-тарая бара, ди. Бер заман тарлавык шулкадәр тарайган, алга таба бер генә адым атларлык та әмәл калмаган, ди. Атны кире борырга да, ияр өстеннән төшәргә дә җай юк икән, ди. Шулай итеп, корольнең олы улы таулар арасына кысылып калган. Малае әйләнеп кайтуын авыру король бик озак көткән, тик егет үзе дә күренмәгән, бернинди хәбәре дә килмәгән.

Король янына уртанчы улы кереп:

— Әти, тере суы эзләп кайтырга хәзер инде хәерфатихаңны миңа бир,— дигән.

Үзе эченнән, әгәр абый үлгән булса, король булып мин калыр идем, дип уйлаган.

Башта король уртанчы улын юлга чыгарып җибәрергә риза булмаган, тик егет тәмам аптыраткач кына хәер-фатихасын биргән, ди.

Уртанчы малай да абыйсы барган юлдан киткән, ул да юлында теге кәрләне очраткан. Кәрлә аңардан да, кая болай ашыгасың, дип сораган, ди. Корольнең уртанчы малае да дорфа гына:

— Минә тинтәк, минем кая ашыгуымда синең ни эшең бар? — дигән дә, артына да әйләнеп карамастан, атын чаптырып китеп барган, ди.

Егетнең тупаслыгына кәрләнең бу юлы да бик нык ачуы килгән, аның каргышы уртанчы малайга да төшкән. Ул, абыйсы шикелле үк, биек таулар арасындагы бер тарлавыкка барып кергән дә шуннан ни алга бара, ни кире чыга алмаган, ди. Кәпәренеп йөргән кеше һәрвакыт әнә шундый берәр бәхетсезлеккә юлыга шул ул!

Уртанчысы да әйләнеп кайтмагач, корольнең төпчек улы тере суы эзләп юлга чыгарга хәер-фатиха сораган. Башта карышса да, кат-кат сорагач, король аңа да ризалыгын биргән, ди.

Төпчек малай да юлда теге кәрләне очраткан, ди. Кәрлә аңардан кая шулай ашыгуын сорагач, малай атын туктаткан да ягымлы гына:

— Тере суы эзләргә чыккан идем, әтием авырып үлем түшәгендә ята,— дигән.

— Тере суын кайдан эзләргә икәнен беләсеңме соң? — дип сораган кәрлә.

— Юк шул,— дип җавап биргән төпчек малай.

— Әдәпле егет икәнсең, абыйларың кебек дорфа да, тәкәббер дә түгелсең. Шуңа күрә мин сиңа тере суын кайдан эзләргә кирәклеген өйрәтермен, анда ничек бару юлын да күрсәтермен,— дигән кәрлә.— Тере суы сихерләнгән патшалыктагы бер чишмәдән агып тора. Менә сиңа бер чыбык, янә дә ике бөтен ипи. Шулар булмаса, сарайга үтеп керә алмассың. Чыбык белән сарайның тимер капкасына өч мәртәбә суксаң, ул үзе ачылып китәр. Эчке якта ике зур арыслан ятканын күрерсең. Алар үкерергә дип авызларын ачуга, шушы ипиләрне бир, ерткычлар шундук песидәй тынычланып калыр. Тик син вакытыңны әрәм итмә: тиз генә чишмәгә йөгер, шуннан кирәгенчә су ал. Аннары сәгать уникене сукканчы сарайдан кире чыгып китәргә ашык. Югыйсә сәгать уникене сугу белән капка яңадан ябылачак. Вакы-

тында чыгып өлгерә алмасаң, гомергә шунда бикләнеп калачаксың.

Король малае кәрләгә рәхмәт әйткән дә, ул биргән чыбык белән ике бөтен ипине алып, юлын дәвам иттергән. Сихерле патшалыкка барып җиткәч, барысы да нәкъ кәрлә әйткәнчә булып чыккан. Чыбык белән өч тапкыр сугуы булган, сарай капкасы ачылып киткән, ике ипиен ике арысланга биргән дә, һич каршылыксыз серле биләмәләргә аяк баскан. Монда ул искиткеч матур бик зур бер залга килеп кергән. Караса, сихерләнгән патша малайлары мәрткә киткәннәр, ди. Ул аларның бармакларыннан балдакларын салдырып алган. Шунда ук бер бөтен ипи, ике үткен кылыч ята икән, егет аларны да эләктергән. Йөри торгач, король малае тагын бер бүлмәгә барып кергән. Монысында гаҗәеп матур бер кыз утыра, ди. Кыз, ят кунакны күргәч, йокыдан уянган шикелле булган, бик куанган, хәтта егетне үбеп тә алган, ди.

— Син мине яман сихердән коткардың. Бар байлыгым, бар мөлкәтем хәзер синеке. Әгәр бер ел үткәч яңадан минем янга әйләнеп килсәң, үзем дә синеке булырмын, туй итәрбез,— дип әйткән, ди, кыз.

Аннары кыз егеткә тере суы кайда икәнлеген күрсәткән, сәгать уникене сукканчы капкадан кире чыгып китәргә кирәклеген исенә төшергән.

Король малае сарай буйлап ары киткән. Бара торгач янә бер бүлмәгә барып кергән. Монысында әле генә чипчиста япмалар ябылган, йомшак ястыклар түшәлгән карават тора, ди. Егет юл михнәтләреннән шактый йончыган икән, бераз ял итеп алырга булган. Йомшак урынга менеп яту белән йокыга да киткән. Күпме йоклагандыр, сәгать суккан тавышка гына уянган. Караса, уникे туларга чирек сәгать кенә калган, ди. Куркуга төшкән егет, кабаланып сикереп торган да чишмәгә йөгергән. Шунда очраган бер савытны эләктергән дә тере суын чумырып алган, аннары капкага ыргылган.

Капка турына килеп җиткәндә генә сәгать уникене суккан, ди. Капка шундый каты шартлап ябылган, хәтта король малаеның табаныннан бер кисәк итен дә умырып алган, ди. Шулай да егет кайгырмаган, тере суын табуына бик сөенеп, вакытын әрәм итмәстән, кайтыр юлга чыккан.

Бер заман ул әлеге кәрлә янына да килеп җиткән. Егет кулындагы кылыч белән ипине күргәч, кәрлә:

— Бик зур хәзинәгә ия булгансың бит. Бу кылыч белән теләсә нинди куәтле гаскәрне җиңә аласың. Ипие

дә хикмәтле — күпме генә ашасаң да кимеми,— дип әйткән, ди.

Малайның өйгә, әтисе янына абыйларыннан башка кайтасы килмәгән, кәрләдән:

— И яхшы күңелле зирәк абзыкай, син миңа абыйларымның кайда икәнлеген дә әйтә алмассыңмы икән? Алар тере суы эзләп миңа хәтле үк киткәннәр иде, ләкин нигәдер кире әйләнеп кайтмадылар,— дигән.

— Ике тау арасындагы тарлавыкта бикләнеп калган алар, артык тәкәббер булганнары өчен каргышым төшкәндер,— дигән кәрлә.

Төпчек малай ялынып-ялварып кәрләдән абыйларын азат итүне үтенгән. Бераздан кәрлә риза булган, ләкин:

— Абыйларыңнан саклана күр, күңелләре бозык аларның,— дип кисәткән.

Абыйлары белән кавышкач, төпчек малай бик сөенгән, ди. Аларга күргәннәрен-кичергәннәрен, тере суын ничек табуын, аны бер савыт тутырып алуын, ерак патшалыкта бик чибәр патша кызын сихердән азат итүен, кызның нәкъ бер ел тулганчы көтәргә вәгъдә бирүен, шуннан соң туй итәчәкләрен, тиздән үзенең бай мәмләкәткә патша булачагын сөйләп биргән, ди.

Өчәүләп кайтыр юлга чыкканнар болар. Көн киткәннәр, төн киткәннәр, ди, бервакыт сугыш барган, халык ачлыктан интеккән бер илгә килеп җиткәннәр, ди. Бу илнең короле, инде котылу әмәле калмады, һәлак булачагыбыз көндәй ачык дип, тәмам өметсезлеккә бирелгән, ди. Чөнки илдәге мохтаҗлык соңгы чиккә килеп җиткән, ди. Кече малай король янына килгән дә аңа әлеге хикмәтле ипине биргән, король шуның белән халкын туйдырган, ди. Соңыннан егет хикмәтле кылычын да биреп торган, король аның белән дошманның бөтен гаскәрен кырып ташлаган, ди. Хәзер инде бу илнең халкы имин-тыныч яши башлаган, ди.

Төпчек малай кылычы белән ипиен кире алган да өч агай-эне үз юлларына киткәннәр. Аларга сугыш барган, ачлыктан җәфаланган тагын ике ил аша узарга туры килгән. Икесендә дә төпчек малай ул илләрнең корольләренә үзенең ипие белән кылычын биреп торган, ди. Ул шулай өч мәмләкәтне һәлакәттән коткарган, ди.

Көн киткәннәр болар, төн киткәннәр, бер заман юллары очсыз-кырыйсыз диңгез буена барып чыккан, ди. Корабка утырганнар да йөзеп киткәннәр, ди, болар. Төпчек малай югында абыйлары үзара:

— Тере суын без түгел, ул алып кайта бит. Көт тә

тор, эти аны король дә итәчәк болай булса. Димәк, безгә юралган бәхет тә, тәхет тә аңа эләгәчәк! — диешкәннәр.

Сөйләшә торгач, ике олы туган энеләрен ничек кенә булса да үтерергә сүз куешканнар. Шулай бервакыт, төпчек малай бик каты йокыга киткәч, абыйлары аның савытындагы тере суын үз савытларына бушатканнар да анықына тозлы диңгез суы тутырып куйганнар.

Өйләренә кайтып җиткәч, төпчек малай, тизрәк терелсен дип, савытындагы суны этисенә эчергән. Кырку, тозлы диңгез суын берничә генә йотым эчкән икән, корольнең сырхавы элеккегә караганда да көчәя төшкән. Король зарлана башлагач, янына олы малайлары йөгереп килгән. Алар энеләрен этисен агуларга теләүдә гаепләгәннәр, аннары аңардан урлап алган тере суын этиләренә сузганнар. Тере суын эчү белән корольнең чире дә беткән, ул үзен яшь чагындагы кебек сау-сәламәт итеп тоя башлаган, ди. Абыйлары төпчек малай янына килгәннәр дә мыскыллап көләргә тотынганнар.

— Тере суын син таптың табуын, михнәтләрен дә син күрдең, ә менә әҗере безгә булды. Акылга утыр әле, моннан соң аягүрә йоклап йөрмәссең. Тере суыңны корабта чакта, син дөньяңны онытып йоклап ятканда алыштырдык. Ел гына узсын әле, теге гүзәл кыз да безгә булачак. Тик кара аны, безне сатарга маташма, эти барыбер сиңа ышанмас. Бу хакта бер генә сүз ычкындырсаң да башыңа җитәчәгебезне бик яхшы белеп тор. Әгәр серне ачарга маташмасаң, бәлки мәрхәмәт тә күрсәтербез әле, тимәбез дә үзеңә,— дигәннәр.

Төпчек улына чал корольнең чыннан да ачуы килгән, чөнки аның үзен үтерергә теләвенә ул чынлап та ышанган. Вәзирләрен җыеп киңәшкән дә малаен яшертен генә атып үтерергә әмер биргән.

Шулай беркөнне корольнең төпчек улы ауга чыккан. Нинди дә булса яман эш кылыначагын башына да китермәгән ул. Малай белән бергә корольнең иң оста аучысы да бара икән. Бер заман урманга да килеп җиткәннәр болар. Икәүдән-икәү генә калгач, аучының төсләре качып, кәефсезләнеп торганын күреп, төпчек малай аңардан:

— Нигә бер дә кәефең юк, ни булды сиңа, тугрылыклы аучыкаем? — дип сораган.

Аучы, хәвефләнеп:

— Әйтергә дә кыймыйм инде дә, ләкин башка чарам да юк сыман,— дигән.

Төпчек малай:

— Сөйлә ни булганын, курыкма, юк-бар өчен ачуланмам, бәлки кичерермен дә әле,— дигән.

— Йа, ходa,— дип көрсенгән, ди, аучы,— мин сине атып үтерергә тиеш ич, корольнең әмере шундый.

Король малае бу хәтәр сүзләрне ишеткәч бик-бик курыккан, юлдашына:

— Тугрылыклы аучыкаем, үтермәсәнә мине! Искеләреңне миңа бир дә, минем асыл киемнәремне үзеңә ал,— дигән.

Аучы, өстеннән бик авыр йөк төшкәндәй куанып:

— Мин моңа бик шатланып риза,— дигән.— Мин сиңа ата да алмас идем әле.

Алар киемнәрен алмашканнар да аучы өенә юл тоткан, король малае урман эченә кереп киткән, ди. Атна үткән, ди, шулай, ай үткән, ди. Менә бер заман король сараена алтын-көмешләр, кыйммәтле маллар төягән өч олау килеп кергән, ди. Бу хәзинәнең һәммәсе дә төпчек малай исеменә атап җибәрелгән икән. Алтын-көмеш, асылташларны төпчек малай кылычы белән дошманнарын җиңгән, аның ипие белән халкын ачлыктан коткарып калган корольләр юллаган икән, өчесе дә шулай итеп рәхмәтләрен белдерергә теләгәннәр, ди. Моны белгәч, король: төпчек улым, мөгаен, гаепсез булгандыр, дип хафалана башлаган, ди. Аннары вәзирләрен чакырып алган да:

— Их, хәзер төпчек улым исән булса икән! Нигә шулай ашыгып үтерергә куштым икән соң мин йөрәк парәмне? — дип өзгәләнгән, ди.

Шул вакыт төпчек малайны урманда үтерергә тиешле аучы телгә килеп:

— Исән ул, исән,— дигән.— Теге чакта фәрманыгызны үтәргә йөрәгем җитмәде, әмерне бозган өчен теләсәгез нишләтегез, мин менә алдыгызда.

Аннары аучы урмандагы хәлләрне корольгә сөйләп биргән, ди. Король дә җиңел сулап куйган. Бераздан ул, төпчек улыма кире сарайга кайтырга рөхсәт бирәм, кадер-хөрмәт күрсәтеп, зурлап каршы алыр идек үзен дип, бөтен тарафларга хәбәр тараткан, ди.

Ерак илдәге сихер тылсымыннан котылган гүзәл патша кызы исә, егет килер вакытка чамалап, сарае алдына саф алтыннан ялт-йолт килеп торган күпер салдырган, ди. Аннары хезмәтчеләренә:

— Сарайга туп-туры шушы юлдан килгән кеше чыннан да мине коткарган егет булыр, аны бер тоткарлыксыз капкадан кертеп җибәрегез, ә инде кем дә кем башка юлдан килә икән, кире борыгыз,— дигән.

Бер ел үткәч, корольнең олы малае, гүзәл кыз янына барырга да вакыт җитте, ахры, дип уйлый икән. Сине коткаручы егет мин инде ул, дип ышандырсам, хатыным да булып куяр, бәлки, өстәвенә, үзем дә тәхеткә утырырмын, дип, хыялланган.

Шулай хыялланып, җыенган да юлга чыккан, ди, бу. Ерак илдәге патша кызының сарае янына килеп җиткәндә бик матур алтын күперне күреп, мондый юлны ничек инде бахбайдан таптатмак кирәк, дип уйлаган да, атын уңга борып, алтын күпер кырыеннан киткән, ди. Сарай капкасына килеп җиткәч аны каравылчылар туктаткан.

— Син чын кияү түгел, яхшы чакта кире борылып китүең хәерлерәк булыр,— дигәннәр, ди.

Тагын күпмедер вакыт үткәч, корольнең уртанчы малае юлга чыккан, ди. Сарай янына килеп җиткәндә аты бер аягын күпергә китереп баскач, егет, йөрәгең җитеп ничек инде мондый затлы юлны бахбайдан таптатмак кирәк, дип уйлаган да атын сулга борган, ди. Сарай капкасы янына килеп җиткәч, каравылчылар аны да туктатканнар.

— Син чын кияү түгел, яхшы чакта кире борылып китүең хәерлерәк булыр,— дип әйткәннәр, ди.

Инде менә кызның яман сихердән котылуына төгәл бер ел тулган, ди. Гүзәл кыз сараена — үзенең сөйгәне янына төпчек малай да юлга чыккан, ди. Аның белән күрешеп, үзенең кайгы-хәсрәтләрен таратырга теләгән, ди, ул.

Юлда гел сөйгәне турында гына уйлаган, ди, егет, тиздән аның белән ничек күрешәчәкләрен күз алдына китергән, ди. Шундый хыялларга чумып, алтын күпергә килеп җитүен дә, хәтта аның барлыгын да сизми калган — аты туп-туры ялтырап, зыңлап торган юл уртасыннан атлап киткән.

Сарайга якынлашуы булган, капка шар ачылып киткән, король кызы үзе егетне бик сөенеп каршылаган, ди. Мине яман сихердән коткаручы да, мәмләкәтемнең хуҗасы да син, дигән, ди.

Утыз көн уен, кырык көн туен иткәннәр, ди. Туй мәҗлесләре узгач, кыз егеткә әтисенең аны кичерүен, туган йортына кайтса, кадер-хөрмәт белән каршы алачагы турында бөтен илләргә хәбәр тараттыруын әйткән, ди.

Төпчек малай атасы янына кайтып, абыйларының үзен ничек алдауларын, ни өчен хәзергә кадәр дөресен әйтә алмавын сөйләп биргән, ди. Король олы һәм уртанчы улларына каты җәза бирергә теләгән, ләкин алар

тиз генә корабка утырганнар да диңгез аръягына китеп барганнар, ди. Шул китүләреннән әле дә булса кире әйләнеп кайтмаганнар, ди.

БӘЛЛҮР ШАР

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер сихерче хатын. Аның өч улы булган, ди. Уллары болай бик тату яшәгәннәр, тик аналары гына аларга ышанмаган, сихерчелегемнең серен белеп, миннән өстен булырга теләмәгәйләре, дип шикләнгән. Шуңа күрә сихерче хатын олы улын карчыгага әйләндергән. Бичарага бер биек тау башында оя корып, шунда гомер итәргә туры килгән. Ара-тирә карчыга-егет, иңкүлекләргә дә очып төшеп, кешеләрнең баш өстендә диярлек әйләнеп йөргәләгән, ди.

Сихерче хатын икенче улын кит балыгына әверелдергән. Анысы төпсез диңгездә яшәгән, ди. Вакыт-вакыт аның су өстенә калкып, һавага су фонтаннары сиптергәләвен дә күргәннәр, ди. Малайлар көн саен ике сәгатькә генә кеше кыяфәтенә дә керә алалар икән.

Өченче улы, әни мине дә берәр ерткыч җанварга — аюга яки бүрегә әверелдереп куяр дип куркып, өеннән чыгып качкан, ди. Шулай дөнья гизеп йөргәндә бу егет Алтын Кояш сараенда сихерләнгән бик матур бер король кызы булуын, аның хәвефле тылсымнан үзен коткаручыны зарыгып көтүен ишеткән, ди. Ләкин кызны сихер тылсымыннан коткару бик авыр, бик хәтәр эш икән, моңа батырчылык итүченең якты дөнья белән бәхилләшүе дә ихтимал икән, ди. Егерме өч егет нәкъ менә шул юлда һәлак булган. Хәзер инде нибары бер кешегә генә бәхетен сынап карау мөмкинлеге калган икән. Әгәр ул да булдыра алмаса, сихерләнгән кызга бүтән берәү дә ярдәм итә алмаячак, ди.

Бу егет куркаклардан түгел икән, күп уйлап тормастан, Алтын Кояш сараен эзләп табарга үзенә сүз биргән. Көн киткән бу, атна киткән, шулай күп илләрне гизгән, ләкин әлеге Алтын Кояш сараена юлны таба алмаган.

Көннәрдән бер көнне егеткәй очсыз-кырыйсыз бер карурманга барып кергән, ди. Монда адашкан да кире чыга алмый тинтерәгән. Йөри-йөри хәлдән тайгач, бик еракта үзен чакырып кул болгаучы ике Алып батырны күргән, ди, егет. Барган, ди, болар янына. Алып батырлар әйткәннәр, ди, моңа:

— Бу эшләпә кемгә булырга тиешлеген берничек тә хәл итә алмыйбыз. Икебезнең дә көче-куәте бертигез,

көрәшсәк-алышсак та файдасыз. Сез, бәләкәй кешеләр, мондый эштә акыллы, зирәк буласыз, бәхәсебезне хәл итеп бирмәссеңме икән? — дигәннәр, ди.

— Шушы иске эшләпә өчен кем бәхәсләшеп тора инде? — дигән егет.

Алып батырлар аңа:

— Хасиятләрен белмисең шул эле: бу — хикмәтле эшләпә бит. Әгәр аны киеп кая да булса барырга теләк белдерсәң, күз ачып йомганчы шунда илтеп куячак,— дигәннәр.

— Шулаймыни? Бирегез әле алайса эшләпәгезне,— дигән егет,— хәзер мин бераз читкә китәрмен дә кычкырырмын, сез узышып минем янга йөгерерсез. Кайсыгыз алдан килеп җитсә, эшләпә шуңа булыр.

Егет эшләпәне кигән дә китеп барган. Үзе һаман сихерләнгән кыз турында уйлаганлыктан, Алып батырлар турында бөтенләй онытькан, юл буйлап атлый да атлый икән. Бара-бара арый башлагач, авыр көрсенгән дә:

— Их, Алтын Кояш сараена барып чыксаң иде менә хәзер,— дип куйган, ди.

Күтәрелеп караса, әлеге сарайның капкасы алдында басып тора, ди, егет. Сарайга кергән дә, бүлмәдән-бүлмәгә йөреп, анданиләр барын тикшерә башлаган бу. Бүлмәләрнең иң соңгысында гына үзе эзләгән сихерләнгән кызга тап булган. Аны күргәч, аптыраудан өнсез калган: дөньядагы сылуларның сылуы дип даны чыккан кызның битләре көл кебек соры, йөзен тирән җыерчыклар каплаган, ди, күз карашлары нурсыз, чәчләре җирән икән, ди. Егет:

— Гүзәллегенә бөтен дөнья таң калган король кызы син буласыңмы инде? — дип кычкырып җибәрүен сизми дә калган, ди.

— Аһ,— дип авыр сулаган, ди, кыз,— минем чын төсем, чын кыяфәтем түгел бу! Нишлим соң, мине кешеләр шушы ямьсез кыяфәттә генә күрә алалар шул. Әгәр минем чын төсемне күрәсең килсә, менә шушы көзгегә кара: ул минем кыяфәтемне бер дә бозмый.

Кызыкай егеткә бер көзге сузган. Аннан әйтеп тә, сөйләп тә бетерә алмаслык, дөньядагы барлык гүзәлләрнең дә гүзәле булырлык кыз карап тора, тик аның алсу яңаклары буйлап тамчы-тамчы хәсрәт яшьләре тәгәри икән, ди. Егет, тәэсирләнеп:

— Бу сихердән ничек коткарып була соң сине? Белсәң, әйт, мин бернидән дә курыкмаячакмын,— дигән.

Кыз аңа:

— Әгәр берәр җан иясе тылсымлы бәллүр шарны

кулына төшереп, шуны сихерченең үзенә күрсәтсә, сихер куәте шундук җуелачак, мин дә әүвәлге кыяфәтемә кайтачакмын. Тик миңа моны күрергә язмагандыр инде... Бәхетсез кызны коткарам дип инде кемнәр генә башларын җуймады, син дә шундый бәлагә тарысаң, бик кызганыч, гомерлек үкенеч булыр миңа,— дип әйткән.

— Хафаланма, бернинди куркыныч та туктата алмаячак мине! — дигән егет.— Бәллүр шарны кулга төшерү өчен мин нишләргә тиешлекне генә әйт син.

— Алайса, тыңла, барысын да яхшы хәтерләп кал,— дигән король кызы.— Шушы сарай урнашкан тау итәгенә төшсәң, чишмә янында бер кыргый үгез күрерсең. Шуның белән сугышырга туры киләчәк сиңа. Әгәр үгезне үтерә алсаң, аның эченнән уттай янып торган кош очып чыгар. Кошның эчендә ялкындай кызган йомырка бар. Бәллүр шар шушы йомырканың сарысы эченә яшерелгән. Ләкин кош, үзен үтермәсәң, йомыркасын салмаячак. Салса да эш җиңеләйми әле: әгәр йомырка җиргә төшсә, тирә-юньне ялкын урап алачак, җирдәге бар нәрсә янып бетәчәк. Шул ялкында йомырка да эриячәк, йомырка белән бергә бәллүр шар да юкка чыгачак. Ул чакта, күргән газапларың барысы да бушка китте дигән сүз.

Егет тау астына төшкән дә чишмә янына килгән. Селәгәйләрен агызып торган кыргый үгез үкерә-үкерә аңа ташланган, ди. Шактый озак алышканнан соң, егет кылычын хайванның корсагына кадаган. Шул мизгелдә үк гөрселдәп җиргә ауган үгез авызыннан уттай янып торган кош очып чыккан да һавага күтәрелгән. Нәкъ шул чакны егетнең карчыгага әверелеп болытлар арасында очып йөргән абыйсы ут-кошка ташланган да аны диңгезгә таба куып киткән, җаен табып, томшыгы белән аны чукып үтергән, ди. Ул да түгел, ут-кошның йомыркасы һавадан аска төшеп киткән, ләкин ул диңгезгә түгел, яр буендагы балыкчы өе өстенә туры килгән, ди. Минуты белән өйгә ут капкан, бер мизгелдән ялкын телләре аны тәмам чорнап алган, ди. Шул вакыт диңгездә күп катлы өйләрдән дә биегрәк дулкыннар тәгәрәшә башлаган, алар ярга ишелеп килгәннәр дә балыкчы өен түбәсеннән үк күмеп киткәннәр, инде дөрли башлаган ялкынны сүндергәннәр, ди. Диңгез суын егетнең кит балыгына әверелгән уртанчы абыйсы яр буена йөзеп килеп шулай дулкынландырган икән.

Янгын сүндерелгәч, егет ут-кош йомыркасын эзли башлаган, бераздан аны табып та алган. Йомырка эрергә өлгермәгән икән әле, салкын суга әләгүдән бераз

кабыгы гына чатнаган, ди. Йомырка сарысы эчендәге бәллүр шар исә бөтенләй зарарланмаган, ди. Егет шунда ук сөенә-сөенә явыз сихерче янына киткән, аңа бәллүр шарны күрсәткән, ди.

— Минем тылсымым юкка чыкты,— дигән сихерче.— Бүгеннән башлап син — Алтын Кояш сараеның короле. Абыйларыңны яңадан әүвәлге хәлләренә кайтару — яңадан кеше кыяфәтенә кертү дә үз иркеңдә.

Егет беренче нәүбәттә сарайдагы король кызы янына йөгергән. Бүлмәгә килеп керсә, хәйран калган: аның алдында көзгедә күренгән гүзәлкәйдән дә гүзәлрәк бер кыз басып тора икән. Егет белән кыз, вәгъдәләшү билгесе итеп, шунда ук балдакларын алмашканнар, кияү белән кәләш булганнар, ди.

КӨТҮЧЕ МАЛАЙ

Әүвәл заманда бер көтүче малай яшәгән, ди. Теләсә нинди сорауга тапкыр һәм акыллы җаваплар бирүе белән даны таралган, ди, аның. Шушы мәмләкәтнең короле бу хакта ишеткән дә малайны сарайга чакырырга кушкан. Кеше сөйләгәнгә генә ышанмаган ул, малайның тапкырлыгын үзе сынап карарга теләгән. Малай сарайга килгәч, король аңа:

— Мин сиңа өч сорау бирермен. Шуларга тапкыр җаваплар ишетсәм, сине үз баламдай якын күрермен — сарайда яшәрсең,— дигән, ди.

— Сорауларыгыз ниндидер бит. Йә, әйтеп карагыз,— дигән көтүче малай.

— Беренче соравым болай булыр,— дигән король.— Диңгездә ничә тамчы бар?

— Галиҗәнап король, төгәл җавап ишетим дисәгез, диңгезгә коя торган барлык елгаларны, инешләрне бер тамчысы да саркымаслык итеп буып куегыз. Шуннан соң санармын да диңгездә ничә тамчы су барлыгын төптөгәл итеп әйтермен,— дип җавап биргән, ди, көтүче малай.

Җавапның тапкырлыгы корольгә ошаган, ул:

— Икенче соравым мондый булыр: йә, әйт әле, күктә ничә йолдыз бар? — дигән, ди.

— Миңа бер бит ак кәгазь бирегез әле,— дигән көтүче малай.

Аннары ул сәгать буе шул кәгазьгә каләм белән исәпсез-хисапсыз кеп-кечкенә нокталар төртеп чыккан. Күреп тә, санап та бетерерлек түгел, ди, ул нокталарны,

карасаң, күзләрең әлҗе-мөлҗе килә башлый, ди. Кәгазьдә инде башка бер нокта куярлык та урын калмагач, көтүче малай корольгә:

— Минә шушы кәгазьдә ничә нокта булса, күктә шулхәтле йолдыз бар. Ышанмасагыз, күккә менегез дә үзегез санап төшегез,— дип әйткән, ди.

Ләкин берәүнең дә күктәге йолдызларны түгел, кәгазьдәге нокталарны да санап чыгарга хәленнән килмәгән, ди.

— Егет икәнсең,— дигән король, җавапның тапкырлыгына канәгать булып.— Инде өченче сорау сиңа: мәңгелектә ничә секунд бар?

— Ерак-еракта, җиде дәрья артында бер Алмаз тау бар икән,— дигән көтүче малай.— Аның түбәсенә күтәрелү өчен бер сәгать, бер ягыннан икенче ягына чыгу өчен тагын бер сәгать, кире әйләнеп төшү өчен янә дә бер сәгать вакыт кирәк, диләр. Менә шушы Алмаз тауга йөз елга бер мәртәбә дөньяда иң кечкенәләрдән саналган бер кошчык очып килә дә, алмаз кыяга ышкып, томшыгын чистарта, имеш. Менә шушы кошчык томшыгын чистартудан ышкылып, әлеге Алмаз тавы тәмам юкка чыкканда мәңгелекнең нәкъ бер секунды үткән булыр. Мәңгелектә ничә секунд булганны шуннан үзегез санап карагыз инде.

Король, көтүче малайның соңгы җавабын да ошатып:

— Өч соравыма да хикмәт ияседәй тапкыр, акыллы җаваплар бирдең. Вәгъдә — иман, бүгеннән сараемда яши башларсың, моннан соң сине үз улымдай якын күрәчәкмен,— дип әйткән, ди.

КРЕСТЬЯН БЕЛӘН ШАЙТАН

Әүвәл заманда бик акыллы, бик хәйләкәр бер крестьян яшәгән. Аның кылган әкәмәтләре турында бик озак сөйләп булыр иде. Тик аларның иң кызыклысы, мөгаен, крестьянның шайтан белән очрашуы, аны ничек итеп төп башына утыртуы вакыйгасыдыр.

Шулай бервакыт крестьян көне буе басуда эшләгән дә, эңгер-меңгер вакыт җиткәч, өенә кайтырга җыенган, ди. Әйләнеп караса, басу уртасында бер өем күмер янып тора икән. Бу нинди хикмәт тагын, дип, крестьян шул серле учакка таба атлаган. Якыннанрак караса, үз күзләренә үзе ышанмый икән: янып торган утлы күмер өеменең кыл уртасында кеп-кечкенә, кап-кара бер шайтан утыра, ди.

Крестьян аңа:

— Син, мөгаен, хәзинә өстендә утырасыңдыр әле?— дип сүз кушкан.

— Әлбәттә,— дип җавап биргән шайтан.— Хәзинә өстендә утырам шул. Мондагы хәтле алтын-көмешне синең гомереңдә дә күргәнең юк.

— Хәзинә минем басуда, димәк, ул — минеке,— дигән крестьян.

— Басуда үскән ике еллык уңышның яртысын миңа бирергә риза булсаң, синеке булыр,— дип әйтеп әйткән, ди, шайтан.— Акчам болай да буа буарлык минем, тик җирдә үскән җимештән дә бераз авыз итәсем килә иде.

Крестьян риза булган. Шайтанга:

— Уңышны бүлгәндә бәхәскә юл калмасын өчен, әйдә, болай килешик: быел син уңышның җир өстендәге өлешен алырсың, ә миңа җир астындагысы да ярар,— дигән.

Шайтанга бу тәкъдим дә хуш килгән. Хәйләкәр крестьян исә басуына шалкан чәчкән икән. Уңышны җыяр вакыт җиткәч, шайтан басуга килгән дә үзенә тиешле уңышны алып китмәкче булган. Ләкин аңа саргаеп, шиңеп беткән яфраклар гына эләккән. Крестьян үзе сөенә-сөенә шалканнарын җыеп алган, ди.

— Син оттың бу юлы,— дигән шайтан.— Йәренгә мин дә акыллырак булырмын. Җир өстендәгесен син алырсың, ә җир астындагысы миңа калыр.

— Моңа да риза мин,— дип җавап биргән крестьян.

Икенче язны крестьян басуына шалкан урынына бодай чәчкән. Иген өлгергәч, тук башаклы бодайны крестьян үзе урып алган. Шайтан да өлешен алырга дип басуга килгән. Тик ни күрсен, аңа камыл белән тамырдан башка бернәрсә дә калмаган. Гаҗәпләнүеннән, гарьләнүеннән ярылырга җитәрдәй ярсып, таш кыялар арасындагы тау тишегенә кереп качкан, ди, шайтан.

Крестьян көлеп:

— Синең ише аңгыраларны төп башына менә шулай утырталар,—дигән, ди.

Аннары хәзинәне өенә алып кайтып киткән, ди.

УНИКЕ ТУГАН

Әүвәл заманда бер король яшәгән, ди. Сөекле хатыны белән алар унике бала үстерәләр, ләкин барысының да малай булуына икесенең дә эче поша икән. Кыз тансыклаган король беркөнне хатынына:

— Әгәр дә син тагын бала табып, анысы кыз була калса, ул исәпсез-хисапсыз байлыгыбызга, бөтен мәмләкәтебезгә берүзе ия булсын өчен, улларыбызны юк итми ярамас,— дигән.

Шулай дигән дә король унике табут ясарга кушкан. Аларга йомычка, кайры тутырып, һәркайсына мәет башы астына куела торган кечкенә мендәрләр салдырган. Аннары табутларны бер аулак бүлмәгә куеп, ишеген бикләгән дә ачкычын хатынына биргән, бу хакта берәүгә дә ләм-мим әйтмәскә кушкан.

Шул көннән соң король хатынының кайгы-хәсрәтсез чагы иртәнге җиңелчә томандай юкка чыккан, бер генә минут та еламый тормаган. Гел әнисе янында бөтерелгән төпчек малай аның кайчан карама моңланып йөрүен күреп:

— Әнкәем, нигә син һәрвакыт шундый караңгы чырайлы? — дип сорый икән.

— Әй, балакаем,— дип җавап бирә, ди, әнисе,— әйтергә ярамый шул бу хакта.

Ләкин малай әнисенә һаман тынгылык бирмичә, тәмам аптыратып бетергән. Бервакыт әнисе түзми, төпчеген әлеге аулак бүлмәгә алып килә дә, ишеген ачып, йомычка-кайры тутырылган табутларга күрсәтә-күрсәтә:

— Бәгырькәем, бу табутларны синең белән абыйларың өчен дип әтиең ясатты. Әгәр мин кыз бала тапсам, сезнең барыгызны да үтереп, шушы табутларда күмәчәкләр,— ди.

Үзе сөйли, ди, король хатыны, үзе тыела алмый бертуктаусыз елый, ди. Улы әнисен тынычландырырга теләп:

— Әнкәем, бәгърем, елама, бу хәлдән котылуның берәр чарасы бардыр әле, мөгаен. Ахыр чиктә, кая да булса качып китәрбез,— ди.

Бераз тынычлангач, әнисе аңа:

— Абыйларыгыз белән урманга китеп торсагыз, ничек булыр икән? Бер биек агач табып, берегез шуның башына менеп утырыр да һәр көнне сакта торыр, сарайдагы манараны күзәтер. Әгәр дә ир бала тапсам, манарага ак флаг элдерермен, бу — өйгә кайтырга ярый, дигән билге булыр. Әгәр дә инде кыз бала тапсам, манарага кызыл флаг элдерермен, бу инде — мөмкин кадәр тизрәк бүтән мәмләкәткә качып китегез, дигән билге булыр. Соңгы очракта язмыш иркенә тапшырам инде үзегезне. Тик мин беркайчан да сезгә яхшылык теләүдән туктамам. Кышын җылы учакка, җәй эссесендә рәхәт күләгәгә тап булуыгызны телэрмен,— ди.

Әниләре шулай хәер-фатиха биргәч, малайлар урманга качып китә. Әле берсе, әле икенчесе көн саен сакта тора, биек имән башына менеп утыра да сарай манарасын күзәтә. Шулай унбер көн үтеп тә китә. Сакта торырга Төпчек малайга да чират җитә. Ул, имән башына менүгә, сарай манарасында кандай кызыл флаг җилфердәвен күреп ала. Бу инде агай-энеләрнең уникесе дә үтерелергә тиеш дигән ишарә була.

Малайларның моңа яман да ачулары чыга. Алар:

— Бер кыз аркасында нишләп һәлак булыйк соң әле без? Бу — чын-чыннан гаделсезлек, моның өчен үч алырга кирәк. Әйдәгез, моннан соң кайда гына очратсак та, кызларның канын коярга ант итик,— диләр.

Агай-энеләре шулай килешәләр дә карурманга тагын да эчкәрерәк кереп китәләр. Бара-бара урманның кап уртасына, көндез дә кара төндәгедәй дөм-караңгы булган бер җиргә килеп чыгалар. Алда бер өй калкып тора икән: үзе буш, тирә-ягында да җан әсәре күренми, ди. Агай-эне, үзара киңәшеп:

— Яшәргә була монда! Син, Төпчеккәй, арада иң кечкенәбез, көч-дәрманың да юк әле, шуңа күрә өйдә генә калырсың, йорт эшләрен карарсың, ә без азык-төлек эзләргә чыгабыз,— диләр.

Киңәшкәнчә, унбер туган сунарга чыгып китә бер заман. Куяннар, кыр кәҗәләре, күгәрченнәр, ашарга яраклы бүтән киекләр аулап, өйгә шактый мул табыш белән кайталар. Төпчек малай шулардан төрле-төрле тәмле ашлар хәстәрли. Унике туган энә шулай тамакларын туйдыра, шул өйдә гомер итеп, ун ел узганын сизми дә калалар.

Ул арада бу егетләрнең сеңелесе дә үсеп буйга җитә. Бик игелекле, төскә-биткә чибәр, маңгаена бер йолдыз да кунган кыз була ул. Шулай бер заман керләр юганда, король кызы унике күлмәк күреп ала, аларның барысы да ирләрнеке икәнен белеп гаҗәпләнә. Ул әнисеннән:

— Кем күлмәкләре болар? Әтинеке дияр идем, кечкенәләр,— дип сорый.

Әнисе, хәсрәтеннән кара көеп:

— Кызым, бәбкәм, абыйларыңның күлмәкләре алар,— ди.

Кыз:

— Кая соң ул абыйларым? Нишләп мин аларны беркайчан да күргәнем юк? — дип сорый.

— Аларның кайда икәнлекләрен үзем дә белмим шул, кызым,— дип җавап бирә әнисе.— Кайсы илләр-

дә, кай җирләрдә каңгырып йөриләрдер инде бичаракайларым.

Аннары король хатыны кызын бикле аулак бүлмәгә алып бара да, эчләренә йомычка-кайры тутырылган, мәет мендәрләре салынган унике табутны күрсәтеп:

— Бу табутлар абыйларың өчен ясатылганнар иде, шуңа күрә алар син туганчы ук качып киттеләр,— ди.

Шуннан соң әнисе аңа фәлән ел элек нинди-нинди хәлләр булганын барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп биргән, ди.

Кыз, әнисен тынычландырырга теләп:

— Елама, әнкәем, абыйларымны ничек кенә булса да эзләп табармын,— дигән.

Тиздән ул абыйларының күлмәкләрен ала да юлга чыга — туп-туры әлеге карурманга юнәлә. Көне буе барган, ди, кыз, кич җиткәндә генә аландагы ялгыз йорт янына килеп җиткән. Өйгә йөгереп керсә, анда бер егет утыра икән. Хуҗа кыздан:

— Син монда ничек килеп чыктың? Кая баруың иде? — дип сорый.

Үзе кыздан бер дә күзен алмый, аның матурлыгына, пөхтә, бай киемнәренә соклана, ди. Маңгаендагы алтын йолдызын күргәч, тәмам хәйран калган бу.

— Мин — король кызы,— ди юлаучы.— Югалган унике абыемны эзлим. Аларны очратмыйча җаным тынгы тапмаячак, кирәк икән, зәңгәр офыкларга кадәр барачакмын.

Шулай ди дә егеткә абыйларының күлмәкләрен күрсәтә. Төпчеккәй бары шунда гына бу чибәр кызның үз сеңелесе булуына төшенә.

— Алайса, мин синең иң нәни абыең булам инде,— ди.

Кыз шатлыгыннан елый башлаган. Төпчеккәй дә аңа кушылган. Кочаклашып күрешкәннәр, ди, болар. Бераз тынычлангач, егет:

— Сеңелкәш, бер четерекле нәрсә бар бит әле: без юлыбызда очраган теләсә нинди кызны үтерергә ант иткән идек. Кыз бала туу аркасында туган-үскән илебездән качып китәргә мәҗбүр булгач, шундый карарга килгән идек,— ди.

— Үлемем белән унике абыемны коткара алсам, мин аңа әзер,— ди кыз.

— Юк,— ди абыйсы,— син үлмәскә тиеш. Хәзер менә шушы мичкә астына кереп утыр, абыйлар кайтканны көт. Мин аларны ничек булса да карарны үзгәртергә күндерермен.

Абыйсын тыңларга була кыз. Инде төн җитте дигәндә, унбер туган аудан кайтып керә. Ашарга әзер икән инде, җыйнаулашып өстәл артына утыралар. Табын янында энеләреннән:

— Йә, дөньяда ниләр бар, ниләр ишеттең? — дип сорыйлар.

— Сез берни дә белмисезмени әле? — ди Төпчеккәй.

Абыйлары:

— Юк, — дип җавап бирә.

Төпчеккәй:

— Сез урманнарда йөреп кайттыгыз, дөнья күрдегез, ә мин ялгыз башым өйдә утырам, алай да сездән күбрәк беләм икән, — ди.

— Шулай булгач, яңалыгыңны тизрәк безгә дә сөйлә, — дип ашыктыра моны абыйлары.

Төпчеккәй:

— Беренче очраган кызны үтермәскә дип вәгъдә бирәсезме соң? — ди.

Абыйлары барысы берьюлы:

— Бирәбез, бирәбез, — диләр. — Ярар, мәрхәмәт күрсәтик инде. Йә, тизрәк сөйлисеңме, юкмы?

Шуннан соң гына Төпчеккәй:

— Көтелмәгән кунагыбыз бар ич әле безнең. Сеңелебез килде, — ди.

Аннары, мичкәне күтәреп, аның астыннан матур киенгән, маңгаенда алтын йолдызы булган чибәркәйне тартып чыгара. Егетләр барысы да бик сөенешәләр, сеңелләре белән кочаклашып күрешәләр, хәл-әхвәл сорашалар, бик әйбәтләп сыйлыйлар.

Икенче көнне Төпчеккәй сеңелесе белән өйдә кала. Сеңелесе аңа йорт эшләрендә булыша. Башка көннәрдә дә унбер агай-эне шулай ауга чыгып китә, төрле-төрле киекләр — кыр кәҗәләре, күгәрченнәр, ашарга яраклы бүтән җанварлар, кошлар аулап кайталар. Төпчеккәй сеңелесе белән аш-су хәстәрләп тора. Кыз һәр иртәдә учак ягарга чыбык-чабык җыештыра, аш тәмләткечләр — төрле үләннәр, яшелчәләр эзли, аннары чүлмәктә шулпа пешерергә куя. Төпчеккәй исә аңа һәр эштә ярдәм итә. Абыйлары кайтканда тәмле аш һәрвакыт әзер була. Өйне дә бик пөхтә тота кыз, абыйларының урынҗирләрен дә юарга-җыярга өлгерә. Егетләр моңа бик сөенә, сеңелләре белән бик тату яшиләр. Өс бөтен, тамак тук булгач, җан тыныч, күңел көр боларның.

Туганнар яшәгән йорт тирәсендә кечкенә генә бер бакча да бар икән. Ул бакчада бик матур унике лалә чәчәге үсеп утыра икән. Беркөнне, абыйларын сөенде-

рергә теләп, кыз шул лалә чәчәкләрен өзеп ала да табынга утырыр алдыннан гына һәркайсына бирәр чәчәк бүләк итәргә уйлый. Әмма кызның лаләләрне өзеп алуы була, унике абыйсы күз ачып йомганчы унике каргага әверелә. Аннары алар урман өстеннән күтәрелеп, очып та китәләр. Шул мизгелдә үк алар яшәгән йорт белән әлеге бакча да юкка чыга, мескен кыз карурман уртасында япа-ялгызы утырып кала. Артына борылып караса, янәшәсендә генә бер карчык басып тора, ди.

— Балакаем, нишләдең син? — ди ул кызга.— Нигә инде лалә чәчәкләренә тидең? Алар синең абыйларың иде бит. Хәзер инде гомерлеккә карга булып калачаклар.

Кыз елый-елый карчыктан:

— Бу сихерне бетерердәй бер әмәл дә юк микәнни?— дип сорый.

— Юк шул,— ди карчык.— Хәер, бердәнбер чара бар барын, ләкин ышаныч аз. Бу юл белән абыйларыңны коткарырга сабырлыгың да җитмәс, хәлеңнән дә килмәс. Нинди чара дисеңме? Җиде ел буе чукрак-телсез кешедәй берни сөйләшмәскә, көлмәскә тиеш син. Җиде ел туларга ярты сәгать калганда ялгыш кына бер кәлимә сүз ычкындырсаң да бар тырышлыгың җилгә очачак, абыйларың шул бер сүз аркасында һәлак булачаклар.

Кыз чын күңеленнән:

— Абыйларымны һичшиксез коткарачакмын,— ди.

Ул шунда ук бу сихерләнгән аланнан китеп, бер биек агач башына менеп утыра да җеп эрли башлый, ләм-мим эндәшмәс, елмаймас-көлмәс була, ди.

Көннәрдән бер көнне шушы урманга бер король ауга чыга. Аның үзе белән бозау хәтле бурзай эте дә була. Шул эт кыз утырган агач төбенә килә дә, арлы-бирле сикеренә, чәбәләнеп-чәбәләнеп өрә башлый. «Нигә шулай каударлана соң әле бу эт? — дип, король агач башына күтәрелеп карый. Анда утырган кызны күргәч, үз күзенә үзе ышанмый. Искиткеч матур, бик-бик сөйкемле, маңгаендагы алтын йолдызы җемел-җемел нур чәчә — сокланып туя алмаслык, ди!

Корольнең шунда ук кызга күңеле төшә.

— Минем никахлы хатыным булсана? — дип эндәшә.

Ләкин кыз бер җавап та бирмәгән, бары тик сизелерсизелмәслек итеп башын гына игән, ди.

Король, агач башына менеп, кызны үзе алып төшә дә, ияренә утыртып, сараена алып кайта. Бик зурлап туй итәләр, тик кәләше һаман бер кәлимә сүз дә ычкын-

дырмый, хәтта елмаймый да, ди. Бер-берләрен яратып, берничә ел бик тату яшиләр болар. Әмма корольнең әнисе бар икән, ул бик явыз бер карчык икән. Шул бер заман килененә төрлечә яла яга, гайбәт тарата башлый.

— Бер хәерче нәмәрсә алып кайткансың лабаса. Кем белә, бәлки эче тулы явызлыктыр әле. Ярар, телсез дә булсын, сөйләшә дә алмасын, ди. Ләкин шул гомердән бирле һич югы бер мәртәбә генә булса да елмаерга тиештер ич инде?! Елмаймаган-көлмәгән кешедән өмет өз, диләр. Эче тулы агудыр карачкының, абау, кыяфәтсез,— дип битәрли дә битәрли, ди, улын.

Башта король мондый сүзләргә бер дә колак салмый. Ләкин явыз карчык тәмам теңкәсенә тигән, киленен нинди генә әшәкелекләрдә гаепләмәгән ул. Король әкренләп сабырлыгын җуя башлый, озакламый хатынын үлем җәзасына да хөкем иттерә, ди.

Сарай ишегалдында зур учак ягалар да кызны шунда яндырырга җыеналар. Король үзе, тәрәзәсе алдына килеп баса да, күз яшьләре аша ишегалдындагы фаҗигане күзәтә. Бичара әле һаман да хатынын ярата икән, ди.

Кызны баганага бәйләп куялар. Сары ялкын телләре аның күлмәк итәкләрен ялый башлый. Нәкъ шул мизгелдә билгеләнгән җиде елның актыккы минуты да тула. Һавада көтмәгәндә канат каккан тавышлар ишетелә, аннары офыкта унике карга очып килүе күренә. Алар бер-бер артлы сарай ишегалдына төшеп куналар. Җиргә төшеп кунганы бере кеше кыяфәтенә керә бара, ди. Шулай итеп унике агай-эне сихер тылсымыннан котыла.

Абыйлары кызны яндырырга дип кабызылган учакны бик тиз туздырып ташлыйлар, утны сүндерәләр, кадерле сеңелләренә рәхмәт әйтеп, аны юатырга, иркәләргә тотыналар.

Хәзер инде кыз үзе дә теләгән кадәр сөйләшә дә, елмая, көлә дә ала. Шунлыктан ул сөекле иренә үзенең ни өчен җиде ел буе телсез булуын, ни өчен беркайчан да елмаймавын-көлмәвен сөйләп бирә. Хатынының тузан хәтле дә гаебе булмавын аңлап, король бик сөенә, җәзаларга җыенуы өчен үкенә, гафу үтенә. Алар үлгәнче бер-берләрен яратып, тату гомер итәләр.

Корольнең усал анасын исә, яла яккан өчен, башта кайнап торган майга, аннары агулы еланнар тутырылган мичкәгә салалар. Явыз карчык әнә шунда тиешле җәзасын алган — якты дөнья белән саубуллашкан, ди.

УРМАН ИЯЛӘРЕ

Әүвәл заманда бер ир яшәгән, ди. Аның хатыны үлеп, кызы ятим калган. Шул заман бер хатын да тол калган, аның да кызы булган, ди. Ике кыз бер-берсен яхшы белгәннәр, еш кына бергә-бергә уйнап көн уздырганнар. Ара-тирә икәүләп тол хатын өендә дә уйныйлар икән. Шулай бервакыт тол хатын теге ирнең кызына:

— Кызым, әтиеңә әйт әле: минем аңа кияүгә чыгасым килә. Әтиең миңа өйләнсә, син һәр иртәне сөт белән генә юыныр, тәмле ширбәт кенә эчәр идең, ә үз кызым су белән генә юыныр, эчәренә дә салкын су гына булыр иде,— дип пышылдаган.

Кыз өенә кайткан да тол хатын сүзләрен әтисенә җиткергән. Әтисе уйга калып утырган-утырган да:

— Нишләргә икән соң? Өйләнү болай күңелле нәрсә кебек тә, төптәнрәк уйласаң, ахыры шиклерәк шул,— дигән.

Абзый шулай бик озак икеләнеп утырган, ләкин төпле генә бер фикергә килә алмаган. Аптырагач, аягындагы тишек итеген салып кызына тоттырган да:

— Менә шушы итекне чардакка алып мен дә бер зур кадакка элеп куй, аннары эченә су тутыр. Әгәр аның тишегеннән су акмаса, тәвәккәлләп, өйләнермен, әгәр инде акса, өйләнеп тормам,— дигән.

Кыз әтисе әмерен нәкъ кушылганча үтәгән. Ләкин гаҗәп хәл: итеккә мөлдерәмә су тутырса да, тамчысы да саркып чыкмаган, тишек ничектер үзеннән-үзе томаланган, ди. Кыз бу хәлне әтисенә белдергән. Әтисе ышанырга да, ышанмаска да белмәгән, чардакка үзе менеп киткән. Кызы әйткәннең дөрес булуын күргәч, теге тол хатын янына барып: «Әйдә, миңа кияүгә чык инде!» — дип сүз кушкан, ди. Озакка сузмаганнар, туй иткәннәр.

Иртәгесен йокыдан торган җиргә ирнең кызына юынырга сөт, эчәренә татлы ширбәт әзерләп куелган, ди. Хатынның үз кызына исә юынырга да, эчәренә дә су гына икән. Икенче көнне хатын иренең кызы өчен дә, үзенеке өчен дә юынырга су гына куйган, эчәргә дә су гына биргән, ди. Өченче көнне үги ана иренең кызына юынырга да, эчәргә дә су гына биргән, ә үз кызына юынырга сөт, эчәргә татлы ширбәт хәстәрләгән, ди. Моннан соң инде хатын гел шулай итә башлаган, ди. Өстәвенә, үги кызын кан дошманы итеп санарга керешкән, көнетөне аңа нинди дә булса начарлык эшләү турында гына уйлаган, ди. Җитмәсә, үги ана көнче дә икән әле. Үги

кызының чибәрлеге, сөйкемлелеге, ә үз кызының күңел биздергеч дорфа булуы яман хисләрен тагын да дөрләтебрәк җибәргән, ди. Шулай бер заман чатлама суык кыш җитеп, таулар, тугайлар калын кар юрганы белән каплангач, хатын кәгазьдән бер күлмәк теккән дә үги кызына:

— Менә шушы күлмәкне ки дә тиз генә урманга бар. Җиләк ашыйсым килә, миңа бер тырыс каен җиләге җыеп кайт,— дигән.

— Абау, әни,— дигән кыз, еламсырап,— кыш көне нинди җиләк үссен ди инде? Җир күптән туңган, бар дөньяны кар баскан. Аннары ни өчен кәгазь күлмәктән генә барырга тиеш соң әле мин? Тышта тынны кисәрлек салкын, өстәвенә җил дә исеп тора. Чәнечкеле ботакларын тырпайткан куаклар кәгазь күлмәгемне генә түгел, бөтен тәнемне ерткалап, җәрәхәтләп бетерәчәк.

Үги ана:

— Әле карышып торасыңмыни? — дип җикеренгән.— Бар, диләр ич, сиңа, юлыңда бул! Тырысыңны тутырып җиләк җыеп кайтмасаң, бүтән күземә күренмә! — Шулай дигән дә кызга каткан ипи сыныгы сузып: — Менә ашарыңа. Бар, алдыңнан артың матур,— дигән.

Үзе эченнән: салкыннан, ачлыктан дөмегер, бүтән күземә күренмәс, дип уйлаган.

Үги кыз тыңлаучан икән, бүтән карышып тормаган, кәгазь күлмәген кигән дә, тырысын алып, урманга киткән. Тирә-якта иксез-чиксез карлы яланнардан башка һичнәрсә юк, ди, нигә шунда сүз имешенә бер яшел үлән сабагы күренсен! Кая инде ул каен җиләге!

Урманга кереп күпмедер баргач, кызыкай нәни генә бер йорт янына килеп чыккан. Аның тәрәзәсеннән кеп-кечкенә өч урман иясе карап тора икән. Кыз аларга хәерле көн теләп, курка-курка гына ишек шакыган. Урман ияләре:

— Кер, әйдә, кер,— дип тавыш биргәннәр.

Кыз өйгә кергән, кыяр-кыймас кына мич буендагы эскәмиягә утырган, шунда бераз җылынып, тамак ялгамакчы булган. Урман ияләре аңардан:

— Безгә дә бер чиметем генә булса да ипи бирмәссеңме икән? — дип сораганнар.

Үги кыз ипи сыныгын урталай кискән дә, яртысын аларга сузып:

— Рәхим итегез! — дигән.

Урман ияләре:

— Шушындый кышкы салкында кәгазь күлмәктән генә нишләп болай урманда йөрисең? — дип сораганнар.

— Аһ! — дип авыр сулаган кыз,— кешегә дә әйтә торган түгел: үги анам менә шушы тырысны тутырып каен җиләге җыеп кайтырга кушты. Таба алмасаң, өйгә кайтып та кирәсе булма, диде.

Ипиләрен ашап бетергәч, урман ияләре кызга бер себерке биргәннәр дә:

— Бераз ярдәм ит әле безгә, ишегалдындагы карларны гына себереп кер әле,— дигәннәр.

Кыз чыгып киткәннән соң урман ияләре үзара:

— Бигрәк акыллы, әйбәт кыз! Соңгы сыныгын да уртаклашты нарасый. Нәрсә бүләк итик икән үзенә? — дип сөйләшәләр, ди.

Урман ияләренең беренчесе:

— Мин аңа көннән-көн арта бара торган чибәрлек бүләк итәм,— дигән.

Икенчесе:

— Ә мин аңа бер сүз әйткән саен авызыннан коела торган алтын тәңкәләр бүләк итәм,— дигән.

Өченчесе:

— Мин аңа юлында очраган беренче корольне кияү итәчәкмен,— дигән.

Үги кыз исә бар ихласы белән тышта урман ияләре кушкан эшләрне үтәргә керешкән — ишегалдындагы карларны көрәргә, себерергә тотынган, ди. Менә шунда ул — адәм ышанмаслык хәл! — мәмрәп пешкән каен җиләкләрен күреп алган. Бармак башыдай эреләр, карасу-кызыллар, кар астында тәгәрәшеп яталар икән! Кыз аларны тырысы түбәләмә тулганчы шатлана-шатлана җыйган. Аннары әлеге урман ияләренә чын күңеленнән рәхмәт әйткән дә, һәркайсына кул биреп саубуллашып, өенә йөгергән — үги анасына татлы җиләкләрне кайтарып бирергә ашыккан.

Капкадан кереп, үги әнисенә «Хәерле көн!» — дип эндәшүе булган, үги кызның авызыннан идәнгә зыңгылдап алтын тәңкәләр коелган, ди. Аннары ул урманда нәрсәләр күрүен, кемнәрне очратуын тәфсилләп сөйли башлаган. Бер сүз әйткән саен авызыннан тәңкә коелганлыктан, бөтен идән озакламый алтынга күмелгән, ди.

Сеңелесенең моңа бик тә көнчелеге кузгалган, әмма тыштан сер бирәсе килмичә:

— Мактануын гына карагыз әле сез моның, алтын тәңкәләр түкерә, имеш! — дип гаеп итүен генә сиздергән.

Аулакта калгач исә әнисеннән үзен дә җиләк җыеп

кайтырга җибәрүен үтенә башлаган. Ләкин әнисе бик нык каршы төшкән:

— Юк, кызым, бәгырькәем, тышта чатлама суык, адашып, туңып үләрсең йә,— дигән.

Әмма кызы ялына-ялына аптыратып бетергәч, бар инде алайса, дип ризалык биргән, ди. Урманда туңа күрмәсен дип, ул үз кызына тиен, җофар тиреләреннән йомшак, җылы тун теккән, ашарына калын итеп май яккан ипи, тәмле-тәмле кәлҗемәләр биргән, ди. Кыз әнә шулай җыенып, урманга киткән дә туп-туры элеге кечкенә йорт янына барып чыккан. Тәрәзәдән баягы нәни кешеләр — урман ияләре карап тора, ди. Ләкин кыз аларга сәлам дә бирмәгән, күз дә салмаган, ишекләрен шакымый-нитми каерып ачып, абына-сөртенә өйләренә кергән дә, мич башларына ук менеп китеп, калын итеп май яккан ипиен, тәмле-тәмле кәлҗемәләрен умырып-умырып ашарга тотынган.

Урман ияләре аңардан:

— Безгә дә бирәр чеметем генә ризык бирмәссеңме икән? — дип үтенгәннәр.

Кыз аларга дорфа гына:

— Үзегез нәрсә бүләк иттегез соң әле? Мин нигә чамалы гына ашамлыгымны да уртаклашырга тиеш? — дип җавап кайтарган. Ул ашап туйгач, урман ияләре:

— Әнә анда себерке бар, шуны ал да өй алдындагы карларны себереп кер әле,— дип үтенгәннәр.

Кыз аларга:

— Һе, кирәк булса, үзегез дә себерерсез әле, мин сезгә ялчы түгел,— дип җавап биргән.

Аннары урман ияләренең үзенә ни дә булса бүләк итәргә ашыкмауларын аңлагач, дулап ишегалдына ук чыгып киткән, ди.

Урман ияләре исә үзләре генә калгач:

— Ай-һай, тискәре, ай-һай, усал, җитмәсә, көнче дә, ялкау да нәмәрсәкәй икән бу. Күңел биздергеч бу бәндәгә нәрсә генә бүләк итик икән инде? — дип киңәшә башлаганнар.

Аларның беренчесе:

— Көннән-көн арта барачак килбәтсезлек бүләк итәм мин аңа,— дигән.

Икенчесе:

— Бер сүз әйткән саен авызыннан сикереп төшә торган гөберле бакалар бүләк итәм мин аңа,— дигән.

Өченчесе:

— Ә мин аңа газаплы үлем бүләк итәм! — дип өстәгән.

Кыз урманда тырыша-тырыша каен җиләкләре эзләгән, тик берне дә таба алмыйча, тәмам кәефе кырылып, өенә кайтып киткән. Урманда ниләр күрүен әнисенә сөйли башлаган икән, һәр сүзе саен авызыннан гөберле бака сикереп чыга башлаган, бервакыт бөтен идән әнә шул хәшәрәтләр белән тулган, ди.

Бу хәлне күреп, үги ананың ачуы тагын да кабара төшкән. Хәзер инде ул торган саен чибәрләнә барган үги кызына нинди дә булса явызлык эшләү турында гына уйлаган.

Бервакыт явыз хатын учак элдереп җибәргән дә эрләгән җебен казанда кайната башлаган. Бераздан аларны үги кызның иңбашына салган, кулына балта тоттырган да елгага барып бәке ачарга, аннары кайнатылган җепләрне шунда чайкарга кушкан, ди.

Сүз тыңлаучан кыз бу юлы да карышмаган, елга буена килеп боз чаба — бәке уя башлаган. Менә шунда бәке ачып торганда кыз үзенә таба пар ат җигелгән артлы чана килүен күргән. Анда исә король утыра икән. Атларын туктаткан да сораган, ди, король:

— Кем син, кызыкай? Монда нәрсә эшлисең?

— Бер ятим кыз мин, бәкедә керләр чайкыйм менә.

Корольгә эчкерсез җавап та, кызның төскә-биткә искиткеч матур булуы да ошаган.

— Минем белән китәр идеңме? — дигән ул.

— Бик шатланып риза булыр идем,— дигән кыз.

Үги анасы җәбереннән котылуны уйлаган ул. Король исә аны чанасына утырткан да туп-туры сараена алып кайткан.

Монда олы мәҗлес корып, туй иткәннәр. Менә шулай урман иярәренең үги кызга теләгән теләкләре барысы да тормышка ашкан, бер ел тулганда корольнең яшь хатыны бер малай тапкан.

Үги ана сөймәгән кызының шундый зур бәхеткә ирешүен ишеткәч, үзенең килбәтсез кызын ияртеп, хәл белергә дип сарайга киткән, ди.

Король каядыр чыгып киткәнлектән, яшь хатын сарайда ялгызы гына калган вакыт булган бу. Шуны гына көтеп торган явыз үги ана кызы белән икәү көтмәгәндә галиҗәнапның бүлмәсенә килеп кергәннәр дә, берсе башыннан, икенчесе аякларыннан эләктереп алып, король хатынын караватыннан сөйрәп төшергәннәр. Аннары тәрәзәне ачып, сарай каршыннан ургылып аккан елгага ташлаганнар, ди. Шуннан соң явыз үги ана үзенең котсыз кызын караватка яткырган, аны башыннан ук юрган белән томалап куйган.

Бервакыт король дә кайтып кергән, тизрәк сөекле хатыны янына ашыккан. Мәрхәмәтсез үги ана, галиҗәнапны туктатып:

— Кәләшең кинәт авырып китте әле, манма тиргә баткан. Бүген борчыма инде син аны,— дигән.

Ниндидер явызлык-фәлән булыр дип корольнең уена да килмәгән, билгеле, хатыны янына икенче көнне иртән генә кергән. Сүз кушкан икән, тегесе җавап бирергә дип авызын ачуы булган, һәр сүзе саен идәнгә гөберле бакалар сикереп төшә башламасынмы! Моны күргән король: «Бу ни галәмәт? Элек алтын тәңкәләр генә коела иде ләбаса»,— дип аптыраштa калган. Явыз үги ана галиҗәнапны: «Артык тирләгәнгә шулай булгандыр, тиздән чире үтеп китәр»,— дип тынычландырырга тырышкан.

Төнлә ашчы малай елгадан бер үрдәк йөзеп килгәнне күргән, ди. Үрдәк, телгә килеп:

— Король, король, хәлең уңаймы?
Йоклыйсыңмы әллә уяумы? —

дип сораган, ди.

Ашчы малай бернинди җавап та бирмәгәч, үрдәк яңадан:

— Кунакларың торамы иртә? —

дигән, ди.

Бу юлы ашчы малай:

— Икесе дә йокы симертә,—

дигән.

Үрдәк янә дә:

— Балакаем минем ни хәлдә? —

дип сораган, ди.

Ашчы малай:

— Бишегендә йоклый, тирбәлә,—

дип җавап биргән.

Шуннан соң үрдәк король хатыны кыяфәтенә кергән дә баласын имезгән. Аннары аны бишегенә салып, әкрен генә тирбәткән. Беравыктан, бәбинең өстенә ябып, яңадан үрдәккә әйләнгән дә елга буйлап йөзеп киткән. Бу хәл икенче төнне дә кабатланган. Өченче тапкыр килгәндә үрдәк ашчы малайга:

— Бар, тизрәк корольгә әйт: кылычын алсын да мин бусагадан атлаганда баш очымда өч тапкыр уйнатсын,— дигән.

Ашчы малай шунда ук король янына йөгергән, тизрәк кылычыңны алып кил дә өч мәртәбә хатының өрәге өстендә уйнат, дигән.

Кылычын өченче мәртәбә селтәве булган, корольнең каршысына теп-тере, исән-сау хатыны килеп баскан. Элеккедән дә матуррак икән, ди. Король куанычының иге дә, чиге дә булмаган. Шулай да хатынын якшәмбе җиткәнче бер аулак бүлмәдә яшереп тоткан. Шул көнне балага исем кушарга тиеш булганнар икән. Балага исем кушкач, король хатынының үги анасыннан:

— Әгәр дә мәгәр берәү явыз ният белән икенче кешене караватыннан сөйрәп төшерсә, аннары аны суга ташласа, моның өчен нинди җәза татырга тиеш? — дип сораган.

Король сүзләренең мәгънәсен аңлап җиткермәгән явыз карчык:

— Мондый мәрхәмәтсезлек өчен ул адәмне эчке ягына кадаклар кагылган мичкәгә салып, тау башыннан аска таба тәгәрәтеп җибәрүдән дә әйбәтрәк җәза булмас,— дигән.

— Җәзаны үзеңә үзең билгеләдең,— дигән король.

Шуннан соң бер зур мичкәнең эчке ягына кадаклар кактырып, шунда явыз карчык белән аның көнче кызын утыртырга кушкан. Аннары, мичкәнең төбен дә кадаклап, тау башыннан аска таба тәгәрәтеп җибәргәннәр, ди.

ҺӘНЗИЛ БЕЛӘН ГӨРИТЕЛ

Кара урман буенда утын кисеп көн күрүче бер ярлы яшәгән, ди. Аның хатыны, ике баласы булган. Малае Һәнзил, кызы Гөрител исемле икән. Тормышлары бер дә мактанырлык булмаган, ачлы-туклы гына гомер иткәннәр, ди, болар. Бер заман илдә бәяләр күтәрелгән, утынчы җан асрарга җитәрлек тә акча эшли алмый башлаган. Бик авыр уйлар баскан моны. Шулай бер кичне, иртәгәсе көн турында кайгыртып, йокыга китә алмыйча, әле бер, әле икенче ягына әйләнгәләп, караватында уфтанып ята икән. Байтак аунагач, авыр сулап, хатынына:

— Йә, нихәл итәбез инде? Нәрсә ашатыйк инде мескен балакайларга, бер кабарлык та ризык калмады ич! — дигән.

— Беләсеңме нәрсә, картым,— дигән хатыны, — иртәгә таң белән торыйк та балаларны алып урманга барыйк, чытырманлыкның иң куе, ялгыз гына өйгә кайту юлын таба алмаслык җиренә керик. Шунда алар өчен бер учак ягып җибәрербез дә калган ипи сыныкларын

кулларына тоттырырбыз. Аннары үзебез, эшкә киткән сыман, юк булырбыз. Шулай итеп алардан котылырбыз.

Моңа каршы ире:

— Юк, карчык, мондый эшне булдыра алмыйм мин. Ничек инде газиз балаларыңны ялгыз урманда ташлап калдырырга кирәк? Без киткәч үк ерткыч җанварлар килеп, ботарлап бетерәчәк бит аларны,— дигән.

Хатыны:

— Тинтәк син, болай дүртебез дә ачтан үләбез бит. Мондый булдыксызлыгың белән табут өчен такта ышкыларга да ярамавыңны онытма! — дигән.

Шулай битәрли-битәрли, хатыны тәмам теңкәсенә тигән моның. Аптырагач, утынчы ризалашкан, тик анда да:

— Барыбер мескен балаларымны кызганам шул,— дип куйган.

Тамаклары ач булганлыктан, балалар йокыга китә алмый яталар икән. Шуңа күрә алар үги аналары сөйләгәннәрнең барысын да ишеткәннәр. Гөрител үксеп елый-елый Һәнзилгә:

— Хәзер нишлибез инде без? — ди икән.

Һәнзил, сеңелесен тынычландырып:

— Тавышланма, Гөрител, борчылма, ничек тә бер әмәлен табарбыз әле,— дигән.

Әти-эниләре йокыга киткәч, малай әкрен генә караватыннан торган да, бишмәтен киеп, ишегалдына чыккан. Шул вакыт болытлар арасыннан ялтырап ай күренгән, аның тоныкл көмеш яктысында җирдәге чуерташлар җемелдәшеп киткәннәр, ди. Һәнзил иелгән дә тиз-тиз шуларны җыя башлаган, кесәләре кабарганчы тутырган. Өйгә кергәч, Гөрителгә:

— Хафаланма, сеңелкәш, тынычлап йокла, өметсез шайтан,— дигән.

Шулай дигән дә үзе дә караватына менеп яткан.

Үги аналары, таң атар-атмас бүлмәгә кереп, Һәнзил белән Гөрителне йокыларыннан уяткан.

— Торыгыз, ялкаулар, урманга барасы бар, утын хәстәрләргә кирәк,— дигән.

Аннары балаларның икесенә дә берәр сынык ипи тоттырып:

— Менә сезгә юлда капкаларга ризык. Тик карагыз аны, вакыт җитмичә ашамагыз, төшкегә бүтән бернәрсә дә юк,— дигән.

Гөрител ипи телемен алъяпкыч астына яшергән. Абыйсы кесәләренә чуерташ тутырганлыктан, Һәнзилнекен дә үзенә алган.

Бер заман җыйнаулашып урманга киткәннәр болар. Һәнзил бераз барган саен туктала да, артына борылып, өйләре ягына карый икән. Әтисе:

— Нәрсә каранасың, Һәнзил, нигә һаман артка каласың? Авызыңны ачып барма, атла! — дип кычкырган.

— Әй, әти,— ди икән Һәнзил,— ак песиебез баласына карыйм мин шулай. Әнә, өй түбәсенә менеп утырган да, минем белән саубуллашмакчы булып, тәпиен болгый.

Үги анасы:

— Һай, тинтәк, нинди песи баласы булсын ди ул, морҗада иртәнге кояш нурлары шулай чагыла лаба-са,— дигән.

Бернинди дә песи баласы күрмәгән, билгеле, Һәнзил, шулай туктала-туктала юл буена кесәсендәге ялтыравык чуерташларны ташлый барган. Карурман уртасындагы куе чытырманлыкка җиткәч, этиләре:

— Ягез әле, балалар, тиз-тиз генә коры-сары җыегыз. Сезгә җылынырга учак ягып җибәрербез,— дигән.

Һәнзил белән Гөрител коры-сарыдан зур чүмәлә өеп куйганнар. Утыннарга ут кабынып, учак дөрләп яна башлагач, үги аналары:

— Балалар, учак янына утырып ял итегез. Без шушы тирәдә утын кисәрбез, җитәрлек хәстәрләгәч, үзегезне килеп алырбыз,— дигән.

Шулай итеп, Һәнзил белән Гөрител учак янында утырып калганнар. Төш җиткәч, һәркайсы үзенең ипи сыныгын алып ашаган. Балта тукылдаган тавыш һаман ишетелеп торганга, эти әле утын кисә икән, дип уйлаганнар. Ләкин ул балта тавышы булмаган. Корыган агач ботагына асып куелган тукмак җилдә селкенеп ары-бире бәрелә, шул шакылдап тора икән. Утыра торгач балалар тәмам алҗыганнар, йокыга киткәннәр. Йокыларыннан уянганда инде караңгы төн җиткән булган. Гөрител:

— Бу чытырманлыктан чыгу юлын ничек табарбыз инде? — дип, еларга ук тотынган. Һәнзил, аны юатып:

— Тагын бераз гына, ай калыкканчы гына сабыр ит инде. Аннары кайтыр юлны да табарбыз,— дигән.

Тулган ай калыккач, Һәнзил сеңелесен җитәкләгән дә иртән юл буе сибеп килгән чуерташларга карый-карый, алга атлаган. Чуерташлар ай яктысында өр-яңа көмеш тәңкәләр кебек ялтырый, балаларга юл күрсәтә икән. Төне буе барганнар мескенкәйләр, таң беленгәндә генә өйләренә кайтып җиткәннәр. Ишек шакыганнар икән, үги аналары килеп чыккан. Ул, Һәнзил белән Гөрителне күргәч:

— Карасана бу юньсезләрне, урманда шулай озак

йоклыйлармыни? Өйгә кайтырга исәбегездә дә юк икән сезнең,— дип сукранып маташкан.

Этиләре бик-бик сөенгән, балаларының урманда ялгыз калуларына төне буе хафаланып чыккан икән.

Ләкин күпмедер вакыт үткәч, утынчының хәл-әхвәлләре тагын начарланып киткән, өйләрендә бер көнлектә ризык калмаган. Шулай бер кичне йокларга яткач, хатын иренә:

— Тагын бар булганын ашап бетердек. Иртәгә нибары ярты ипиебез калды, аннары хет ачка үл. Балаларны кая булса да олактырмый чара юк. Бу юлы карурманның иң уртасына, кеше аягы басмаган җиренә илтеп ташларга кирәк. Өйгә кайтыр юлны яңадан табалмаслык ешлыкка,— дигән.

Ата йөрәген тагын ачы хәсрәт кимерә башлаган. Үзе, соңгы сыныгыңны балалар белән уртаклашу әйбәтрәк, дип уйлый икән. Ләкин хатыны аны тыңларга да теләмәгән, сүз әйтергә дә ирек бирмәгән, битәрләгән дә битәрләгән.

Балалар бу юлы да уяу ятканлыктан, үги аналары сөйләгәннәрнең барысы да колакларына кергән. Картлар йокыга киткәч, Һәнзил тагын караватыннан сикереп торган да тагын чуерташлар җыярга чыкмакчы булган. Ләкин явыз хатын бу юлы ишекне балалар ача алмаслык итеп бикләгән икән, шуңа күрә малай берни эшли алмаган. Шулай да үзе:

— Елама, Гөрител, тынычлап йокла, өметсез шайтан гына,— дип сеңелесен юаткан.

Үги ана таң атар-атмас балалар янына кереп, караватларыннан җилтерәтеп торгызган. Икесенә дә берәр сынык ипи тоттырган, ләкин ул сыныклар беренче тапкыр биргәндәгедән дә кечерәк булганнар. Һәнзил кесәсендәге әнә шул ипи сыныгын чеметкәләп, әледән-әле туктый-туктый, валчыкларын юл буена ташлый бара икән.

— Нигә дип адым саен тукталасың син, Һәнзил? — дигән атасы.— Як-ягыңа каранмыйча гына атла тизрәк!

Малай:

— Күгәрченнәремә карыйм, алар, әнә, өй түбәсенә кунганнар да миңа нидер әйтергә телиләр сыман,— дигән.

— Һай, тинтәк,— дигән үги анасы,— нишләп синең күгәрченнәрең булсын ди ул? Иртәнге кояш нурлары морҗада шулай чагыла лабаса.

Тик Һәнзил ипи валчыкларын сиздерми генә һаман юлга ташлый барган. Бу юлы балаларны карурманның

иң уртасына алып кергәннәр. Аларның монда гомер булганнары юк икән. Зур итеп учак ягып җибәргәч, үги аналары:

— Балалар, менә шушында гына уйный торыгыз. Арысагыз, бераз ятып алырсыз. Без шушы тирәдә генә утын кисәрбез, җитәрлек хәстәрләгәч, кичкә таба сезне үзебез килеп алырбыз, бергәләп кайтырбыз,— дигән.

Абыйсының үз ипиен чеметкәләп юл буе ташлап баруын абайлаган Гөрител, төш җиткәч, бар хәзинәсен Һәнзил белән уртаклашкан. Тик нәни кыерчык аларның кече телләренә дә йокмаган. Шулай да бераздан балалар йокыга киткән. Караңгы төшсә дә, алар янына килүче булмаган. Ярты төн җиткәч кенә уянганнар бичаралар. Һәнзил, сеңелесен юатып:

— Ай калыкканчы көтик инде, Гөрител. Ай яктысында без юлга ташлап килгән ипи валчыклары күренер, шулар өйгә кайтырга да булышыр,— дигән.

Ай калыккач юлга чыкканнар икән, җирдә бер генә ипи валчыгы да күренмәгән. Кошлар аларны көндез үк чүпләп бетергәннәр, ди. Һәнзил Гөрителгә:

— Кайгырма, табарбыз кайтыр юлны, барыбер табарбыз,— дигән.

Ләкин таба алмаганнар юлны: төне буе барганнар, икенче көнне дә кичкә кадәр атлаганнар, тик һаман да урманнан чыга алмаганнар. Ул арада бик каты ашыйсылары килә башлаган. Пешеп тә җитмәгән бер-ике җиләктән башка көне буе бернинди ризык капмаган бит алар. Тәмам хәлдән таеп, бер генә адым атларлык та хәлләре калмагач, бер агач төбенә ятканнар да йокыга киткәннәр.

Аларның өйдән чыгып китүләренә инде өч көн тулган. Малай белән кыз әле һаман юл табарга өметләнәләр икән, ләкин үзләре һаман урман эченәрәк кенә керә баралар, ди.

Шулай беркөнне төш вакыты җиткәндә балалар агач ботагына кунган кардай ап-ак бер матур кош күргәннәр. Шундый да өздереп сайрый икән, ди, ул кош: Һәнзил белән Гөрител, туктап, аның чутылдавын тыңлый башлаганнар. Кошкай исә канатларын җилпеп җибәргән дә очып киткән. Һәнзил белән Гөрител, аның артыннан барып, кечкенә генә бер йорт янына килеп чыкканнар. Кош шушы өйнең түбәсенә төшеп кунган икән. Якынрак барсалар, ни күрсеннәр: өй үзе ипидән салынган, түбәсе тәмле перәннекләр белән ябылган, ә тәрәзәләре үтә күренмәле шикәрдән, ди. Һәнзил сеңелесенә:

— Әйдә, болай булгач, рәхәтләнеп бер сыйланып

алыйк инде. Мин түбәсен кимерермен, ә син, Гөрител, тәрәзәсен яла, бик тә тәмле булырга охшый,— дигән.

Һәнзил өй түбәсенең бер «тактасын» куптарып алып ашый башлаган. Гөрител тәрәзә пыяласын ялаган. Шулчак өйдән:

— Кем түбәмне җимерә,
Тәрәзәмне кимерә? —

дигән чәрелдәвек тавыш ишетелгән.

Балалар:

— Җил китергән өндер бу,
Бәхет ачкан көндер бу,—

дип җавап биргәннәр.

Һәнзил белән Гөрител шулай дигәннәр дә, ачыгулары соңгы чиккә җиткәнлектән, өйнең түбәсен, тәрәзәсен кимерә башлаганнар. Малайга йортның перәннектән ябылган түбәсе бик ошаган, ул аңардан олы-олы калҗалар куптарып ала икән. Гөрител исә тәрәзәнең шикәрдән коелган зур гына бер өлгесен кулына төшергән дә суыра башлаган. Шул вакыт йортның ишеге ачылып киткән, аннан, кәкре таягына таянып, картаеп, шәлперәеп беткән бер карчык килеп чыккан. Һәнзил белән Гөрител куркуларыннан кулларындагы сыныкларын җиргә төшереп җибәргәннәр.

Карчык, башын чайкый-чайкый:

— Төкле аягыгыз белән, матурларым! Нинди җилләр ташлады соң сезне монда? Өйгә керегез, бернигә дә мохтаҗлык кичермичә, рәхәтләнеп яшәгез! — дигән, ди.

Карчык малай белән кызны кулларыннан әләктереп алган да өенә алып кергән. Шунда ук өстәлгә тәмле-тәмле ризыклар: сөт, шикәр белән чикләвек төше сибелгән алма бөккәннәре тезеп куйган. Аннары ап-ак җәймә ябылган ике түшәк әзерләгән. Һәнзил белән Гөрител шушы йомшак урыннарга менеп ятканнар да, оҗмахка әләктек, ахры, дип, татлы йокыга талганнар.

Ягымлы булып кыланса да, бу карчык явызлардан да явыз сихерче икән. Адашкан балаларны шулай алдалап кулга төшерү өчен, ул өен юри ипи белән перәннектән генә салдыра, аннары тозакка эләккән сабыйларны берәм-берәм пешереп ашый икән. Мондый көннәр аның өчен чын-чыннан бәйрәм булган, ди. Сихерченең күзләре куянныкыдай кып-кызыл икән, шуңа ул ерактан бик начар күргән, аның каравы бик яхшы ишетә, кешеләрнең килгәнне сизгер җанвар шикелле әллә кайдан белеп ала икән. Һәнзил белән Гөрител янына ук килеп баскач, сихерче карчык эченнән бик сөенгән, мыскыллы

көлемсерәп: «Асылкошлар кулымда хәзер, күпме тырышсалар да кача алмаслар»,— дип сөйләнгән.

Явыз карчык балалар йокыдан уянганчы, таң атмас борын ук торган да рәхәтләнеп яткан сабыйларның алсу битләренә карап: «Менә дигән тәгам булачак болар»,— дип мыгырданган. Аннары корышып беткән кыскычтай куллары белән Һәнзилне эләктереп алып абзарга сөйрәп чыккан да шундагы тимер читлеккә ябып, ишеген шартлатып бикләп куйган. Малай күпме генә кычкырса да, ярдәмгә килүче күренмәгән. Аннары карчык Гөрител янына килгән, аны төрткәләп уяткан да:

— Тор, ялкау, су алып кайт та абыеңа тәмле-тәмле әйберләр пешер. Әнә, абзарда читлектә утыра ул. Бик әйбәтләп симертергә кирәк үзен, аннары мин аны кыздырып ашармын,— дигән.

Гөрител үксеп еларга тотынган, ләкин елаудан ни файда? Теләсә-теләмәсә дә, явыз сихерченең кушканнарын үтәргә туры килгән кызга. Шул көннән алып мескен Һәнзил өчен иң тәмле ашлар пешерелгән, ә Гөрителгә суырылып ташланган кысла ботыннан башка берни дә эләкмәгән. Сихерче карчык һәр иртәне абзарга чыга да:

— Һәнзил, кая, бармагыңны суз әле, симерәсеңме икән, карыйк бер,— дип эндәшә икән.

Һәнзил исә аңа бармагын түгел, нинди дә булса берәр сөяк суза, ди. Карчык, яртылаш сукыр күзләре рәтләп күрмәгәнлектән, аны Һәнзилнең бармагы дип белә, малайның һаман да тазармавына гаҗәпләнә икән. Дүрт атна үтеп киткән шулай, тик Һәнзил әле һаман шыр сөяк кебек, ди. Сихерченең сабырлыгы төкәнгән, бүтән түзәрлеге калмаган.

— Әй, Гөрител,— дип кычкырган ул кызга.— Тиз генә су алып кайт әле. Арыграк булса да, Һәнзилне иртәгә кыздырып ашыйм инде,— дигән.

Су ташыганда ничек кенә өзгәләнмәгән мескен Гөрител, елаган да елаган.

— Урманда ерткыч җанварлар да тотып ашамады ичмасам үзебезне! — дип иңрәгән.

Явыз карчык:

— Шыңшуыңнан тукта, барыбер кем дә ярдәм итә алмаячак,— дип кычкырган.

Гөрител иртә таңнан казан асарга тиеш икән. Тик сихерче карчык аңа:

— Башта ипи пешереп алыйк әле. Мичне кыздырып куйдым инде, камыр да издем,— дигән.

Шулай дигән дә мескен кызны ялкын телләре биешеп торган мич янына төрткәләп китергән.

— Бар әле, мич эченә кер дә ташларны карап чык. Әйбәт кызган булсалар, ипиләрне куярбыз,— дигән.

Тик бу — явыз сихерченең хәйләсе генә икән. Гөрител керү белән, мич капкачын ябып куймакчы, берьюлы кызны да куырып ашамакчы икән нияте. Ләкин Гөрител карчыкның уен бик яхшы чамалаган.

— Нишләргә икән соң? Мин бит әле мичкә ничек итеп керәсен дә белмим,— дигән ул.

Сихерче карчык:

— Тинтәк нәмәрсә, мич авызының нинди зур икәнен күрмисеңмени? Син түгел, мин үзем дә иркенләп сыям аңа, карап тор менә! — дигән дә башын мичкә үк тыгып күрсәткән.

Шулчак Гөрител карчыкны бар куәтенә мич эченә этеп җибәргән, аннары тиз генә тимер капкачны ябып, келәсен дә төшереп куйган.

Менә сиңа бәйрәм! Явыз карчык коточкыч тавышлар чыгарып уларга тотынган икән, Гөрител өйдән үк чыгып качкан. Шәфкатьсез сихерче исә җәзаның ачысын татыган: үзе яккан мичтә үзе куырылган.

Гөрител, өйдән чыгуга, абыйсы янына йөгергән, тимер читлекнең ишеген ачкан да:

— Котылдык, Һәнзил, сихерче карчык дөмекте,— дип кычкырган. Һәнзил читлектән атылып чыккан. Әй, сөенешкәннәр болар: бер-берсен кочаклап сикерешкәннәр, уйнаганнар! Куркыр нәрсә юк ич инде хәзер! Икәүләп сихерченең өенә кергәннәр. Бүлмәләрнең почмагы саен энҗе-зөбәрҗәтләр, асылташлар тутырылган сандыклар тора икән. Һәнзил:

— Болар сиңа чуерташ түгел инде,— дип, кесәләренә сыйган кадәр асылташ тутырган.

Гөрител:

— Миңа да тегесен-бусын бераз алырга ярыйдыр,— дигән дә сандыклардагы хәзинәне сыйган кадәр алъяпкычына бушаткан.

— Хәзер китсәк тә ярый инде, бу сихерчеләр урманыннан тизрәк ычкынуың хәерле,— дигән Һәнзил.

Бер сәгать барганнар шулай, ике сәгать барганнар, бер заман бик зур, бик киң елга буена килеп чыкканнар. Һәнзил:

— Елганы ничек кичәрбез икән инде? Басма-фәлән дә юк, күпере дә күренми,— дигән.

— Көймәләр дә күзгә чалынмавы гаҗәп. Әнә тегендәрәк бер ак үрдәк йөзә йөзүен. Үтенеп сорасак, бәлки

аргы якка чыгарып куяр? — дигән Гөрител. Аннары, үрдәккә эндәшеп:

— Үрдәккәем, коткарсана,
Без — Гөрител белән Һәнзил.
Басма да юк, күпер дә юк,
Аргы якка чыгарчы син! —

дигән.

Йөзеп килгән бит үрдәк яр буена. Һәнзил кошкайның аркасына менеп атланган да сеңелесенә:

— Әйдә, син дә утыр! — дигән.

Тик Гөрител:

— Юк, юк, алай үрдәккә авыр булачак. Башта беребезне чыгарып куйсын, аннары икенчебезне,— дигән.

Игелекле үрдәк теләкләрен төгәл үтәгән. Балалар икесе дә аргы якка хәвеф-хәтәрсез чыгып, юлларын дәвам иткәннәр. Баралар, баралар, барган саен урман танышрак булып тоела икән. Бер заман балалар алда үзләренең йортларын да күргәннәр. Икесе дә йөгерә башлаганнар, куанышып өйләренә килеп кергәннәр дә әтиләренең кочагына ташланганнар.

Балаларын урманда калдырып кайтканнан бирле әтиләре бер генә минут та җанына тынычлык таба алмаган, үги аналары исә үлеп киткән, ди. Гөрител алъяпкычын чишеп җибәргән икән, идәнгә зыңгылдап энҗемәрҗәннәр, асылташлар коелган. Һәнзил дә, кесәләреннән алып, идәнгә учлап-учлап асылташ сипкән. Шулай итеп, бөтен кайгы-хәсрәтләре таралган аларның, бергәбергә рәхәт гомер кичерә башлаганнар.

Шуның белән әкиятебез дә тәмам. Әнә, бер тычкан йөгерә: шуны тотып алыгыз да тиресен тунагыз — менә дигән бүрек тектерерсез!

БАТЫР ТЕГҮЧЕ

Җәйге көннәрнең берсендә бер абзый тәрәзә каршында тегү тегеп утыра икән. Кәефе күтәренке булганга, эше дә әйбәт тәгәри, ди. Нәкъ шул чакта урам буйлап бер хатын үтеп бара икән, үзе әледән-әле:

— Әйбәт варенье сатам! Тәмле варенье сатам! — дип кычкыра, ди.

Сатучы хатынның тавышы тегүчегә бик ягымлы булып ишетелгән, ул үзенең ябык озын муенын тәрәзәдән сузып:

— Монда мен әле, кадерлем, товарыңны үзем алырмын,— дип кычкырган.

Сатучы авыр кәрзиннәрен күтәреп тегүче яшәгән өченче катка күтәрелгән дә аның алдына төрле-төрле вареньелар салынган чүлмәкләрен тезеп куйган. Тегүче аларның барысын да җентекләп карап, иснәп чыккан. Аннары хатынга:

— Вареньең миңа бик ошый. Дүрт мыскал үлчәп бир әле, кадерлем. Бәлки чирек кадак та артык булмас,— дигән.

Байтак әйберемне сатармын ахры моңа дип өметләнгән хатын, кәефе кырылып, тегүчегә сораганы кадәр варенье үлчәп биргән дә ачулы мыгырдана-мыгырдана китеп барган.

Шушы варенье беләкләремә көч, буыннарыма дәрман өстәсен иде, дип теләгән тегүче. Аннары шкафындагы ипидән зур гына бер телем кисеп алган да әлеге вареньены юка гына итеп шуның өстенә яккан. Тәмле булырга охшый үзе, рәхмәт төшкере, тик башта шушы куртканы тегеп бетерим инде, аннары рәхәтләнеп ашармын, дип сөйләнә-сөйләнә варенье яккан ипи телемен өстәленә куйган да үзе ашыга-ашыга киемен җөйли башлаган. Ул арада тәмле варенье исе бөтен бүлмәгә таралган. Әлегә кадәр стена, түшәмнәргә кунып ялкау гына арлы-бирле очып йөргән чебеннәр өерләре белән варенье ягылган ипи телеменә ябырылганнар. Кем чакырды соң әле сезне монда? — дип үртәлгән тегүче. Чыдамаган, әрсез кунакларны пыр туздырып куа башлаган. Ләкин чебеннәр немец телен аңламаганмы, тәмле сыйдан баш тартасылары килмәгәнме, тагын да ишәебрәк җыела барганнар. Эшләр болайга киткәч, тегүченең сабырлыгы тәмам төкәнгән, тиресеннән чыгардай булып ярсып, чүпрәк кисәге эләктергән дә әле сез шулаймыни, күрсәтим әле алайса күрмәгәнегезне, дип чебен өеренә шап берне! Рәхим-шәфкать кая ул, чүпрәген алып санаса, алдында җиде чебен тәгәрәшеп ята, ди.

Тегүче шундый батырлык күрсәтүенә үзе дә таң калып: менә мин нинди егет! дигән. Аннары бу хакта бөтен шәһәр белергә тиеш, дип уйлап алган да, ниятләгән эшен озын-озакка сузмыйча, үзенә билбау теккән. Аңа зур-зур хәрефләр белән: «Бер сугуда җидәүне егучы!» дигән сүзләр чигеп куйган. Һәй, нигә безнең шәһәр генә, бөтен дөнья белергә тиеш мине! дип уйлаган ул бераздан. Үз батырлыгы белән горурланудан йөрәге тәкә койрыгыдай лепер-лепер тибрәнә икән.

Тегүче билбавын буган да дөнья гизәргә ниятләп юлга җыенган. Чынлап торып, минем шөһрәтем бу остаханәгә генә сыймас хәзер, дип уйлаган, ди. Сәфәр чыгар

алдыннан, юлда ашарга берәр нәрсә тапмакчы булып, бүлмәсенең астын-өскә китергән, ләкин күгәреп беткән сыр кисәгеннән башка берни дә таба алмаган, ахыр чиктә шуны кесәсенә тыгып куйган.

Ишек алдына чыкса, ни гаҗәп: бер кошчык куаклар арасына, чытырманлыкка кергән дә шуннан котыла алмый тыпырчына икән. Тегүче кошчыкны кулына төшергән дә кесәсенә — әлеге сыры янына шудырган. Шуннан соң абзый кыю адымнар белән ерак юлга чыгып киткән.

Җиңел сөякле, хәрәкәтчән булганга, бер дә ару-талуны белмәгән тегүче. Бара-бара бер тау янына килеп чыккан бу. Тау башына менсә, анда чамасыз олы гәүдәле бер алып батыр утыра, ди. Бернигә исе китмәгәндәй, илтифатсыз гына кыяфәт белән, тирә-якны күзәтеп утырган алып янына тегүче кыю гына барган да:

— Хәерле көн, адәм баласы! Ни эш бетереп утырасың монда? Очсыз-кырыйсыз дөньяның берәр чиген күрергә тырышасыңмы әллә? Менә мин дә сәфәр чыктым әле, бәхетемне сынап карарга исәп. Бәлки миңа юлдаш булырсың? — дип эндәшкән.

Алып чирканган шикелле тегүчегә мәсхәрәле күз карашы белән текәлеп торган да:

— Хәчтерүш! Шушы мескенкәй дә сөйләнгән була бит! Йә, нәрсә чәрелдисең? — дигән.

— Кем мескендер бит әле,— дип җавап биргән тегүче.— Менә укы, надан булмасаң, кемлегемне белерсең аннары.

Курткасының сәдәпләрен ычкындырып, билбавын күрсәткән икән, алып: «Бер сугуда җидәүне егучы», дигән язуны укыган. Укыган да бик гаҗәпсенгән. Ул «җидене» тегүченең бер сугуыннан һәлак булган кешеләр дип уйлаган, мондый батырны санга сукмый ярамас, дип куйган. Шулай да башта ул тегүчене сынап карарга теләгән. Кулына бер таш алып бик каты кыскан да сыгып су чыгарган.

— Алай көчле булгач, син дә минем кебек ташны сыгып су чыгарып кара әле,— дигән алып.

— Шул да булдымы батырлык? Безнең өчен гадәти бер уен гына ич ул,— дигән тегүче.

Аннары кесәсендәге сыр кисәген кулына алган да учы белән изеп суын чыгарган. Шуннан соң алыпка:

— Күрдеңме инде,— синеке ише генә булмады ич! — дигән.

Алып ни әйтергә дә аптыраган, өтек кыяфәтле, җиңел сөякле тегүчедән мондый куәтне һич тә көтмәгән инде ул. Шулай да бирешергә теләмәгән, иелеп җирдән

бер таш алган да бар көченә һавага тондырган. Таш, күздән югалып, тәмам күренмәс булган, беравыктан гына җиргә килеп төшкән.

— Йә, гайрәт иясе, булдырып кара шулай,— дигән алып.

— Сүз дә юк, ярыйсы аттың. Ләкин синең ташың барыбер кире җиргә төште, ә менә мин җиргә әйләнеп төшмәслек итеп ыргытам хәзер,— дигән тегүче.

Кесәсеннән теге кошчыкны алган да һавага чөйгән бу. Кошкай ирекккә чыгуына шатланып, һаман саен югарырак күтәрелгән. Билгеле инде, ул әйләнеп кайтырга уйламаган да.

— Йә, ни әйтерсең, дускай? Осталыгым ошадымы? — дигән тегүче.

Таң калган алып:

— Чыннан да әйбәт ыргытасың икән,— дигән. Әмма үзе әле һаман сер бирергә теләмәгән.— Хәзер инде күпме йөк күтәреп бара алуыңны гына беләсем килә,— дип өстәгән.

Алып шулай дигән дә батыр тегүчене төбе-тамыры белән йолкынып ташланган бер юан имән янына алып килгән.

— Беләгең юан булса, әйдә, шушы имәнне урманнан алып чыгарга булыш әле миңа,— дигән.

— Хи-хи-хи, шул да булдымы кыен эш? — дип көлгән тегүче.— Әйдә, төп башын җилкәңә сал әле, мин ботак-чатаклы иң авыр, җайсыз җиреннән күтәрермен.

Алып батыр иңбашына имәннең төп башын салган, ә тегүче җайлы гына итеп бер ботак өстенә менеп атланган. Алыпның артына борылып карарга да чамасы юк икән — имән агачын да, әле тагын аның ябалдашына менеп кунаклаган тегүчене дә сөйрәп барырга туры килгән аңа. Тегүчегә ботак өстендә дөнья гизү күңелле дә, рәхәт тә икән, шуңа күрә аңа агач күтәреп баруы уен эш кенә булып тоелган. «Өч тегүче килеп керде капкадан...», дип җырлый-җырлый бара, ди. Ә алыпның исә шундый авыр йөкне сөйрәп килә-килә бер заман аяк атларлык та хәле калмаган. Бик гарьләнсә дә тегүчегә:

— Хәлем бетте, ташлыйм агачны,— дип кычкырырга мәҗбүр булган.

Тегүче кунаклаган ботагыннан шундук җиргә сикереп төшкән дә, юл буе шулай күтәреп баргандай, ике куллап агач ботакларына килеп ябышкан. Үзе алыпка:

— Мин, мин, дисең, шундый зур гәүдәле үзең, тик алай да шушы пүчтәк агачны да күтәреп бара алмадың,— дигән.

Шуннан соң инде алар юлларын бергәләп дәвам иттергәннәр.

Бервакыт зур гына чия куагы яныннан үткәндә, алып җимешләре алсуланып пешкән таза ботакларны җиргә кадәр бөгеп төшергән дә тегүчегә тотып торырга кушкан.

— Үзең дә тәмле җимешләр белән сыйлан,— дигән ул иптәшенә.

Ләкин тегүченең бөгелгән куакны тотып торырлык та куәте юк, билгеле. Шуңа күрә, алып кулын ычкындыру белән, чия агачы тураеп, ботакка ябышкан тегүчене һавага чөйгән. Тегүче шактый биек очып менгән дә дөпелдәп җиргә килеп төшкән. Шулай да бәхете бар икән үзенең, бер җире дә имгәнмәгән. Алып батыр:

— Син нәрсә? Әллә шул ботакларны бөгеп торырлык та хәлең юкмы?— дигән.

— Хәл дигәнең кирәгеннән ашкан анысы, бер сугуда җиде җанны дөмектерүчегә ботак бөгеп тору чүп кенә ул. Аучыларның мылтык атканын ишетмәдеңмени? Ядрә тимәсен дип агач аша сикердем мин. Яле, булдыра алсаң, син дә минем кебек сикереп кара,— дигән тегүче.

Алып батыр да җитезлеген сынап карамакчы булган икән, ләкин биек куак аша сикереп чыга алмаган, ботакларга эләгеп, һавада асылынып калган. Шулай итеп, бу юлы да тегүче өстен чыккан. Алып юлдашына:

— Син чыннан да батыр икәнсең! Әйдә, минем белән тау куышына барыйк, кунак булырсың,— дигән.

Тегүче карышып тормаган, тегеңә ияреп киткән. Тау куышына керсәләр, ни күрсен: учак тирәли берничә алып утыра, имеш. Һәркайсының кулында кыздырылган бер бөтен сарык түшкәсе, алыплар шуны умыралар гына, ди. Тегүче як-ягына каранган да, монда минем бүлмәгә караганда иркенрәк икән шул, дип уйлап алган. Аннары иптәше, менә шушында йокларсың, дип тегүчегә түшәк җәелгән караватк күрсәткән. Әмма ятак аңа иләмсез зур икән, шуңа күрә тегүче күрсәтелгән урынга ятмаган, караңгыда бер почмакка барып чүмәшкән. Ярты төн җиткәч, теге алып шыпырт кына торган да, инде бу йоклагандыр, дип бер зур тимер таяк белән селтәнеп тегүче ятагына шундый итеп китереп сылаган, караватчелпәрәмә килгән, ди. Чикерткәдәй сытылды инде бу, дип уйлаган, ди, алып.

Алыплар иртә таңнан торганнар да, кунак турында бөтенләй онытып, урманга киткәннәр. Кичен кайтканда тегүче аларны берни булмагандай шат йөз белән каршы-

лаган, кәефе күтәренке, күңеле көр икән. Бу хәлне күргән алыплар куркуга төшкәннәр, барыбызны да үтереп ташламагае бу, дип уңга-сулга карамыйча, куышларын ташлап качканнар, ди.

Тегүче исә яңадан юлга чыккан, күзе кайсы якка караса, шул якка барган да барган. Көн барган, төн барган бу, шулай итеп ниндидер бер король сараена килеп җиткән. Көн буе йөри-йөри ярыйсы ук арыган икән, мондагы йомшак чирәмгә утыруы белән йокыга да киткән. Шулай йоклап ятканда моның янына кешеләр җыелган, барысы да кызыксынып тегүчене күзәтәләр икән. Билбавындагы «Бер сугуда җидәүне егучы» дигән сүзләрне укыгач, болар:

— Ай-яй, ил тыныч чакта нишләп йөри икән монда бу баһадир? Мөгаен, бик көчле сугыш чукмарыдыр бу,— дип тел шартлатканнар.

Аннары билгесез батыр турында корольгә хәбәр итеп:

— Әгәр дә мәгәр сугыш-фәлән чыга калса, бик кирәкле, бик файдалы кеше бит бу, һич тә кулдан ычкындырырга ярамый аны,— дигәннәр.

Бу фикер корольгә дә ошаган. Ул хезмәтчеләреннән берәүне тегүче янына җибәреп, уянуы белән аны король гаскәрендә хезмәткә калырга күндерергә кушкан.

Әлеге хезмәтче йоклаган тегүче янына килеп, тын алырга да кыймыйча, тегенең уянганын көтеп басып тора икән. Күпмедер шулай ятканнан соң, бер заман тегүче киерелә башлаган, аннары күзләрен ачкан. Король хезмәтчесе шунда ук йомышын үтәргә ашыккан.

— Үземнең дә килүем нәкъ менә шуның өчен иде. Шушы минуттан король хезмәтенә әзермен,— дип җавап биргән тегүче.

Сарайда аңа зур хөрмәт күрсәткәннәр, баһадирның үзенә аерым бер бүлмә биргәннәр. Билгесез килмешәкнең кинәт болай күтәрелүе король вәзирләренең көнчелеген уяткан. Алар тегүчене тотып ашардай булганнар, күңелләреннән аның җәһәннәмгә олагуын теләгәннәр. Үзара:

— Киләчәктә әллә нинди хәлләр булуы ихтимал. Әгәр дә мәгәр, гауга кубып, аның белән даулаша башласак, барыбызны да тотып дөмбәсләячәк бит бу. Бер сугуда «әһ» тә итми җидебезне тәгәрәтәчәк, арабыздан кем дә аңар каршы тора алмаячак,— дип пошыналар икән.

Шулай уйлашканнар, киңәшкәннәр дә, бергәләшеп король алдына килеп, үзләрен хезмәттән азат итүне үтенгәннәр.

— Анының белән бергә хезмәт итә алмыйбыз, бер сугуда җидәүне ега торган кешегә беркем дә сүзката алмаячак,— дигәннәр.

Король тәмам хафага төшкән. Билгесез бер кеше аркасында үзенең ышанычлы, тугрылыклы хезмәтчеләреннән колак кагарга бер дә теләмәгән, шунлыктан тегүчене бүтән беркайчан күзгә күренмәслек җиргә олактырырга ният кылган. Ниятләвен ниятләгән, тик сәбәпсезнисез кинәт кенә баһадирны эштән чыгарырга да батырчылык итмәгән. Билгесез батырның үч итеп үзен дә, бүтән аксөякләрне дә кырып ташлавыннан, тәхеткә менеп утыруыннан курыккан ул. Тегеләй дә, болай да уйлап караган король, аннары бер карарга килеп, тегүчене чакырырга кеше җибәргән. Әгәр ул чыннан да шундый батыр икән, корольнең аңа бер йомыш кушарга нияте бар, дип әйтергә боерган.

Король урманнарының берсендә ике пәһлеван яшәгән икән. Алар кешеләрне талап, үтереп, йорт-җирләрен яндырып, бик күп бәла-каза китергәннәр, ди. Юлбасарларга каршы чыгарга берәү дә батырчылык итмәгән, чөнки беркемнең дә якты дөнья белән бәхилләшәсе килмәгән. Шушы ике пәһлеванны җиңә алса, король тегүчегә бердәнбер кызын ярәштерергә, өстәвенә бирнәгә ярты мәмләкәтен бүләк итәргә вәгъдә биргән. Ярдәм кирәк булса, үзең белән кораллы йөз җайдак алырсың, дигән дә, вәгъдәсен раслап, ант эчкән.

Миндәй егеткә король кияве булу начар булмас иде булуын, гүзәл кыз белән ярты мәмләкәт теләсә кемгә тәтеми, дип уйлаган тегүче. Аннары корольгә:

— Баш өсте, галиҗәнап. Пәһлеваннарны җиңәчәгемә тамчы да шигем юк, кораллы җайдакларың да кирәкми. Бер сугуда җиде җанны теге дөньяга олактырган баһадирга ике юлбасар гына нәрсә ул?! — дигән.

Тегүче юлга чыккан. Теләмәсә дә, король әмере буенча, аны кораллы йөз җайдак озата барган. Пәһлеваннар яшәгән урманга килеп җиткәч, тегүче җайдакларны туктатып:

— Ары барып мәшәкатьләнеп йөрмәгез, шушында гына торыгыз, юлбасарлар белән исәп-хисапны үзем генә өзәрмен,— дигән.

Урман эченә ялгызы кереп киткән тегүче. Бераздан тукталып тирә-ягына карана торгач, пәһлеваннарны да күреп алган. Бер агач төбендә йоклап яталар икән болар. Җил-давыллар уйныймыни, гырылдауларыннан тирә-яктагы агачларның юан-юан ботаклары шаулыйшаулый чайкала, ди. Тегүче озын-озак уйлап тормаган,

ике кесәсенә дә ташлар тутырган да тиз генә агач башына, пәһлеваннар йоклап яткан турыга үрмәләгән. Биек агачның урта бер җиренә җиткәч, җайлы гына бер ботакны сайлап, шунда әйбәтләп утырган да пәһлеваннарның берсенә таш ыргытырга тотынган. Байтак вакыт сизмәгән моны пәһлеван. Бер заман күзләрен ачкан да, иптәшенең кабыргасына төртеп:

— Төшләнеп ятасыңмы әллә? Нигә әле һаман миңа сугасың да сугасың? — дип ачуланган.

— Үзең төш күреп ятасыңдыр, нишләп сиңа сугыйм ди мин? — дигән икенчесе.

Пәһлеваннар яңадан йокыга киткәннәр. Хәзер инде тегүче пәһлеваннарның икенчесенә таш ыргыта икән.

— Ни дип син мине болай дөмбәслисең әле? — дип ярсыган хәзер икенче пәһлеван.

— Нишләп сугыйм ди мин сиңа, аптыратма әле! — дигән беренчесе, йокы аралаш ачулы мыгырданып.

Көне буе йөреп икесе дә нык арыган булганга, шулай бераз даулашып алганнар да тагын күзләре йомылган боларның. Тегүче яңадан уенын дәвам иттергән, кесәсеннән иң зур ташны сайлап алган да, селтәнеп беренче пәһлеванның күкрәгенә тондырган.

— Чамадан аштың инде!

Беренче пәһлеван шулай үкереп, корт чаккандай сикереп торган да иптәшен бар куәтенә агачка китереп орган икән, имәннең кәүсәсе зеңгелдәп киткән, ди. Икенчесе дә җавапсыз калмаган. Алар шулай икесе дә бик каты ярсыганнар, юан-юан агачларны төбе-тамырлары белән суырып алалар да бер-берсен дөмбәслиләр икән. Икесе тиң җансыз калып җиргә тәгәрәгәнче сугышканнар пәһлеваннар. Шуннан соң гына тегүче куначасыннан җиргә сикереп төшкән. Үзенә үзе: бәхетем бар икән әле, мин утырган агачны йолкып алсалар, тиен кебек агачтан агачка сикереп, сыпыртырга туры килгән булыр иде. Дөрес, җитезлек дигән нәрсә бездә бар инде барын, берәр җае табылыр иде табылуын, дип кодрәтләнә икән. Аннары, кылычын алган да бу, бер-бер артлы пәһлеваннарның күкрәкләренә кадаган. Шуннан соң гына урманнан чыккан, үзен көтеп торучы җайдакларга:

— Корольнең боерыгы үтәлде, икесен дә дөмектердем. Үземә дә җиңел булмады булуын. Агачлар йолкып алып, шулар белән каршы тормакчылар иде, эшләре пешмәде. Бер сугуда җидәүне егучыга кем каршы тора алсын ди инде!

— Яраландыңмы соң? — дип кызыксынган җайдаклар.

Тегүче:

— Барысы да тәртиптә, чәч бөртегемә дә кагыла алмадылар,— дип җавап биргән.

Җайдаклар аңа ышанырга да, ышанмаска да белмичә, сөйләгәннәре чынмы икән моның дип, урман эченә кереп киткәннәр. Андагы хәлләрне күргәч, хәйран калганнар. Пәһлеваннар чыннан да үз каннарына батып җирдә тәгәрәп ята, тирә-якта төбе-тамыры белән йолкынган агачлар ауный, ди.

Сарайга кайтып җиткәч, корольдән вәгъдәсен үтәвен таләп итә икән тегүче. Король исә ашыгып вәгъдә бирүенә үкенә башлаган, баһадирдан котылу өчен яңа хәйлә эзләргә керешкән.

— Кызымны, ярты мәмләкәтемне алыр өчен тагын бер батырлык эшләргә кирәк бит әле. Урманыбызда сыңар мөгезле коточкыч бер җанвар яши, ул безгә ел саен бик күп бәла-каза китерә. Менә шуны тотып читлеккә ябарга кирәк,— дигән король.

Тегүче күзен дә йоммый:

— Ике пәһлеваннан курыкмаганны, бер кыргый җанвардан куркаммы соң? Бер сугуда җидәүне егасы булса, бер хәл әле. Ичмасам, лаеклы эш табылды, дияр идем,— дигән.

Тегүче эшне озакка сузмаган, дилбегә белән балта алган да чытырманлыкка кереп киткән. Гаскәренә бу юлы да урман кырыенда көтеп торырга кушкан. Озак эзләргә туры килмәгән аңа, явыз мөгезборын үзе аның каршысына килеп чыккан. Килеп тә чыккан, үзенең гаять куркыныч мөгезе белән кадап үтермәкче булып өстенә дә ташланган моның. Ашыкма, ашыкма, ашыккан ашка пешкән, дигән тегүче. Үзе тукталган да мөгезборынның якынрак килгәнен көтә башлаган. Җанвар килеп җитеп мөгезе белән чәнчим дигәндә генә тегүче мәче җитезлеге белән янәшәдәге агач артына посып өлгергән, мөгезборын исә җан-фәрман чабып килгән уңайга очлы мөгезен төбенәчә агач кәүсәсенә батырган.

Батыруын батырган, тик мөгезен кире суырып алырга гына көче җитмәгән тинтәкнең, шулай итеп үзе әсир төшкән.

— Килеп каптыңмы, аңгыра малкай? Хәзер бу тозактан җиңел генә ычкына алмассың инде,— дип, тегүче яшеренгән урыныннан чыккан да башта җанварның муенына муенчак бәйләгән, аннары балтасын алып агач кәүсәсенә кадалган мөгезне кисеп ташлаган. Шуннан соң юашланган хайванны җитәкләп, сарайга алып кайтып киткән.

Ләкин король бу юлы да биргән вәгъдәсен үтәргә ашыкмаган, моңарга өченче йомыш кушкан.

— Урманда бер бик явыз кабан дуңгызы бар, шул мур кыргыры дөньяның астын-өскә китереп, тузынып йөри. Туйга хәтле менә шуны тотып кайт. Кирәк дисәң, ярдәмгә иң оста аучыларны сайлап ал,— дигән.

— Шул да булдымы эш, бу бит минем өчен балачага уены гына,— дигән тегүче.

Ярдәмгә бирелгән кешеләрдән дә баш тарткан. Аучылар моңа сөенгән генә, кабан дуңгызы белән элек тә очрашкалаганга, хәтәр ерткычка яңадан юлыгырга бер дә ашкынып тормаганнар.

Кабан дуңгызы тегүчене күреп алган да, үткен тешләрен ыржайтып, авызыннан күбекләр чәчә-чәчә аның өстенә ыргылган, егетне җиргә бәреп егып, эчәкләрен айкап ташларга теләгән. Якында гына бер абзар бар икән. Җитез тегүче куян тизлеге белән шунда элдерткән. Кабан дуңгызы аның артыннан ташланган. Ул арада тегүче тәрәзә аша тышка сикергән дә, абзарны урап чыгып, ишеген тыштан ябып та куйган. Шулай итеп, кеше өркетеп йөргән явыз җан үзе кулга төшкән, юан корсагы аңа тәрәзә аша сикереп чыгарга ирек бирмәгән.

Шуннан соң гына тегүче, кулга эләккән ул кыргый хайванны үз күзләре белән күрсеннәр өчен, аучыларны чакырып китергән.

Хәзер инде теләсә-теләмәсә дә, корольгә вәгъдәсен үтәргә, кызы белән ярты мәмләкәтен тегүчегә бирергә туры килгән. Әгәр король үзе алдында баһадир да, батыр да түгел, гап-гади бер тегүче басып торуын белсә, кәефе бөтенләй кырылган, җен ачулары чыккан булыр иде, билгеле.

Король өчен әллә ни шатлыгы булмаса да, утыз көн уен, кырык көн туен иткәннәр. Билгесез бер тегүче менә шулай король кияве булып киткән.

Атна үткән, ай үткән, ел үткән. Шулай бер заман король кызы иренең йокы аралаш: «Әй, син, шул куртканы тегеп, менә бу чалбарны җөйләп бир әле, юкса аршын таягы белән арканны каезлыйм хәзер»,— дип төшләнүен ишеткән. Ул шунда ук иренең кем булуын, нинди кешеләр арасында туып-үсүен аңлап алган.

Иртәгесен кыз нинди бәхетсезлеккә дучар булуын әтисенә дә ачкан, коткарыгыз мондый хәерче ирдән, гади тегүче хатыны булу миңа хурлык, дигән. Король кызын юатырга тырышып:

— Бүген төнлә йокы булмәгезнең ишеген бикләми калдыр. Тышкы якта ышанычлы хезмәтчеләрем торыр.

Алар ирең йокыга киткәч керерләр дә, аяк-кулларын бәйләп, аны алдан әзерләнгән корабка илтерләр, шул кораб алдакчыны җәһәннәм артына ук олактырыр,— дигән.

Кыз моңа шатланып риза булган. Әмма ата кешенең сүзләрен тегүченең корал йөртүчесе ишетеп калган. Хуҗасына җаны-тәне белән турылыклы булганлыктан, тозак коруларын вакытында килеп әйткән ул аңа.

— Язмыштан узмыш юк, исән булсак, бу бәладән дә котылырбыз,— дигән тегүче.

Кич булгач, һәр көндәгечә хатыны белән йокларга яткан тегүче. Беравыктан хатыны, ирен йокыга киткәндер инде, дип уйлап, урыныннан торган да йокы бүлмәсенең ишеген ачып куйган, аннары үзе яңадан түшәгенә килеп яткан. Шулчак юри генә йоклаганга сабышып яткан тегүче шәрран ярып:

— Әй, син, шул куртканы тегеп, менә бу чалбарны җөйләп бир әле. Юкса аршын таягы белән аркаңны каезлыйм хәзер. Бер сугуда җидәүне дөмектергән, ике пәһлеванны үтергән, җанкыяр мөгезборынны кулга төшергән, ерткыч кабан дуңгызын абзарга тотып япкан баһадир мин! Бүлмә ишеге артында калтыранып торучы козгыннар гына өркетә алмас! — дип кычкыра башлаган.

Тегүченең бу сүзләрен ишеткән хезмәтчеләр, куркуларыннан өнсез калып, артларыннан рәхимсез гаскәр куган шикелле, уңны-сулны белми кача башлаганнар. Бу хәлдән соң инде берәү дә тегүчегә каршы чыгарга батырчылык итмәгән. Шулай итеп, ул король булып калган, гомере буе тәхеттә утырган.

КОШТАПКАН

Яшәгән, ди, әүвәл заманда бер урман сакчысы. Көннәрдән бер көнне ауда йөреп кайтмакчы булган бу. Урманга җиткәч, бала елавына охшаган бер тавыш ишеткән. Аваз килгән якка таба бара торгач, бер биек агач янына җиткән. Күтәрелеп караса, агач башында бер нәни бала елап утыра, ди. «Шушы агач төбендә берәр ана баласы белән ял итәргә туктаган булгандыр да йокыга талгандыр, күрәсең. Нинди дә булса бер ерткыч кош ана итәгендәге сабыйны күргәндер дә атылып җиргә төшкәндер, бәбине эләктереп, һавага күтәрелгәндер, аннары нарасыйны шушы агач башында калдырып киткәндер»,— дип уйлаган урман сакчысы.

Ул агач башына менеп баланы алып төшкән дә: әгәр бу бәләкәчне өйгә алып кайтып, үземнең Ленхенем белән бергә тәрбияләсәм, ничек булыр икән? — дип уйлаган. Уйлаган эш уңган эш, дигәндәй, урман сакчысы бик тиз бер төпле карарга килгән — табылдык сабыйны өенә алып кайткан. Шул көннән ике бала гел бергә булганнар. Табылдык балага, аны үз әнисеннән кош урлап алып киткәндер, дип уйлаганга, «Коштапкан» исемен кушканнар. Ленхен белән Коштапкан бер-берләрен шулкадәр якын күргәннәр, бер-берләренә шулхәтле иялэшкәннәр, берсе икенчесен әз генә күрми торса да, сагына, боега башлыйлар икән.

Урман сакчысында аш пешерүче булып бер карчык та яши икән. Шулай бер кичне карчык пар чиләк белән коедан су ташый башлаган. Бер тапкыр яисә ике тапкыр гына түгел, әллә ничә тапкыр коедан су алып кайткан, ди, карчык. Моны күреп торган Ленхен:

— Занна әби, нигә әле шулхәтле күп су ташыйсың? — дип сорау биргән.

— Берәүгә дә серне ачмасаң, үзеңә генә әйтермен,— дигән карчык.

Ленхен ләм-мим эндәшмәскә сүз биргән. Шуннан соң карчык аңа:

— Иртәгә таң аткач, этиең ауга китүгә, су кайнатырга куям. Аннары кайнап торган казанга Коштапканны терелэй ташлап пешерергә уйлыйм,— дигән.

Икенче көнне урман каравылчысы таң беленер-беленмәс үк ауга җыенган. Ул киткәндә балалар караватларында ята икән әле. Шулвакыт Ленхен Коштапканга:

— Әгәр үзең ташламасаң, мин дә сине беркайчан ташламам,— дигән.

— Бүген дә, мәңге дә ташламам,— дип җавап биргән Коштапкан.

Шуннан соң Ленхен:

— Хәзер үзеңә бер сер әйтәм: кичә кич Занна карчык казанга бик күп су ташыды. Мин аңардан: шулхәтле су нәрсәгә кирәк, дип сорадым. Ул, әгәр серне берәүгә дә ачмасаң, үзеңә генә әйтермен, диде. Мин сүз биргәч, иртәгә иртән этиең ауга киткәннән соң казан тулы су кайнатам, аннары Коштапканны терелэтә шунда салып пешерәм, диде. Әйдә, хәзер тиз генә торып киеник тә, соңга калганчы, качып китик,— дигән.

Балалар урыннарыннан сикереп торганнар да, тиз генә киенеп, качып киткәннәр. Казандагы су кайный башлагач, карчык балалар йоклаган бүлмәгә кергән, Коштапканны алып чыгып, кайнап торган казанга

ташламакчы булган. Әмма түшәкләре янына килсә, ни күрсен, балаларның икесе дә юкка чыккан, ди. Карчык яман курыккан. Урманчы өйгә кайтып, балаларының юклыгын белгәч, ни әйтермен инде аңа? дип кайгыра башлаган. Тизрәк артларыннан куып җитәргә дә кире алып кайтырга кирәк үзләрен.

Карчык балаларны куарга өч хезмәтче җибәргән, тотып алыгыз да икесен дә өйгә алып кайтыгыз, дигән. Балалар урман кырыенда ял итеп утыралар икән. Алар өч хезмәтченең үзләренә таба йөгерә-йөгерә килгәннәрен ерактан ук күреп алганнар. Ленхен Коштапканга:

— Әгәр үзең ташламасаң, мин дә сине ташламам,— дигән.

Коштапкан аңа:

— Бүген дә, беркайчан да ташламам,— дип җавап биргән.

Шуннан соң Ленхен:

— Син гөлҗимеш куагы бул, ә мин аның чәчәгенә әйләнермен,— дигән.

Менә хезмәтчеләр урман буена да килеп җиткәннәр. Каранганнар, эзләнгәннәр, ләкин урман кырыенда үсеп утырган гөлҗимеш куагыннан, шул куактагы бердәнбер чәчәктән башка берни күрмәгәннәр. Балаларның эзләре дә суынган, ди. Хезмәтчеләр, монда эзләнүдән рәт чыкмас, дигәннәр дә кире борылганнар. Пешекче карчыкка:

— Күпме эзләсәк тә, гөлҗимеш куагы белән шуңардагы бер матур чәчәктән башка берни күрмәдек,— дигәннәр.

Карчык хезмәтчеләрне тиргәп:

— Тинтәкләр, гөлҗимеш куагын ботарлап ташларга иде, чәчәген өзеп алырга да өйгә алып кайтырга иде. Тиз генә кире барыгыз да мин кушканча эшләгез,— дигән.

Хезмәтчеләр качакларны икенче тапкыр эзли киткәннәр. Балалар бу юлы да аларны ерактан ук күреп алганнар. Ленхен иптәшенә:

— Коштапкан, әгәр үзең ташламасаң, мин дә сине ташламам,— дигән.

Коштапкан аңа:

— Бүген дә, беркайчан да ташламам,— дип җавап биргән.

— Алайса, син чиркәү бул, ә мин шуның тирәсендә үсә торган чәчәккә әверелермен,— дигән Ленхен.

Менә хезмәтчеләр килеп тә җиткәннәр. Каранганнар, эзләнгәннәр, ләкин ялгыз бер чиркәү белән шуның тирәсендә үскән чәчәктән башка берни дә күрмәгәннәр.

Моннан эзләүдән рәт чыкмас, өйгә кайтып китәргә кирәк, дип алар тагын кире борылырга мәҗбүр булганнар.

Өйгә кайткач, карчык хезмәтчеләрдән:

— Берни дә тапмадыгызмыни? — дип сораган.

Хезмәтчеләр:

— Юк. Анда ялгыз бер чиркәү белән шуның тирәсендә үскән чәчәктән башка берни дә күрмәдек,— дип җавап биргәннәр.

— Аңгыралар сез, чиркәүне җимерергә, ә чәчәкне өзеп алып кайтырга иде,— дип тиргәгән карчык аларны.

Бүтән чара калмагач, балаларны куарга карчык үзе чыккан, хезмәтчеләрен дә иярткән. Куа килүчеләрне балалар еракта ук күреп алганнар. Алар артыннан аксый-туксый атлаучы карчыкны да күргәннәр. Ленхен әйткән:

— Коштапкан, әгәр үзең ташламас булсаң, мин дә сине ташламам,— дигән.

Коштапкан:

— Бүген дә, беркайчан да ташламам,— дип җавап биргән.

— Алайса, син күл бул, ә мин шул күлдә йөзеп йөргән үрдәккә әверелермен,— дигән Ленхен.

Күл янына килеп җитү белән карчык балаларның хәйләсен аңлап алган. Тиз генә ярга сузылып яткан да, күлнең суын эчеп бетереп, үзенең явыз максатына ирешмәкче булган. Шулчак үрдәк уктай атылып карчык янына йөзеп килгән дә, томшыклары белән сихерчене чәченнән эләктереп алып, суга сөйрәп төшергән. Явыз карчык әнә шулай тончыгып үлгән. Ә балалар икәүләп өйләренә кайтып киткәннәр дә бергә-бергә шат, рәхәт гомер кичерә башлаганнар. Исән булсалар, бүген дә шулай тату яшиләрдер әле, мөгаен.

АЛТЫ ЯЛЧЫ

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер король. Сихерче карчык икән ул үзе. Аның дөньяда тиңсез матур кызы булган. Тик явыз карчыкның бар уе ничек итеп кешеләрне бәла-казаларга юлыктыру турында гына икән. Кызын яучылаган егетләргә башкарып чыга алмаслык эш куша, әгәр шуны үти алмасалар, башларын чаптырта икән. Шуңа да карамастан, кызның матурлыгы күпләрне һушыннан яздырган, аны сорап килүчеләр кимемәгән. Тик кияү булырга теләгән егетләрнең берсе дә кушылган йомышларны үти алмаган, сихерче карчык

та һичкемгә мәрхәмәт күрсәтмәгән: егетләрне җиргә тезләндерәләр икән дә башларын бүкәнгә салып чабып өзәләр икән.

Көннәрдән беркөнне әлеге кызның искиткеч гүзәллеге турында ишеткән бер король малае атасына:

— Әткәй, миңа шул кыз янына барырга рөхсәт ит, өйләнәсем килә,— дигән.

— Моңа минем мәңге ризалык бирәчәгем юк,— дигән атасы.— Анда барсаң, билгеле инде, мәгънәсез рәвештә харап кына булачаксың.

Әмма шул көннән соң король малае тәмам авыруга сабышкан, бөтенләй үлем хәленә җиткән, җиде ел буе урыныннан да тормаган. Иң оста табиплар да ярдәм итә алмаган аңа. Атасы бу хәлне күреп бүтән чара калмавын аңлаган, хәсрәтеннән нишләргә дә белми, улына:

— Бар соң алайса, бәхетеңне сынап кара инде. Башкача мин сиңа берничек тә ярдәм итә алмыйм,— дигән.

Малай бу сүзләрне ишетүгә урыныннан сикереп торган, сырхавы да шундук беткән, озакка сузмый, сөенә-сөенә юлга да кузгалган. Бара торгач, аңа бер басу аша үтәргә туры килгән. Шулчак юл буенда аның күзенә печән кибәнедәй бер нәрсә чалынган. Якынрак килсә, ни гаҗәп, җиргә бер адәм сузылып яткан, чүмәлә кебек кабарып торган нәрсә шуның корсагы икән. Таумыни!

Юлаучы килеп җитүгә, Таукорсак аягүрә торып баскан да:

— Әгәр сиңа ялчы-фәлән кирәк булса, ал мине үзең белән,— дигән.

— Мондый килбәтсез зат белән нишләрмен икән мин? — дигән король малае.

— Һәй, бу кадәресе генә нәрсә әле. Әгәр киерелеп җибәрсәм, хәзергедән өч мең тапкыр артык зурая алам мин,— дигән Таукорсак.

— Алайса, кирәк булуың да бик ихтимал,— дигән король малае.— Әйдә минем белән.

Таукорсак белән король малае ары таба юлларын бергә дәвам иттергәннәр. Күпмедер баргач, янә бер кеше очраган боларга. Җиргә колагын куеп нидер тыңлап ята, ди.

— Нишләп ятасың монда? — дип сораган король малае.

— Тыңлыйм әле менә,— дип җавап биргән әлеге кеше.

— Ә нәрсә тыңлыйсың соң?

— Дөньяда нинди-нинди хәлләр барын. Минем колак үләннәрнең ничек үсүен дә ишетә бит.

— Алайса әйт әле: гүзәл кызы булган король-карчык сараенда менә шушы минутта ниләр бар? — дип сораган король малае.

— Өйләнмәкче булган бер егетнең башын чапкан кылычның чыңлавы ишетелә,— дип җавап биргән Сизгерколак.

— Синең кирәк булуың бик ихтимал, әйдә, безгә иптәш бул,— дигән король малае.

Хәзер инде алар юлларын өчәүләп дәвам иттергәннәр. Күпмедер баргач, ике аяк тәпие күргән болар, ләкин аякларның дәвамы кайда икәнлекне һич шәйләрлек түгел, ди. Байтак барган болар аяклар янәшәсеннән, бер заман гәүдә янына килеп җиткәннәр. Тагын бераз баргач, бу галәмәт озын адәмнең башын да күреп алганнар.

— Кара әле, син озын арканнан да озынрак икәнсең ич,— дигән король малае.

— Әй, бу кадәресе генә нәрсә әле,— дигән Арканбуй.— Әгәр дә рәхәтләнеп бер киерелсәм, хәзергедән өч мең тапкыр озынрак, дөньядагы иң биек таудан да биегрәк була алам мин. Теләсәгез, сезгә хезмәт итәргә әзермен, үзегезгә ияртегез мине.

— Әйдә алайса иптәшкә,— дигән король малае,— кирәк булуың бик ихтимал.

Киткәннәр, ди, болар дүртәүләп. Күпмедер вакыт үткәч, юлчыларга күзләрен бәйләп утырган бер кеше очраган.

— Күзләрең авыртамы әллә? Я булмаса яктыдан чагыламы? — дип сораган король малае.

— Юк,— дип җавап биргән Зәһәркүз.— Күземдәге бәйләүне чишәргә ярамый миңа. Карашым бик зәһәр, күз салган һәр нәрсә шунда ук харап була. Кирәгем булыр дисәгез, хезмәт итәргә әзермен.

— Әйдә алайса, безгә иптәш булырсың,— дигән король малае.— Кирәк булуың да бик ихтимал.

Киткәннәр, ди, хәзер болар бишәүләп. Тагын күпмедер юл үткәч, боларга эссе кояш астында ятучы бер адәм баласы очраган. Үзе бөтен тәне белән дер-дер калтырый, тешләре тешкә шак-шок бәрелә, ди.

— Кояш кыздыруына түзәр чама юк, ә син салкында туңган кеше кебек дерелдисең,— дип гаҗәпләнгән король малае.

— Әй-йе-йе, табигатем шундый шул минем,— дип җавап биргән Калтыравык.— Эссерәк булган саен ныграк туңа барам, сөякләремә кадәр өши. Һава салкыная башласа, киресенчә, торган саен кызам. Менә шундый

инде хәлләрем: зәмһәрир суыкта уттай янам, ялкын уртасында бозга әйләнәм!

— Чыннан да, гаҗәп кеше икәнсең,— дигән король малае.— Әгәр иптәш булырга теләсәң, әйдә, ияр безгә.

Калтыравык та кушылган, ди, боларга. Бара торгач, озын муенын суза-суза тирә-якны күзәтүче бер адәм очраган. Король малае аңардан:

— Кая шулай бик төбәлеп карап торасың? — дип сораган.

— Күзләрем үткен, урман-кырлардамы, таулар-болыннардамы — кайда ни барлыгын уч төбемдәге кебек ап-ачык күреп торам,— дигән әлеге адәм.— Озын сүзнең кыскасы: бөтен дөнья хәлләре билгеле миңа.

— Теләсәң, әйдә безнең белән. Миңа иптәшкә нәкъ менә шундый кеше җитми иде,— дигән король малае.

Хәзер инде кәләш эзләүче егет үзенең алты иптәше белән туп-туры король-карчык яшәгән шәһәргә юнәлгән. Ул монда үзенең кем икәнен белдереп тормаган, бары тик:

— Әгәр гүзәлләрнең гүзәлен — галиҗәнап кызыгызны миңа кияүгә бирергә риза булсагыз, кушкан теләсә нинди йомышыгызны үтәргә әзермен,— дип кенә әйткән.

Сихерче карчык шундый чибәр егетнең тозакка килеп эләгүенә бик нык шатланган.

— Өч шартыма күнәргә туры килер сиңа, егеткәй. Әгәр шуларның өчесен дә җиренә җиткереп үти алсаң, мәмләкәтемнең хуҗасы да, кызымның ире дә булырсың,— дигән ул.

— Әмереңне көтәм,— дигән король малае.

— Кызыл диңгез уртасында йөзегемне төшереп җибәргән идем, менә шуны табып китерү беренче эшең булыр.

Король малае өенә кайтып киткән дә иптәшләренә:

— Беренче шарт җиңелдән түгел: Кызыл диңгез төбеннән карчыкның йөзеген табарга кирәк. Йә, нинди киңәш бирәсез? — дигән.

— Күрик әле: кай җирдәрәк ята икән ул,— дигән Үткенкүз һәм, чамасыз озын муенын сузып, диңгез төбен карый башлаган.— Әһә, бер очлы ташта эленеп тора икән йөзеге.

Арканбуй аларны диңгез буена алып килгән дә:

— Йөзекнең кайда икәнен күрсәм, сузылып кына алыр идем инде,— дигән.

— Эш шуңа гына терәлеп торса, булдырабыз аны хәзер,— дигән Таукорсак.

Шунда ук яр буена сузылып яткан да авызын суга

тидергән икән, дулкынланып торган диңгез суы, төпсез упкынга ургылгандай, Таукорсак авызына агып кереп югала башлаган. Ул шулай бөтен суны эчеп бетергән, диңгез төбе болын кебек коп-коры булып калган. Шуннан соң Арканбуй бераз иелгән дә, кулы белән сузылып, әлеге йөзекне эләктереп тә алган. Король малае беренче боерыкны үти алуына бик куанган, йөзекне шунда ук карчыкка илтеп биргән. Сихерче моңа үзе дә хәйран калып:

— Әйе шул, минем йөзегем бу,— дигән.— Ярар, беренче шартымны үтәдең дип саныйк. Инде хәзер икенчесен тыңла. Әнә, күрәсеңме, сараем каршындагы болында көтү йөри. Симерүе җиткән өч йөз үгез булыр анда. Менә шуларны ашап бетерергә тиеш син. Итен-сөяген, мөгезен-тоягын, тиресен-йонын — бер нәрсәсен дә калдырмыйча! Янә дә нәүрәбебездә өч йөз мичкә хәмер ята, шуларны да эчеп бетер. Әгәр үгезләрдән бер генә бөртек йон, бер генә тояк, өч йөз мичкә эчемлектән бер генә тамчы хәмер калса да, җаның кыелачагын белеп тор!

Король малае карчыктан:

— Кунаклар чакырырга мөмкинме соң? Берүзең булганда аш-суның тәме китә,— дип сораган.

Сихерче карчык, авызын чалышайтып:

— Берүзеңә күңелсез дисеңмени? Алайса, берәрсен чакыр инде. Тик ишетсен колагың: артык берәү дә булмасын,— дип көлгән.

Король малае иптәшләре янына кайткан да Таукорсакка:

— Бүген минем кунагым булырсың. Туйганчы рәхәтләнеп сыйлан әле бер! — дигән.

Таукорсак киерелгән, сузылган да өч йөз үгезне башы-аягы белән кабып йотып та җибәргән. Әле өстәвенә: тагын берәр нәрсә бирсәләр, ару гына буласы икән, дип сөйләнгән. Аннары күз ачып йомганчы өч йөз мичкә хәмерне дә эчеп бетергән. Чүмеч-фәлән дә кирәк булмаган, мичкәләрне күтәргән дә каплаган авызына, тамчысына кадәр ялап алган. Шуннан соң король малае туп-туры карчык янына киткән, икенче боерыкның да үтәлүен белдергән. Карчык исә моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәгән.

— Моңа кадәр бу эшне берәүнең дә башкарып чыга алганы юк иде. Ярар, хәерле булсын. Ләкин тагын бер шартымны үтисең бар ич әле,— дип сөйләнә икән.

Үзе шулчак эченнән: бу юлы алай уңай гына котыла алмассың, башың мәтәлеп төшәр, калыр муеның тырпаеп, дип уйлый, ди. Аннары өйләнергә ашкынган егеткә:

— Бүген кич бүлмәңә кызымны китерермен, кочагыңа алырсың аны. Тик аң бул: утыра-утыра йокыга китә күрмә. Сәгать төнге уникене сукканда яныгызга керермен. Әгәр шулчак кызым кочагыңда булмаса, җаның белән бәхилләшәчәгеңне белеп тор,— дигән.

Король малае, монысы җиңел шарт икән, йоклау түгел, күземне дә йоммам әле, дип уйлаган. Аннары иптәшләрен чакырып китергән дә карчыкның өченче боерыгы хакында сөйләп биргән.

— Мәкерле карчык бу юлы да берәр хәйлә кормый калмас. Сез инде бу кичтә бигрәк тә сак була күрегез, уяу торыгыз, кызый минем яннан чыгып китә күрмәсен,— дигән.

Төн җиткәч, егет бүлмәсенә кызын ияртеп карчык килеп кергән. Ул кызын король малаеның кочагына салып чыгып киткәч, Арканбуй киерелгән, сузылган да кыз белән егетне уратып ук алган, Таукорсак ишек каршысына килеп баскан. Шулай итеп бүлмәгә бер җан иясе дә үтеп керә алмаслык булган. Утыралар икән егет белән кыз кочаклашып, тик чибәркәй ләм-мим бер сүз эндәшми, ди. Егет сөеклесенең гүзәллеген күрсен дипме, көмеш ай тәрәзәдән якты нурларын сибә, ди. Сылукайдан бер дә күзен алмый икән король малае, кая ул йоклау, дәрт тулы йөрәге җилкенгәннән-җилкенә генә бара икән.

Әмма сәгать унбер тулгач, карчык үзенең бөтен сихер-тылсымнарын эшкә җиккән: кинәт дөньядагы барлык җан иясе тирән йокыга талган. Нәкъ менә шул чакта егет кочагындагы кәләш юк булган. Унике туларга чирек сәгать калганда гына сихер көче юкка чыккан, барысы да шунда уянып күзләрен ачкан, ди.

— Һай, җебегән мин, һай, пешмәгән мин,— дип өзгәләнгән король малае.— Харап булды лабаса газиз башкайларым!

Турылыклы иптәшләре дә кайгырыша башлаган, тик Сизгерколак кына:

— Туктагыз әле, тыңларга ирек бирегез,— дип ах-ух килүчеләрне тынычландырган. Беравык тирә-юньгә колак салып торганнан соң: — Кыз моннан өч йөз сәгатьлек юл ераклыгындагы кыя-тауда утыра, язмышын каһәрләп елый, бичара. Арканбуй, бу очракта безгә син генә ярдәм итә аласың. Киерелеп торып бер сузылсаң, синең өчен ике-өч адым гына ич ул ара,— дигән.

— Дөрес,— дигән Арканбуй,— ләкин минем белән Зәһәркүз дә барсын, юлда очраячак киртәләрне юк итәргә булышыр.

Арканбуйның күзләре бәйләнгән Зәһәркүзне кулларына алуы булган, чуртан боерыгы белән дигәндәй, шул мизгелдә үк сихерләнгән кыя янына барып та җиткәннәр. Арканбуй Зәһәркүзнең битенә уралган чүпрәкне чишкән, тегесенең бер күз текәп караве булган, кыя чәлпәрәмә килеп таралып төшкән. Арканбуй гүзәлкәйне кулларына күтәреп алган да күз ачып йомганчы егет бүлмәсенә китереп тә куйган. Аннары Зәһәркүзне дә тиз генә шулай алып кайтып җиткергән. Сәгать унике тулганчы ук егет белән кыз инде нәкъ элеккечә икесе бергә бүлмәдә утыра, кыз егетнең кочагында, күңелләре көр, йокларга исәпләрендә дә юк, ди.

Сәгать уникене сукканда сихерче карчык егет бүлмәсенә юнәлгән. Кармагыма эләкте бу юлы егеткәең, дигән сыман, үзе мәкерле көлемсери икән. Кызының моннан өч йөз сәгатьлек юл ераклыгында биек кыя-тау башында утыруына тамчы да шикләнмәгән инде ул. Ләкин кызның егет кочагында утыруын күргәч, карчыкның коты алынган. Бу егет миннән дә көчлерәк булып чыкты бит, дип нык кайгырган.

Хәзер инде карчыкка киреләнеп торырлык җай калмаган, кызын егеткә бирергә туры килгән. Ләкин шулай да явыз карчык кызының колагына:

— Затсыз бер кешегә буйсынырга, үзеңә тиң түгел егеткә кияүгә чыгарга туры килә бит. Нинди хурлык инде бу синең өчен! — дип пышылдап өлгергән.

Бу сүзләрдән соң кызның тәкәббер күңеле ачу белән тулган, ул ничек тә киявеннән үч алырга теләгән. Иртәгесен өч бәйләм утын китереп өйдергән, шуннан соң король малаена:

— Әнием кушкан әмерләрне үтәдең үтәвен, ләкин минем дә бер шартым бар: арагыздан берегез янып торган шушы утын өеме уртасына кереп утырсын. Әгәр дә шушы сынауны үтә алмаса, хатының булачак түгелмен,— дигән.

«Иптәшләренең берсе дә аның өчен утта янарга риза булмаячак, билгеле. Миңа булган мәхәббәтен раслау өчен үзенә утка керергә туры киләчәк. Шулай булгач, бик ансат котылачакмын мин аңардан»,— дип уйлый икән кызыкай.

Король малаена иптәшләре:

— Синең өчен һәркайсыбыз нәрсә дә булса эшләде инде. Калтыравыкның гына булышканы юк. Әйдә, ялкын эченә кереп утырсын да җылынсын бераз,— дигәннәр.

Калтыравыкны утын өеме уртасына кертеп утырткаканнар да ут төртеп җибәргәннәр. Коры агачлар чатыр-

чотыр яна башлаган. Өч көн дөрләгән ялкын. Агачлар янып бетеп, ут сүнгәч, ни күрсеннәр, көл өеме уртасында күзге усак яфрагыдай дер-дер калтыранып Калтыравык утыра, үзе «мондый салкынны гомеремдә дә күргәнем юк иде, учак тагын бераз янган булса, туңып үләчәк идем», дип сөйләнә икән.

Нишләмәк кирәк, чибәр кыз нәсел-нәсәбе билгесез егеткә кияүгә чыгарга мәҗбүр булган. Кызы белән кияве никах йоласын үтәргә киткәч, карчык, ачулы мыгырданып: бу хурлыкка түзәр хәлем калмады, дигән дә яшьләр артыннан куа барырга гаскәр җибәргән. Гаскәренә юлда очраган бар нәрсәне кырып-җимереп ташларга, кызны кире алып кайтырга әмер биргән. Ләкин Сизгерколак карчыкның шыпырт кына әйткән бу сүзләрен ишетеп торган.

— Нишлибез инде хәзер? — дип сораган ул Таукорсактан.

Ә Таукорсак нәрсә эшлисен әллә кайчан уйлап куйган булган инде. Теге вакытта, диңгез төбеннән йөзек алган чакта эчкән суын бер-ике тапкыр төкергән икән, тарантас артында олы гына бер тирән күл барлыкка килгән. Куа килүче гаскәрләр шушы күлнең нәкъ уртасында калганнар да барысы да суда тончыгып үлгәннәр. Әмма шушы хәбәрне ишетүгә, сихерче карчык алар артыннан үзенең корычтан киенгән атлы гаскәрләрен җибәргән. Сизгерколак исә җайдакларның авыр кораллары шалтыраганын әллә кайдан ук ишетеп алган, кирәкле вакытта гына Зәһәркүзнең бер күзендәге чүпрәкне чишеп җибәргән. Зәһәркүз корыч киемле дошман җайдакларына бер генә баккан, аларның барысы да пыяла кебек уалып чәлпәрәмә килгән. Шуннан соң егет белән кызга комачаулаучы булмаган, юлларын тыныч кына дәвам иттергәннәр. Чиркәүдә никах йоласын башкарганнан соң, алты иптәше король малае белән саубуллаша башлаганнар.

— Бар теләгең дә үтәлде, инде хәзер кирәгебез калмады. Моннан соң сәфәребезне синнән башка гына дәвам иттермәкче булабыз, без дә үз бәхетебезне табарга тиеш,— дигәннәр.

Егетнең этисе сараеннан ярты сәгатьлек юл ераклыгында бер авыл булган. Шушы авыл янында бер карт дуңгыз көтүе көтә икән. Көтү янына килеп җиткәч, король малае хатынына:

— Чынлыкта минем кем икәнлегемне беләсеңме? Мин бит король малае түгел, ә дуңгыз көтүчесе. Ә-ә-нә, дуңгызлар куып йөрүче картны күрәсеңме? Ул — минем

этием. Без синең белән аңа дуңгыз көтәргә булышырга тиешбез,— дигән.

Король малае хатыны белән тарантастан төшкән дә шундагы кунакханәгә кергән. Җаен туры китереп, хуҗа кешегә төнлә белән хатынының затлы киемнәрен алып яшереп куярга кушкан. Иртән торсалар, яшь хатынның өстенә кияренә бер киеме дә юк, ди. Хуҗа хатыны аңа бер иске күлмәк, иске йон оеклар биргән. Җитмәсә, кыйммәтле нәрсә бүләк иткәндәй:

— Ирегез хакына гына бу, юкса берсен дә бирмәс идем,— дип сөйләнә икән.

Кыз иренең дуңгыз көтүчесе булуына тәмам ышанган, бергәләп көтү көтешкән. Үзе эченнән: тәкәбберлегем, артык масаюым өчен җәза бу миңа, дип уйлана икән. Сигез көн дәвам иткән бу авыр эш. Һич кенә дә түзәрлеге калмаган нәзберек король кызының, аяклары-куллары сөялләнеп, җәрәхәтләнеп беткән. Шулай бервакыт аның янына ике кеше килеп туктаган да:

— Иреңнең кем булуын беләсеңме инде? — дип сораганнар.

— Беләм,— дигән хатын,— дуңгыз көтүчесе ул. Әле хәзер генә, вак-төяк белән сату итеп, бераз акча эшләп булмасмы икән, дип базарга киткән иде.

Теге кешеләр моңа:

— Әйдә безнең белән, ireң янына алып барабыз,— дигәннәр.

Алар яшь кәләшне сарайга алып килгәннәр. Залга керсә, ни күрсен, аның ире король киемнәреннән утыра, ди. Ләкин хатын, үзен кочаклап алганчы, ирен таный алмаган. Ире аны үбеп алган да сәер хәлләрне аңлатып:

— Синең аркада бик күп михнәтләр күрдем, күп газаплар чиктем. Шуңа күрә син дә бераз интегергә тиеш идең,— дигән.

Шуннан соң утыз көн уен, кырык көн туен итеп, бергә яши башлаганнар алар. Бу әкиятне сөйләүче дә туйларында булырга теләгән иде, туры гына килмәде.

КҮҢЕЛЛЕ МУЗЫКАНТЛАР

Моннан бик күп еллар элек дөньяда бер тегермәнче яшәгән, ди. Ул тегермәнченең бер ишәге дә бар икән. Акыллы, гайрәтле, бик әйбәт ишәк булган ул.

Ишәк күп еллар тегермәндә эшләгән. Аркасында он капчыклары ташый-ташый бер заман картайган.

Хуҗа, ишәкнең хәлдән таеп эшкә ярамый башлавын

күргәч, «хәзер моңардан барыбер файда юк инде», дигән дә йортыннан куып чыгарган.

Ишәк башта аптырап калган, «кая барыйм инде хәзер, кемгә сыеныйм?» дип баш ваткан. Уйлаган-уйлаган да, «Бремен шәһәренә барыйм әле, бәлки урам музыканты булып китәрмен», дигән карарга килгән.

Чынлап та шулай иткән ул. Торткан да Бремен шәһәренә юл алган. Яңа һөнәрен яхшырак күрсәтер өчен юл буе күнекмәләр ясап, кычкырып-бакырып барган, ди. Менә шулай килә-килә ул юл читендә көчкә-көчкә генә сулыш алып ятучы бер этне очраткан.

— Маэмай, син нишләп болай әлсерәдең? Нигә болай авыр сулыйсың? — дип сораган ишәк.

— Һү-һү-һү... Әй, ишәк абзый, кызгаң мине,— дигән эт, бик зәгыйфь тавыш белән генә.— Мин бик озак бер аучыда яшәдем. Аның өчен кырлар, сазлыклар буйлап чаба-чаба киек кошлар ауладым. Тик хәзер көчем кимеде, картайдым, сунарга чыгарга да дәртем-дәрманым калмады. Шуңа күрә хуҗам мине үтерергә уйлады. Ярый әле моны вакытында сизеп алдым да качарга өлгердем. Тик менә хәзер нишләргә дә белмим: ничек итеп тамагымны туйдырырмын икән?

— Беләсеңме нәрсә,— дигән ишәк,— мин Бремен шәһәренә юл тотам. Әйдә, син дә ияр, без анда урам музыканты булырбыз. Синең тавышың матур, бик нык өрә аласың. Син җырларсың, дөңгер кагарсың, ә мин гөсләә уйнармын.

— Әйдә алайса, киттек,— дигән эт, шатланып.

Алар юлны икәүләп дәвам иттергәннәр. Ишәк ишәкчә бакырып, эт үзенчә өреп бара, ди.

Бераздан юл уртасында боегып утыручы мәче очрагап боларга. Яңгыр астында чыланып, туңып беткән, ди, бичара. Чырае тәмам сытылган, бик күңелсезләнгән, ди.

— Син монда ник болай моңаеп утырасың? — дип сораган ишәк.

— Син нигә болай калтыранасың, Мыекбай? — дип эндәшкән эт тә.

— Әй, сез, ишәк агай, маэмай абзый, кызганыгыз мине! — ди икән мәче.— Мин бик күп еллар бер хатында яшәдем, күселәр, тычканнар тоттым. Тик хәзер инде картайдым, тешләрем үтмәсләнде, тырнакларым да тупасланды. Менә шуннан соң хуҗа хатын, «бер эшкә дә ярамый бу хәзер», дип суга батырырга уйлады. Ярый әле ниятен вакытында сизеп алдым да өйдән чыгып сыздым. Хәзер менә кая барырга, нишләргә дә белмим.

Ишәк озак уйлап тормаган:

— Әйдә безнең белән Бремен шәһәренә,— дигән.— Анда урам музыканты булырбыз. Синең тавышың моңлы, җырлый-җырлый скрипка уйнарсың, маэмай да дөңгер кага-кага җырлар, ә мин гөслә уйнармын.

— Әйдәгез алайса, барыйк,—дип ризалык биргән мәче.

Хәзер инде алар юлны өчәүләп дәвам иттергәннәр. Ишәк ишәкчә бакырып, эт үзенчә һау-һаулап, мәче мыраулап бара икән. Бер заман ниндидер йорт яныннан үткәндә капка башында бугазын киереп, «ки-кри-күк» дип, бер әтәч кычкырып утыра, ди.

— Ник син тиктомалдан кычкырып утырасың, Кикрик баш? — дип аваз салган ишәк.

— Ни булды сиңа? — дип өн биргән маэмай.

— Әллә берәрсе кыерсыттымы сине? — дип эндәшкән мияубикә.

— Әй, сез, ишәк агай, маэмай абзыкай, мәче тутакай, кызганыгыз мине! — дигән әтәч.— Иртәгә хуҗаларыма кунаклар килә. Хуҗа хатыны менә шуларга тәмле шулпа пешерергә җыена. Иртәгә минем җанымны кыячаклар, шуңа күрә туйганчы кычкырып калыйм, дим.

— Алай икән, әтәчкәй, кызыл кәпәчкәй,— дигән ишәк.— Беләсеңме нәрсә, әйдә әле син безнең белән. Ни күрсәң дә, әҗәлдән хәерлерәк инде. Без Бремен шәһәренә музыкантлар булып барабыз. Синең тавышың көчле, син җырларсың, мәче скрипка уйнар, маэмай дөңгер кагар, ә мин гөслә уйнармын.

Әтәчкә мондый тәкъдим бик ошаган:

— Әйдәгез алайса, киттек,— дигән.

Моннан соң алар юлларын дүртәүләп дәвам иттергәннәр. Ишәк ишәкчә сөрән салып, эт этчә өн биреп, мәче үзенчә мыраулап, әтәч үзенчә кычкырып бара икән. Тик алар яктыда Бремен шәһәренә барып җитә алмаганнар, күз бәйләнә башлаганда бер урман кырыена тукталганнар, шунда төн уздырырга булганнар. Ишәк белән эт зур бер имән агачы төбенә сузылып яткан, мәче шуның бер аскы ботагына үрмәләгән, әтәч исә югарырак менеп кунаклаган. Тик бераздан аңа бу урыны да ошамый, ул тагын да югартынрак ботакка очып куна да, йокларга дип башын канаты астына тыкканчы, як-ягына күз ташлый. Шулчак әтәч үзләреннән ерак түгел бер җирдә ут җемелдәвен күреп:

— Кикерикүк, ут елтырый! — дип кычкыра.

— Нинди ут икән ул? — Якын-тирәдә йорт-фәлән бардыр, бәлки? — ди ишәк.

— Ул йортта ит тә бардыр әле. Ашыйсым килә, һич югы бер сөяк табылса икән,— дип өсти маэмай.

— Ул өйдә сөт тә булырга тиеш. Бик эчәсем килә,— дип аның сүзен куәтли мәче.

— Ул өйдә ярма да булмый калмас. Мин аны чүпләр идем,— дип әтәч тә аларга кушыла.

Алар әнә шулай дәртләнеп, хыялланып, ут күренгән якка таба киткәннәр. Якынлашкан саен ут яктырак җемелдри. Бераздан алар урман аланына килеп чыкканнар. Алан уртасында бер йорт тора, шуның тәрәзәләреннән якты сибелә икән.

Ишәк өй янына барган да тәрәзәдән караган.

— Ишәк агай, кемнәр бар анда? — дип сораган әтәч.

— Кемнәрме? Тәмле-тәмле ашамлык-эчемлек белән тулган өстәл, аның тирәсенә җыелган юлбасарлар бар. Бик кәефле генә сыйланып утыралар.

— Ах, шундый ашыйсым килә,— дигән эт.

— Ә минем эчәсем килә,— дигән мәче.

— Ул юлбасарлар урынында без утырсак икән,— дип сөйләнгән ишәк.

— Аларны бу өйдән ничек куып чыгарырга икән? — дигән әтәч.

Менә шуннан соң алар киңәшә, берәр хәйлә эзли башлаганнар. Уйлый торгач, болай итәләр: ишәк алгы аяклары белән әкрен генә тәрәзә төбенә баса, аның аркасына эт сикереп менә, эт сыртына мәче үрмәли, мәченең башына әтәч менеп куна. Шуннан соң алар барысы берьюлы сөрән салып, кычкырып җибәрәләр. Ишәк бакыра, эт ырылдый-ырылдый өрә, мәче күкле-яшелле тавышлар чыгарып мияулый, әтәч «кикерикүк» дип дөньяны яңгырата. Аннары дүртесе берьюлы тәрәзә аша өй эченә ташланалар. Мондый тавыш-гаугадан, пыяла чылтырауларыннан юлбасарлар тәмам өнсез-телсез кала. Алар, артларына да борылып карамастан, өйләреннән атылып чыгалар да урманга кереп югалалар.

Ә ишәк, эт, мәче, әтәч, өстәл янына утырып, үзләренә ошаган ризыкларны сыпырта башлаганнар. Әй сыйланганнар, әй сыйланганнар! Бер заман ашый-ашый ашаудан, эчә-эчә эчүдән туеп, йокларга ятканнар. Һәркайсы үзенә җайлы урын сайлаган: ишәк ишегалдындагы печәнгә сузылып яткан, эт ишек төбенә, мәче учактагы көл өстенә менеп бөгәрләнгән, әтәч капка башына кунаклаган. Көне буе юл йөреп хәйран арыганнар икән, өйдәге утны сүндергәннәр дә изелеп йокыга да киткәннәр.

Төнлә юлбасарлар, бераз исләренә килгәч, өйне күзәтә башлаганнар. Тәрәзәдәге ут сүнеп, бүлмә эче караңгылыкка чумуын күргәч, юлбасарлар атаманы:

— Бәлки без бер дә юкка гына шулай курыкканбыздыр? — дигән.—Ниләр бар икән анда, барып карап килергә иде.

Шулай дигән дә бер кешесен белешергә-тикшерергә җибәргән. Бу юлбасар өйгә кайтып, ишекне ачып кергән икән, караса — учакта ике ут ялтырый. Утлы күмердер бу, мөгаен, чыра кабызып алыйм әле, дип уйлаган юлбасар. Чыраны күмергә төртәм, дип сузса, ул мәче күзләре икән.

Мәче ярсып сикереп торган да ысылдап-мырылдап юлбасарның битен бик каты тырнап алган. Коты алынган юлбасар ишеккә ташланган, анда бичарага ырылдап эт ябышкан, әйбәтләп кенә аягыннан тешләп тә алган. Юлбасар ишегалдына чыгып, инде котылдым дип кенә уйлаганда, анда аны ишәк тибеп очырган. Капкага сугылган икән, шау-шуга уянган әтәч бөтен тирә-якны яңгыратып «кикерикүк!» дип кычкырып җибәрүгә, тегенең йөрәге ярыла язган. Шулай итеп, мескенкәй, иптәшләре янына тәмам сулышы кабып, көч-хәл белән генә кайтып җиткән.

— Бетте баш! Өебезгә әллә нинди өрәкләр кереп оялаган. Берсе битемә ябышты да сөнге белән ерткандай йөземне җәрәхәтләде. Ишек төбендәгесе хәнҗәрен ботыма кадады, ишегалдындагысы күсәк белән арт саныма тондырды, ә дүртенчесе, капка башына менеп кунаклаган казыйлары, «тотыгыз шул угрыны, тотыгыз да монда китерегез!» дип кычкырып калды. Көчкә качып котылдым,— дип сөйләгән ул иптәшләренә.

Бу хәлләргә таң калган юлбасарлар яңадан өйләренә якынлашырга җөрьәт итмәгәннәр.

— Моннан тизрәк китәргә кирәк безгә,— дип, эзләрен суытырга ашыкканнар.

Ә Бремен музыкантлары — ишәк, эт, мәче белән әтәч аларның өендә төпләнеп калганнар. Хәзер инде аларга шәһәргә барып йөрисе дә калмаган, юлбасарларның өе дә, алар мул итеп әзерләгән ашамлыклар да илгизәрләргә бик ошаган, ди, алар әле дә булса шунда гомер итәләр, ди.

КУЯН БЕЛӘН КЕРПЕ

Сез, бәлки, бу әкияткә ышанмассыз.

Минем бабай бу әкиятне сөйләгәндә һәрвакыт болай ди торган иде:

— Бу әкияттәге хәлләрнең барысы да ялган түгел.

Монда дөреслек тә бар. Югыйсә кешеләр аны сөйләмәсләр дә иде.

Әкият болай башлана иде.

Бер тапкыр керпе кояшлы, якты, аяз бер көнне үз өенең ишек төбенә баскан килеш, кулларын корсагына куеп, җырлап тора икән.

Ул шулай җырлап тора торгач, кинәт бер уйга килә: «Кырга барып, гәрәнкәләремне карап кайтыйм әле»,— ди. «Хатыным балаларны юындырып киендергәнче кырга да барып, өйгә дә кайтып өлгерермен»,— дип уйлый.

Керпе чыгып китә һәм юлда куянны очрата. Ул да кырга үзенең кәбестәләрен карарга бара икән.

Керпе, куянны олылап, башын иеп исәнләшә һәм ачык чырай белән:

— Исәнмесез, хөрмәтле куян. Ни хәлдә яшисез? — ди.

Куян, үзен әллә кемгә санап, бик эре кылана. Керпе белән әдәпле генә исәнләшү урынына башын гына селки һәм тупас сөйләшә.

— Син, керпе, нәрсә болай иртә таңнан кыр кыдырып йөрисең?

— Мин йөрергә чыктым,— ди керпе.

Куян мыскыллап көлә.

— Йөрергә? Бу кыска сыйракларың белән ерак китә алмассың, минемчә.

Керпенең бу сүзгә бик хәтере кала. Ул үзенең чынлап та кыска һәм кәкре аякларын телгә алганны бер дә яратмый.

— Син, куян, үз аякларыңны тизрәк һәм яхшырак йөгерә дип уйлыйсыңмы әллә? — ди ул.

— Әлбәттә,— ди куян.

Керпе аңардан:

— Минем белән узышырга теләмисеңме? — дип сорый.

— Синең белән узышырга? Көлдермә, зинһар. Әллә син үзеңнең кәкре аякларың белән мине узмакчы буласыңмы? — ди куян.

Керпе:

— Күрерсең, менә күрерсең, мин сине узармын,— дип җавап бирә.

— Әйдә алайса, узышып карыйк,— ди куян.

— Тукта әле! Элек мин өйгә кайтып иртәнге ашны ашыйм. Ярты сәгатьтән шушы урынга әйләнеп килермен. Шуннан соң узышырбыз. Ярыймы? — ди керпе.

— Ярар,— ди куян.

— Әйе шул,— дип килешкән тычкан.

Алар бергәләп уйлашканнар да, кыш көне тукланыр өчен бер чүлмәк май сатып алганнар. Мөлдерәмә тулы икән ул. Тик аны кайда сакларга? Уйлашалар, уйлашалар да майны амбарга яшерергә булалар. Аның бер почмагына чокыр казыйлар да чүлмәкне шунда урнаштыралар.

Күпмедер вакыт үткәч, мәченең майдан авыз итәсе килә башлый. Түземе тәмам төкәнгәч, тычканга:

— Менә нәрсә, туганкай,— ди.— Бүген мине ашка чакырдылар ич әле. Мияубикә апам аклы-каралы бер бала тапкан, шуңа исем кушу мәҗлесенә чакырды. Шунда барыйм инде мин. Ә син өйдә генә утыр, хуҗалыгыбызны караштыра тор. Ярыймы?

— Ярар соң, чакыргач, барырсың инде,— дигән тычкан.— Мин үзем дә тәм-томны татып карарга каршы түгел дә, нишлисең, кемгәдер өйне карарга да кирәк бит.

Ә мәче боларның барысын да үзе уйлап чыгарган була. Аның Мияубикә исемле бернинди апасы да юк икән. Шулай ук аны ашка чакыручы да булмый.

Мәче өйдән чыгу белән туп-туры амбарга йөгергән. Чүлмәкне җирдән казып алган да майның өстен ялый башлаган. Тамагын туйдыргач, шәһәрдәге йорт түбәләрендә иркенләп кәеф-сафа корып йөргән, рәхәтләнеп кояшта кызынган. Майлы чүлмәкне исенә төшергән саен, мыраулый-мыраулый мыекларын ялап куя икән.

Мәче өйгә кич белән генә кайтып кергән.

— Я, ничек соң, күңелле булдымы? Әйбәт сыйладылармы? — дигән тычкан.

— Ярыйсы,— дигән мәче.

— Балага нинди исем куштыгыз соң?

— Өсте.

Тычкан гаҗәпләнеп:

— Өсте? Бигрәк сәер яңгырый. Мәче халкында андый исем дә буламыни? — дигән.

— Бер дә сәер түгел,— дигән мәче кырыс кына.— Сезнең «Чи-чи»дән бер дә начар җире юк.

Тагын берничә көн узуга, мәченең янә майдан авыз итәсе килә башлаган. Нәфесе кузгалгач, тагын түзмәгән бу:

— Син, тычкан, өйдә утырып тор инде, дускаем, миңа бер игелегең булыр,— дигән.— Бүгенге өй эшләрен үзең генә караштыр. Мыраугали абзыйның хатыны кыз тапкан, үзе кап-кара, муены ап-ак, ди. Бүген шуңа исем кушу мәҗлесе җыялар.

Йомшак күңелле икән тычкан бу юлы да:

— Ярар, барырсың,— дигән.

Мәче туры амбарга чапкан. Чокырдагы чүлмәкне алган да майның яртысын ялт иттергән. Аннары мыегын ялый-ялый, «аулакта сыйланудан да күңеллерәк эш юк икән», дип сөйләнгән. Күңеле шулай күтәрелгәч, кызынып, йорт түбәләрендә йөреп, көне буе ял иткән. Кәефле генә хәлдә өйгә кайткач, тычкан аңардан:

— Көнне матур үткәрдеңме? — дип сораган.

— Рәхмәт, әйбәт узды.

— Монысына нинди исем куштыгыз?

— Уртасы.

— Уртасы? Менә әкәмәт, мондыйны ишеткәнем дә, укыганым да юк иде. Андый исем дә буламыни? — дигән тычкан.

Мәче аңарга:

— Була, була, кушкач нигә булмасын,— дип җавап биргән.

Бер гадәтләнгәч гаҗәпмени, бераздан мәченең тагын май ашыйсы килә башлаган.

— Яхшы нәрсә өч тапкыр кабатлана, диләр, дөрес ахрысы,— дигән ул тычканга.— Мине тагын бәби туена чакыралар бит әле. Сарыкаш җиңгәм дә ул тапкан икән. Үзе кап-кара, тәпиләре ап-ак, ди. Әллә нигә бер генә туа икән мондый тансык песикәй. Барып килергә рөхсәт ит инде син миңа!

— «Өсте», «Уртасы»...— дип сукранган тычкан,— кеше ишетмәгән, илдә булмаганны...

— Өйдә утыра-утыра эчең поша ахры, менә бер заман үзең дә чыгып йөри башларсың әле,— дип юаткан аны мәче.

— Ярар, бар инде алайса,— дигән тычкан.

Мәче киткән. Тычкан исә, савыт-сабаларны юып, идәннәрне себереп бетергәч, тәрәзә төбенә менеп утырган да өйдәшен көтәргә тотынган.

Мәче исә бу вакытта амбарга килеп кергән дә чокырдагы чүлмәкне алып, майның калган өлешен сыпырткан. Аннары:

— Эш бетте, кайгы китте,— дип мыекларын ялап куйган.

Тамагы тук булгач, өенә бик ашыкмаган, йорт түбәләрендә йөреп, кояшта кызынып, кич белән генә кайтып кергән.

— Бүген дә күңелле булдымы соң? — дип сораган аңардан тычкан.

— Күңелле,— дигән мәче.

— Бәбигә нинди исем куштыгыз инде?

— Сиңа бу исем дә ошамас әле, мөгаен,— дигән мәче.— Калдыгы дип атадык.

— Калдыгы? Дөньяда мондый исем юк, син моны үзең уйлап чыгаргансың,— дигән тычкан.

— Нишләп булмасын? Кушкач була икән шул,— дигән мәче.

Тычкан башын чайкап торган да йокларга яткан.

Шушы көннән соң мәчене берәү дә бәби туена чакырмый икән. Ул арада җилле-буранлы салкын кыш та килеп җиткән, җир өстен ап-ак юрган каплаган. Хәзер инде тышта бер бөртек ризык та табарлык түгел икән. Шул вакыт тычкан чүлмәктәге майны исенә төшергән.

— Мәче дус, әйдә, чүлмәктәге майны карап киләбез,— дигән ул.— Җәйдән хәстәрләп әйбәт иттек, хәзер менә бераз сыйланырга да мөмкин.

— Әйдә,— дип көлемсерәгән мәче.

Амбарга килеп җиткәннәр, чүлмәкне казып алганнар, тик майдан җилләр искән, ди.

— Ах! — дигән тычкан, ачыргаланып.— Менә хәзер синең нинди дус булганлыгыңны аңладым инде. Нинди мәҗлесләргә йөрүеңне дә төшендем, сәер исемнәрнең мәгънәсен дә... Беренче тапкырында майның өстен генә ашагансың икән, икенче баруыңда уртасына төшкәнсең, аннары...

Мәче:

— Тукта! Телеңне тыймасаң, үзеңне дә кабып йотам хәзер,— дип акырып җибәргән.

Тычкан, бар тавышы белән чинап:

— ...калдыгын! — дип кычкырган.

Кычкыруы булган, мәче аның өстенә сикергән дә мескен тычканны «әһ» иткәнче башы-аягы белән кабып та йоткан.

Шуннан соң мәче белән тычканның дуслыгы да беткән.

БҮРЕ БЕЛӘН ҖИДЕ КӘҖӘ БӘТИЕ

Әүвәл заманда яши иде, ди, бер карт кәҗә. Аның җиде бәтие бар иде, ди. Һәрбер ана үзенең балаларын яраткан кебек, бу кәҗә дә үзенең бәтиләренең барчасын да бик ярата иде, ди.

Менә бер көнне кәҗә азык юнәтер өчен урманга ба-

рырга җыена. Китәр алдыннан ул бәтиләрен үз янына чакырып ала да:

— Сөекле бәтикәчләрем, миңа хәзер урманга барырга кирәк, сез үзегез генә калырсыз. Өйдә генә утырыгыз, бүредән саклана күрегез. Аны өйгә кертсәгез, ул барыгызны да ашап бетерер. Мөгез белән тоякларыгызны да калдырмас. Хәйләкәр ул, явыз, кайчакта шундый кылана, бүре дип тә белмәссең. Тик сез аны күргәч тә танырсыз. Аның сыйраклары кара булыр, тавышы тупас булыр,— ди.

Бәтиләре аңа:

— Әнкәебез-газизкәебез, син бер дә борчылма, бара бир. Бүрене кертмәбез,— дип җавап бирәләр.

Кәҗә үзенең бәтиләре белән «мә, мә, мәәә», дип саубуллаша да, тәмам тынычланып, юлга чыга.

Әниләре китүгә, наяннар сикерешеп уйнарга тотына. Тик бераздан аларны ишек шакыган тавыш сагаерга мәҗбүр итә.

— Кем бар анда? — дип сорый бәтиләр.

Ишек артыннан исә кемдер:

— Ачыгыз, сөекле балакайларым, мин бу, әниегезгазизкәегез. Мин кайттым, сезгә тәмле-тәмле күчтәнәчләр алып кайттым,— дип җавап бирә.

Әмма бәтиләр, ишек шакучының тупас тавышын ишетүгә, аның кем икәнлеген аңлап алалар.

— Юк, ишек ачмыйбыз,— диләр бәтиләр,— син безнең әниебез түгел. Аның тавышы нечкә, ягымлы, ә синең тавышың бик тупас. Син — бүре, кит моннан! — дип кычкыралар.

Шуннан соң бүре кибетчегә барып, аңардан бер таяк акбур сатып ала. Шул акбурны йоткач, аның тавышы кәҗәнеке кебек нечкәрә. Аннары бүре бәтиләр торган өйгә яңадан әйләнеп килә дә тагын ишек кага. Кәҗә бәтиләре:

— Кем бар анда? — дип сорыйлар.

Бүре аларга:

— Ачыгыз, сөекле балакайларым, мин бу, әниегезгазизкәегез. Мин кайттым, сезгә тәмле-тәмле күчтәнәчләр алып кайттым,— дип җавап бирә.

Бу сүзләрне бүре нәзек кенә тавыш белән әйтә, ә үзе кара сыйраклары белән тәрәзә кырыена таяна. Бәтиләр аның кара сыйракларын күреп алалар да:

— Кит моннан! Безнең әниебезнең сыйрагы ап-ак, ә синең сыйракларың кап-кара. Син — бүре! — дип кычкыралар.

Бүренең бик ачуы килә. Тик берни эшли алмый, бә-

тиләр аны өйгә кертмиләр. Шуннан соң ул, күмәччегә йөгереп барып:

— Абынып аягымны авырттырдым, шуңа камыр сылап җибәр әле,— ди.

Күмәчче аның сыйрагына камыр сылагач, бүре тегермәнче янына йөгерә.

— Аякларыма ап-ак булырлык итеп он сип инде,— ди аңа.

Тегермәнче, бу явыз кемнедер алдаларга җыена бугай, дип уйлый да, бу эшкә риза булмый. Ләкин бүре:

— Сипмәсәң, тотам да ашыйм үзеңне,— ди.

Тегермәнче курка кала, бүренең аякларына, ап-ак булганчы, он сибә. Менә нинди куркак кешеләр дә була бит дөньяда!

Шуннан соң явыз бүре өченче мәртәбә бәтиләр торган өйгә килеп, ишекне кага.

— Кем бар анда? — дип сорыйлар эчтән.

Бүре аларга:

— Ачыгыз, сөекле бәләкәчләрем, мин бу, әниегезгазизкәегез. Сезгә тәмле-тәмле күчтәнәчләр алып кайттым,— дип җавап бирә.

Кәҗә бәтиләре:

— Башта тәрәзәдән тәпиләреңне күрсәт әле. Әниебезме син, түгелме — күрик,— дип кычкыралар.

Бүре аларга камыр сылап, он сипкән сыйракларын күрсәтә. Бәтиләр аларның аналарыныкы төсле ак булуын күрәләр дә, чынлап та әниебез кайткан икән дип ышанып, ишекне ачалар. Ачсалар, ишектән бүре атылып керә, ди.

Бәтиләр яман куркышалар, кайсы кая кача башлыйлар: берсе өстәл артына яшеренә, икенчесе караватка сикереп менә, өченчесе мич эченә кереп китә, дүртенчесе кухняга йөгерә, бишенчесе шкафка кереп утыра. Алтынчысы кер юа торган тагарак астына поса, ә җиденчесе, иң кәние, стена сәгате эченә кереп югала.

Тик бүре аларның барысын да эзләп таба, озын-озак уйлап тормастан, берсе артыннан икенчесен каба да йота, каба да йота. Өстәл астына кергәнен дә, түшәккә менгәнен дә, мич эченә качканын да, кухняга яшеренгәнен дә, шкафка кергәнен дә, тагарак астына посканын да! Бары стена сәгате эченә кереп качкан иң кәни җиденче бәтине генә таба алмый. Бүре, тамагы туйгач, ашыкмыйча гына чыгып китә, яшел болындагы бер куак төбенә ятып, рәхәт йокыга тала.

Озакламый кәҗә дә урманнан кайта. Йа ходай, нигәргә тап була ул өендә! Ишек төбенәчә каерып ачыл-

ган, өстәл-урындыклар, эскәмияләр кайсы кайда ауган, тагарак чәлпәрәмә килгән, ястык-мендәрләр, юрганнар тузгыган...

Бичара кәҗә газиз бәтиләрен эзләргә керешә, тик никадәр эзләсә дә таба алмый. Кычкырып дәшеп карый, беркем җавап кайтармый. Төпчегенең исемен атагач кына, сәгать эченнән:

— Әнкәем, мин монда! — дигән нечкә тавыш ишетелә.

Кәҗә сәгать капкачын ачкач, аннан иң нәни бәти сикереп чыгып, әнисенә ул югында өйгә бүре килүен, аннары тагын нинди хәлләр булуын барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Мескен кәҗә балакайлары өчен кайгырып, шундый ачы күз яшьләре түгә, аның хәсрәтләнүен бернинди сүз белән дә сөйләп бетерә алырлык түгел. Ул шулай елый-елый өеннән үк чыгып китә. Бәләкәче дә әнисе артыннан калмый йөгерә.

Бераздан алар болынга килеп җитәләр. Карасалар, бер куак төбендә бүре йоклап ята, ди. Ул шундый каты гырылдый, тавышыннан хәтта агач ботаклары да селкенеп тора. Кәҗә экрен генә атлап ерткыч янына килә, ал ягыннан да, арт ягыннан да колак салып тыңлый. Бүренең чүмәләдәй кабарган корсагында нидер селкенә, кемдер тиберчене кебек тоела аңа.

— Әкрен, әкрен! — дип кисәтә ул бәләкәчен.— Бүренең эчендә нәрсәләрдер кыймылдый, чыелдый түгелме? Бәтиләрем исән булуы да ихтимал, комсыз ерткыч аларны терелэй йоткан ахры.

Шуннан соң ул үзенең нәни бәтиен өйгә инә-җеп белән кайчы алып килергә җибәрә. Шуларны үзенә китереп җиткерү белән, кәҗә дошманының корсагын ярырга тотына. Бераз гына яруы була, бүре корсагы эченнән бер бәтиенең башы күренә. Тагын да күбрәк ярып җибәрсә, бүре корсагыннан бәтиләренең алтысы да бер-бер артлы сикерешеп килеп чыгалар. Барысы да исән-саулар, берсе дә зарарланмаган, чөнки комсыз бүре бәтиләрне чәйнәми-нитми генә йоткан була.

Әй куанышa да соң инде шуннан соң кәҗә халкы! Бәтиләр назланып, иркәләнеп әниләре тирәсендә сикеренергә, бөтерелергә тотыналар. Олы башы белән аналары да биергә керешә. Аннары бәтиләренә:

— Барыгыз әле, тиз-тиз генә ташлар җыеп китерегез, явыз бүре йокысыннан уянганчы, комсызның корсагына тутырып куярбыз,— ди.

Җиде бәти йөгерешә-йөгерешә таш җыеп китерә дә, аларны күп итеп бүренең корсагына тутыралар. Аннары

аналары бүре карынын шундый тиз, шундай оста теген куя, бүре моны үзе сизми дә кала.

Менә бер заман бүре йокысыннан уяна. Эчендәге ташлар эсселәткәнлектән, яман эчәсе килә моның. Торып баса да, су буена барып, су эчмәкче була. Алпан-тилпән атлап китүе була, эчендәге ташлар дөбер-шатыр килеп корсагында тәгәрәшеп йөри башлый. Бүре, сызлануына чыдый алмыйча, кычкырып ук җибәрә:

— Яна эчем, сусауларым сүрелми,
Күзләремә якты дөнья күренми.
Алты бәти әллә күбрәк булганмы?
Әллә эчем артыграк тулганмы?

Шулай да су буена барып җитә бүре. Әмма су эчим әле дип иелүгә, эчендәге авыр ташларны күтәрә алмыйча, елгага мәтәлеп барып төшә. Шулай итеп, явыз бүре суга батып үлә. Моны карап торган бәтиләр шатлана-шатлана:

— Явыз ерткыч дөмекте! Комсыз ерткыч дөмекте! — дип такмакларга тотыналар.

Куанычтан әниләре белән бергәләшеп яшел болында байтак сикерешәләр, байтак әйлән-бәйлән уйныйлар, ди, алар.

АК ЕЛАН

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер король. Үзенең акылы, зирәклеге белән бөтен дөньяда дан тоткан, ди, ул. Аның җир йөзендә белмәгән бер генә нәрсәсе дә булмаган. Иң серле хәлләр турында җилләр аңа хәбәр иреш-терел торганмыни!

Әмма корольнең бер сәер гадәте бар икән: төшке ашка утырганда, өстәлгә бөтен савыт-саба, тиешле ризыклар куелганнан соң, бүтән киләсе кеше булмаса да, көн саен иң ышанычлы хезмәтчесенә бер савыт ризыкны артык китерергә куша, ди. Ул савытның өсте гел ябулы булганга, хезмәтчесе дә анда нәрсә салынуын белмәгән. Король берүзе калгач кына, савытны ачып, ялгызы ашый икән. Озак вакытлар дәвам иткән бу шулай.

Көннәрдән бер көнне хезмәтче, өстәл җыештырганнан соң, әлеге савытта ни барлыгын бик беләсе килеп, аны үз бүлмәсенә алып кергән. Башта бик әйбәтләп ишеген бикләгән, аннары сак кына савытның капкачын ачкан. Караса, савытта пешерелгән ак елан ята, ди. Моны күргәч, хезмәтченең елан итен татып карыйсы килгән, бер телемен кисеп алган да авызына капкан. Елан ите-

неӊ теленә тиюе булган, тәрәзә төбендә шунда ук нинди-дер ягымлы тавышлар яңгыравын ишеткән. Хезмәтче тәрәзәгә якынрак килеп колак салган икән, гаҗәпләнүеннән хәйран калган: чыпчыклар үзара чукердәшеп сөйләшәләр, имеш. Алар серләрен бүлешә, бер-берләренә кырларда-болыннарда очып йөргәндәниләр күргәннәрен сөйлиләр, ди. Елан ите хезмәтчегә менә шулай кошлар, җанварлар телен аңлау кодрәте биргән икән.

Нәкъ шул көнне сарайда көнделсез бер хәл булган: король хатыны үзенең иң яраткан бик кыйммәтле йөзеген югалткан. Әлеге хезмәтче барлык бүлмәләргә дә кереп йөри алганлыктан, гаепне аңа аударганнар. Король хезмәтчесен чакырып алган да, кинаяле сүзләр әйтеп, бик каты әрләгән. Иртәгәгә чаклы угрының кем икәнен белә алмасаң, үзеңне гаепләячәкбез дә җәзалап үтерәчәкбез, дигән.

Хезмәтче үзенең гаепсез икәнлеген әйтеп нихәтле антлар итсә дә, файдасы тимәгән. Төрмәгә япмаганнар ябуын, ләкин корольнең әлеге фәрманы көчендә калган.

Хәвефләнүдән, куркудан нишләргә дә белмәгән хезмәтче ишегалдына чыгып утырган. Бу четерекле хәлдән котылырга кем генә ярдәм итә алыр миңа, дип уйлана икән бичара. Шунда сарай яныннан гына аккан инештә үрдәкләр йөзеп йөри икән. Томшыклары белән каурыйларын чистарта-чистарта үзара кызу-кызу бакылдашалар, ди.

Хезмәтче аларның сүзләренә колак сала башлаган. Үрдәкләр бүген иртән кайда йөрүләре, нинди-нинди тәмле ризыклар табулары турында сөйләшәләр икән. Шулчак кошларның берсе уфтанып:

— Хәлем мөшкел әле, карынымда бер авыр нәрсә ята. Кабаланып, тәмле җимдер, дип ялгыш король хатынының тәрәзә төбендә яткан йөзеген йотып җибәргән идем, шул эчемне авырттырып тора,— дигән.

Хезмәтче әлеге үрдәкне җитез генә эләктереп алган да кухняга кертеп аш пешерүчегә биргән.

— Мә, суйдыр әле шушы үрдәкне, җитәрлек симергән инде,— дигән.

Ашчы, үрдәкнең авырлыгын чамалап:

— Әйе шул,— дигән,— әйтәсе дә юк, әйбәт симергән. Мине тизрәк тотып кыздырсыннар, дип бик каты тырышкан мәхлук.

Ашчы үрдәкне суйдырган да эчәкләрен чистарта башлаган. Шул вакыт үрдәк карынынан король хатынының йөзеге килеп чыккан. Шуннан соң инде хезмәтче үзенең гаепсез булуын бик җиңел исбатлаган.

Король, хаксыз рәнҗетелгән турылыклы хезмәтчесенең күңелен табар өчен, теләгән нәрсәсен сорарга кушкан. Сараендагы берәр дәрәҗәле урынга куярга да риза икән. Хезмәтче боларның барысыннан да баш тарткан, бер чаптар белән азрак акча бирүне генә үтенгән. Ник дисәң, аның дөнья гизәсе, ил буйлап сәяхәт итәсе килгән. Сораганын алгач, хезмәтче тиз-тиз генә җыенган да юлга чыгып киткән.

Аз баргандырмы бу, күп баргандырмы, бер заман бер буа янына килеп җиткән. Караса, буада камышлар арасына өч балык кереп кысылган да, бу тозактан котылырга тырышып чәбәләнәләр икән. Балыкның теле юк, сөйләшә алмый, диләр диюен, тик хезмәтче аларның үзара: «Менә шушылай бер дә юктан гына харап булачакбыз икән инде»,— дип өзгәләнүләрен ишеткән. Хезмәтче йомшак күңелле, игелекле кеше булган. Тиз генә атыннан сикереп төшкән дә бичараларны тозактан коткарып, ирекко җибәргән. Балыклар сөенечләреннән чупырдашып сикерешкәннәр, аннары судан башларын чыгарып, егеткә рәхмәтләрен белдергәннәр.

— Без сине беркайчан да онытмабыз, бәладән коткаруың өчен үзеңә дә ярдәм итәрбез,— дигәннәр.

Хезмәтче атына атланган да юлын дәвам иттергән. Шулай чаптырып барганда җирдәге бер түмгәк астыннан ниндидер тавышлар ишетелгәндәй тоелган. Игътибар беләнрәк тыңласа, кырмыскалар патшасы сукрана имеш:

— Бу адәм дигән алып белән аларның әзмәвер хайваннары безгә кайчан да булса тынычлык бирерме икән? Тинтәк ат авыр тоягы белән түмгәгебезгә китереп басса, барыбызны да мәрхәмәтсез төстә сытып бетерәчәк бит! — ди икән.

Хезмәтче атын читкәрәк борган да кырмыска оясын әйләнебрәк үткән. Моны күргән кырмыскалар патшасы:

— Без сине беркайчан да онытмабыз, үзеңә дә ярдәм итәрбез,— дигән.

Бара торгач, хезмәтче бер урман буена килеп җиткән. Югарыга күтәрелеп караган икән, гаҗәеп бер тамаша — мәрхәмәтсез ата карга белән ана карганың үз балаларын җәберләвен күргән. Алар нәни кошчыкларны томшыклары белән каптырып алалар да оядан җиргә ыргыталар. Җитмәсә:

— Күзебездән югалыгыз, әрәмтамаклар! Хәзер дә без туйдырмабыз ич инде. Үсәсен үстегез, үз көнегезне үзегез күрегез,— дип карылдыйлар икән.

Мескен карга балалары кыймылдый да алмый җирдә ята, канатларын көчкә селкеткәләп:

— Хәлсез ич әле без, оча да алмыйбыз, ничек итеп ризык таба алыйк, ди? Ачка үләргә генә кала инде безгә,— дип чырылдашалар.

Йомшак күңелле егет ияреннән төшкән дә, үткен кылычы белән атын чалып, карга балаларына ашарга калдырган. Кошчыклар шатланып, тамаклары туйганчы тукланып алганнар да канат кага-кага хезмәтчегә рәхмәт белдергәннәр.

— Без сине беркайчан да онытмабыз, үсеп җиткәч үзеңә дә ярдәм итәрбез,— диешкәннәр.

Хәзер инде хезмәтче җәяүләп юлын дәвам иттергән. Бара-бара бер зур шәһәргә килеп җиткән. Аның урамнарында төркем-төркем халык җыйналган, һәр тарафта ыгы-зыгы купкан, ди. Шулчак бер җайдак килеп чыккан да:

— Тыңлагыз, тыңлагыз! Королебезнең кызы үзенә кияү сайлаячак! Аңа өйләнергә теләгән егет берничә четерекле эш башкарырга тиеш. Кушылганны үти алмаган кешегә газиз башы белән саубуллашырга туры киләчәк! — дип сөрән сала башлаган.

Бәхетләрен сынап караучылар байтак булган инде, тик барысы да башларын гына югалтканнар, ди. Хезмәтче, кызны күрүгә, аның гүзәллегенә сокланып, тәмам акылын җуйган. Бар дөньясын онытып, король алдына килеп баскан да үзенең чибәркәйгә өйләнергә теләвен белдергән. Шунда ук егетне диңгез буена алып төшкәннәр дә, аның күз алдында суның иң тирән җиренә алтын йөзек ташлаганнар. Король аңа диңгез төбеннән шушы йөзекне алып чыгарга кушкан.

— Әгәр дә тапмыйча чыксаң, сине яңадан суга атачаклар, дулкыннар кочагында тончыгып үлгәнче шулай итәчәкләр,— дигән.

Якын-тирәдәге халык бу чибәр егетне бик тә кызганган, ләкин нишләмәк кирәк, бераздан барысы да таралышкан, яр буенда хезмәтче берүзе калган. Нишләргә инде хәзер, дип кайгыга чумып тора икән бу. Шулчак үзенә таба йөзеп килүче өч балыкны күреп алган, теге чакта камышлар арасыннан үзе коткарган җан ияләре, ди. Уртадан килүче балыкның авызында әкәм-төкәм кабырчыгы бар икән. Ул яр буена йөзеп килгән дә кабырчыкны егетнең аяк астына куйган. Хезмәтче, ни булыр икән бу, дип кабырчыкны кулына алган. Ачып җибәрсә, эчендә король диңгезгә ташлаган йөзек, ди.

Шатлыгыннан түбәсе күккә тиярдәй булып сарайга

йөгергән хезмәтче йөзекне корольгә кайтарып биргән дә вәгъдә ителгән кызны үзенә ярәшүләрен көтә башлаган. Тик корольнең тәкәббер кызы егетне үзенә тиң күрмәгән, аңа кияүгә чыгарга бик хурланган. Миңа өйләнергә теләсәң, үзем кушасы эшне дә үтисең бар әле, дигән.

Кыз котырып печән үсеп утырган бакчага чыккан да билдән биек үлән арасына ун капчык тары ярмасы сипкән.

— Иртәгә кояш чыкканчы шушы ярмаларны чүпләп бетер, бер бөртеге дә калмасын,— дигән ул.

Егет бакчага чыгып утырган да, бу эшне ничек итеп башкарырга инде, дип уйлана башлаган, ләкин башына бер генә юньле уй да килмәгән. Утыра да утыра, ди, шулай хафаланып, иртән таң аткач үзенең үлемгә хөкем ителәчәген көтә икән. Бакчага шәфәкъ кызыллыгы иңгәч кенә башын күтәргән ул. Караса, ярма тутырылган ун капчык бер-берсенә сөяп куелган, үлән арасында бер генә бөртек тә калмаган, ди. Төнлә бакчага үзенең күп меңле халкы белән кырмыскалар патшасы килгән икән. Шул игелекле бөҗәкләр үлән арасына сибелгән ярмаларны берәмтекләп чүпләгәннәр дә капчыкларга тутырып куйганнар.

Бер заман король кызы бакчага чыкса, егетнең бу йомышны да төгәл башкаруын күреп, таң калган. Ләкин ул һаман да әле үзенең тәкәбберлеген җиңә алмаган.

— Ике шартны үтәдең үтәвен, ләкин мин сиңа, мәңгелек агачыннан бер алма алып кайтып бирсәң генә, кияүгә чыгачакмын,— дигән.

Егет мәңгелек агачының кайда үсүен белмәсә дә, теләр-теләмәс кенә сәфәргә кузгалган. Өмете зурдан булмаган, билгеле, шулай да хәлдән тайганчы аягы атлаган якка барырга карар иткән. Төн киткән, көн киткән, өч мәмләкәтнең җирен үткән. Бер заман кичке караңгылык куерганда ниндидер урман буена барып җиткән. Шундагы бер агач төбенә утырып йокларга җыенган. Шулчак ботаклар арасында ниндидер кыштырдау тавышы ишеткән бу. Аннары көтмәгәндә генә югарыдан бер алма өзелеп төшкән. Шул мизгелдә үк өч карга очып килгән дә җыйнаулашып егетнең иңбашына кунганнар.

— Без — синең аркада ач үлемнән котылган карга балалары. Үсеп җиткәч, алтын алма эзләвеңне ишеттек тә, диңгезләр кичеп, җир кырыена кадәр барып җиттек. Мәңгелек агачы әнә шунда үсә икән, кулыңдагы алманы шуннан алып кайттык сиңа,— дигән алар.

Шатлыгыннан башы күккә тигән егет ашыга-ашыга сарайга кайткан да сылукайга алтын алманы илтеп бир-

гән. Хәзер инде король кызының киреләнергә бер дә урыны калмаган. Алманы урталай бүлгәннәр дә бергәләп ашаганнар. Минуты белән икесенең дә йөрәге кайнар мәхәббәт ялкынына уралган. Картаеп беткәнче бик тату, бик бәхетле яшәгәннәр, ди, алар, кайгы-хәсрәтнең ни икәнен дә белмәгәннәр, ди.

АЛТЫН КОШ

Борын-борын заманда булган, ди, бер король. Аның сарае ял итү өчен бик уңайлы олы гына бакча белән уратылып алынган икән. Бакчасында хикмәтле бер алмагач үскән, аның алмалары саф алтыннан булган, ди. Өлгерү белән агачта ничә алма барлыгын санап куялар икән. Ләкин көн саен таң атар алдыннан гына бер алма югала да тора, ди. Бу турыда галиҗәнапка хәбәр иткәннәр. Король алмагач янына төнгә каравылчы куярга дигән уйга килгән.

Корольнең өч малае булган. Беренче төнне бакча каравылларга король үзенең олы улын җибәргән. Ләкин төн урталары якынлашкач, тегенең үлеп йокысы килә башлаган. Иртән торса, тагын бер алма юкка чыккан, ди. Икенче төнне бакчаны уртанчы улы саклаган. Тик аның белән дә шундый ук хәл булган. Сәгать төнге уникене сугар алдыннан гына йокыга киткән бу. Иртән торса, янә бер алма үтүт, ди! Хәзер инде бакча саклау чираты төпчек малайга җиткән. Ул каравылга барырга бик теләсә дә, атасы аңа әллә ни өмет багламаган — абыйлары булдыра алмаганны моңар кая инде, дип уйлаган. Шулай да, бик үтенгәч, рөхсәт иткән.

Егет алмагач төбенә килеп яткан да тирә-якны күзәтә башлаган, ничек кенә булса да йокыга бирешмәскә тырышкан. Сәгать уникене суккач, һавада кинәт канат җилпегән тавыш ишетелгән. Малай ай яктысында алмагачка таба бер кош очып килгәнне күргән. Кошның каурыйлары саф алтыннан, ай яктысында ялт-йолт итеп тора икән. Алмагачка төшеп кунган да бу, әйбәтләп кенә бер алманы өзеп, томшыгына капкан. Егет җәясен алган да атып җибәргән. Бик туры тидерә алмаган алуын, шулай да угы кошның канатына кагылып узган, шул чакта аның бер каурые җиргә төшеп калган, ди.

Иртәгесен корольнең төпчек малае табышын әтисенә алып килеп, кичә төнлә белән бакчада нинди хәлләр булуын сөйләгән. Галиҗәнап үзенең вәзирләрен җыйган да алтын каурыйны күрсәткән. Вәзирләре таң калып, бу

каурый бөтен мәмләкәтебез байлыгыннан да кыйммәтрәк булырга тиеш, дигәннәр.

— Шундый кыйммәтле икән, миңа бер каурые гына әз, кошның үзе кирәк,— дигән король.

Алтын кошны эзләргә башта корольнең олы улы юлга чыккан. Ул үзен иң акыллылардан санап, алтын кошны, әлбәттә, мин генә таба алачакмын, дип уйлаган. Бара торгач байтак юл үткән, ди, бу. Шулай бара-бара бер урман кырыена килеп җиткән. Караса, юл өстендә бер төлке утыра, ди. Егет җитез генә иңбашыннан мылтыгын алып җәнлеккә төзәгән. Төлке аңа:

— Атма миңа, акыллы киңәшләр бирермен үзеңә! Алтын кошны эзләп юлга чыккансың икән. Сәфәрем уңсын, дисәң, тыңла яхшылап. Бүген кич бер авылга барып җитәрсең. Анда кара-каршы урнашкан ике кунакханә булыр. Берсенең утлары балкып торыр, анда бик уңайлы, күңелле сыман күренер. Ләкин син анысына якын да барма. Икенчесе тыйнаграк, фәкыйрьрәк булса да, тот та шунысына кер,— дигән.

Олы ул, аңгыра җәнлек нинди акыллы киңәш бирә алсын соң, дип уйлаган да мылтыгының чакмасына баскан. Мылтык шартлап атылган, ләкин ядрә төлкегә тимәгән. Төлке исә койрыгын болгаган да җитез генә урманга кереп, күздән югалган. Король малае, һай, кызганыч, тидереп булмады лабаса, дип юлын тагын дәвам иттергән. Чыннан да кичен бер авылга барып җиткән бу. Анда дөрестән дә ике кунакханә бар икән: берсендә шундый күңелле, җырлыйлар да бииләр, ди, ә икенчесе фәкыйрьрәк күренә, тын гына, күзгә бәрелмичә генә торган гап-гади бер йорт, ди. Нур балкытып, күңелле авазлар таратып утырган кунакханәне санга сукмыйча, шушы хәерче йортка керсәм, шыр юләр булырмын, дип уйлаган корольнең олы улы. Шулай итеп, бай кунакханәгә урнашкан да, кәеф-сафа корып, типтереп яши башлаган. Алтын кошны да, этисен дә, аның биргән киңәшләрен дә оныткан.

Көн артыннан көн үткән, әмма олы улының үзе дә, хәбәре дә юк, ди. Инде алтын кошны эзләп тапмакчы булып, корольнең уртанчы улы юлга җыенган. Абыйсы кебек үк, моңар да шул ук җирдә элеге сәер төлке очраган. Уртанчы малайга да ул шул ук киңәшне биргән. Ләкин абыйсы кебек үк уртанчы улы да төлкенең сүзләренә колак салмаган. Элеге ике кунакханәле авылга килеп җиткән, ди, ул. Аларның берсендә кәеф-сафа коралар икән. Төбәлебрәк караса, тәрәзә янында абыйсы басып тора, ди. Ул да энесен күреп алган, әйдә, монда кер, дип

чакырган. Энесе карышып тормаган, бай кунакханәгә кергән, аннары абыйсы шикелле шунда, дөньясын онытып, типтерә башлаган.

Көн артыннан көн үткән, әмма уртанчы улның үзе дә, хәбәре дә юк. Инде корольнең төпчек улы бәхетен сынап карарга теләгән. Ләкин атасының аны бер дә өйдән чыгарып җибәрәсе килми икән. Юкка гына нужа чигәр, абыйлары булдыра алмаганны, кая инде аңа алтын кош табу. Андый-мондый бәхетсезлеккә очраса, ничек котыласын да белмәс. Сабый ич әле, акыл ягы да чамалырак, дип уйлаган. Әмма тәмам теңкәсенә тигәч, төпчек улына да хәер-фатиха бирми хәле булмаган.

Урман буенда әлеге дә баягы теге төлке утыра икән, ди. Ул, төпчек малай атарга теләп мылтыгын төзәгәч: «Зинһар, җанымны кыйма, мин сиңа акыллы киңәшләр бирермен»,— дигән. Төпчек малай йомшак күңелле булган, җәнлекне тынычландырырга теләп:

— Борчылма, төлкекәй, мин сиңа бернинди дә яманлык эшләргә җыенмыйм,— дигән.

— Игелегең өчен үкенмәссең,— дигән төлке.— Ә хәзер, барасы җиреңә тизрәк барып җитим дисәң, утыр койрыгыма.

Малайның койрыкка менеп атлануы булган, төлке тау-таш араларыннан шундый кызу чабып киткән, колак төбендә җил генә сызгыра икән. Авылга барып җиткәч, малай төлке белән саубуллашкан да, аның киңәшен тотып, бай кунакханәгә әйләнеп тә карамастан, фәкыйрь йортка урнашкан, монда бик тынычлап йокларга яткан. Иртәгесен, басу юлына чыгуы белән, кичәге төлкене очраткан.

— Мин сиңа тагын нәрсәләр эшләргә тиешлегеңне әйтергә телим,— дигән җәнлек.— Менә шушы юлдан туп-туры бар да бар. Бара торгач, бер зиннәтле сарай күрерсең. Сарай капкасы алдында гаскәр торыр, тик син алардан курыкма: солдатлар барысы да гырылдап йоклаган булыр. Шулар арасыннан атлап уз да туп-туры сарайга кер. Бүлмәләрнең иң соңгысына барып җиткәч, стенага эленгән агач читлек күрерсең. Алтын кош шул читлек эчендә булыр. Янәшәдә генә бик матур алтын читлек тә эленеп торыр. Тик син, кара аны, кошкайны агач читлектән алтынына күчерәсе булма, югыйсә эшләрең бик яман булыр...

Шул киңәшләрне биргәч, төлке егетне янә койрыгына атландырган да тау-ташлар арасыннан алга ыргылган, егетнең чәчләре генә җилдә җилферди икән.

Сарайга килеп җиткәч, барысы да нәкъ төлке әйт-

кәнчә булып чыккан. Төпчек малай алтын кош ябылган бүлмәгә килеп кергән. Кошкай иске агач читлектә утыра, янәшәсендә генә бик матур алтын читлек эленеп тора, ди. Король бакчасыннан урланган өч алтын алма да шунда икән. Егет, мондый асыл кошны ямьсез әрҗәдә алып кайту килешмәс, дип уйлаган да, агач читлекнең ишеген ачып, аны алтын читлеккә күчермәкче булган. Ләкин шул мизгелдә кош яман тавыш белән кычкырып җибәргән. Йоклап яткан солдатлар дәррәү уянганнар да йөгерешеп бүлмәгә килеп кергәннәр. Алар малайны тотып алганнар да, хөкем иткәнче дип, зинданга ябып куйганнар, ди.

Иртәгесен егетне хөкемдарлар алдына китереп бастырганнар. Аның нинди эш белән йөрүен белгәч, үлем җәзасына хөкем иткәннәр. Шуннан соң бу мәмләкәтнең короле егеткә:

— Шартыма күнсәң, исән калдыра алам мин сине. Фәлән мәмләкәттә җилдән дә җитез йөрүче алтын юртак бар. Шуны алып кайтып бирсәң, үзеңне дә азат итәрмен, алтын кошлы да булырсың,— дигән.

Нишләсен егет, башка чарасы булмагач, ризалык биреп, юлга чыккан. Тәмам кайгыга төшкән бу. Алтын юртак кай җирләрдә икән? Ничек табарга инде аны? — дип авыр сулап куйган. Шулчак король малае үзенең тугрылыклы дустын — юл буенда утырган төлкене күреп алган.

Җәнлек моңа:

— Киңәшемне тотмауның бәласен татыдыңмы инде? Тик, ярар, күңелеңне бөтенләй төшермә, ярдәм итәрмен инде бер юлга, алтын юртакны ничек табу чарасын өйрәтермен,— дигән.— Менә шушы юл белән туп-туры бар да бар. Бара торгач, зиннәтле бер сарайга җитәрсең. Алтын юртак шуның ишегалдындагы ат абзарына ябылган булыр. Ат абзары капкасы алдында терлек караучылар белән сакчыларны күрерсең. Ләкин син алардан курыкма, барысы да гырылдап йокыга талган булырлар. Бернигә карамый, алтын юртакны җитәкләп дә тышка алып чык. Тик, кара аны, онытып җибәрмә, бахбайны агач белән тиредән генә эшләнгән иске ияр белән генә иярлә, янәшәсендә эленеп торган алтын ияргә кызыкма, юкса бәла-казага юлыгырсың.

Шулай дигән дә, король малаен койрыгына атландырып, тау-ташлар буйлап алга атылган, егетнең колак төбендә җил генә уйный, ди. Шуннан соң барысы да нәкъ зирәк җәнлек әйткәнчә булып чыккан. Егет җиңел генә алтын юртак ябылган ат абзарына килеп кергән.

Әмма юртакның сыртына төлке әйткән мескен иярне салган чакта егет икеләнә калган. Шушындый сөлек кебек юртакны кеше күзенә күрсәтмәслек ияр белән иярләсәм, аны кимсетү булыр иде, алтын ияр нәкъ шушы ат өчен ясалган лабаса, дип уйлаган ул.

Әмма алтын иярне кулына алып атның сыртына салуы булган, юртак бик каты кешнәп җибәргән. Тавышка ат караучылар белән сакчылар да уянган. Алар егетне тиз генә эләктереп алганнар да, хөкем иткәнче дип, зинданга ябып куйганнар.

Иртәгесен төпчек малайны хөкемдарлар алдына китереп тә бастырганнар, үлем җәзасына да хөкем иткәннәр. Шуннан соң бу мәмләкәтнең короле:

— Әгәр дә фәлән мәмләкәттәге алтын сарайдан гүзәлләрнең дә гүзәле булган патша кызын алып кайта алсаң, үзеңне дә азат итәрмен, алтын юртакны да бирермен,— дигән.

Нишләсен егет, бичарадан ни чара юлга чыккан. Бәхетенә каршы, беравык баргач, янә дә әлеге тугры дусты төлкене очраткан. Зирәк җәнлек, аны шелтәләп:

— Шушы хәлеңдә калдырып китсәм дә була иде дә, нигәдер кызганам үзеңне. Тагын бер ярдәм итеп карыйм, булмаса,— дигән.— Менә бу юлны күрәсеңме? Ул туп-туры алтын сарайга илтә. Кояш баеганда гына барып җитәрсең анда. Төнлә, бөтенесе йокыга киткәч, патшаның гүзәл кызы су коеныга чыгар. Суга керәм дигәндә генә йөгереп бар да үбеп ал үзен. Шуннан соң ул синнән калмас, артыңнан ияреp. Юлга кузгалыр алдыннан этиәнисе белән саубуллашырга рөхсәт сорар, риза була күрмә. Югыйсә эшләрең сүтелер,— дигән.

Шулай дигән дә, король малаен койрыгына атландырып, төлке тау-ташлар аша алга омтылган, егетнең колак төбендә җил генә улый, ди. Алтын сарай янына килеп җиткәч, барысы да нәкъ зирәк җәнлек әйткәнчә булып чыккан. Егет ярты төн җитеп, барысы да тирән йокыга талганны көткән. Төн уртасында чибәр кыз су коенырга чыккан. Суга керәм дигәндә генә, король малае йөгереп барган да сылукайны үбеп алган. Кыз аңа:

— Синең белән китәргә мин бик риза,— дигән.

Аннары ялына-ялына эти-әнисе белән саубуллашырга рөхсәт сораган. Егет башта каты торган, ләкин кыз һаман елаган да елаган, саубуллашыйм инде, дип аның аягына ятып ялвара башлаган. Төпчек малай, ахыр чиктә йомшап, сылукайга ата-анасы белән саубуллашырга рөхсәт иткән.

Кыз этисе караваты янына килеп җитүгә, бөтен сарай халкы йоклаган җиреннән сикерешеп торган да шундук егетне эләктереп алган. Аннары, хөкем иткәнче дип, зинданга илтеп япканнар.

Иртәгесен алтын сарай патшасы егеткә:

— Якты дөнья белән саубуллашырга туры килер сиңа. Котылырга теләсәң, бер генә юл бар. Тәрәзәм каршындагы биек тауны күрәсеңме? Шуның аркасында мин тирә-яктагы бернәрсәне дә күзәтә алмыйм. Шушы тауны сигез көн эчендә урыныннан күчереп бетерсәң, үзеңне дә азат итәрмен, кызымны да бирермен,— дигән.

Нишләсен егет, аңа тауны казудан башка чара калмаган. Ялсыз-нисез көрәге белән җирне актарган да актарган. Ләкин, җиде көн үтсә дә, тау һаман кечерәймәгән. Эшенең бер дә үрчемәвен күреп, тирән кайгыга төшкән егет, бар өметләре юкка чыккан. Җиденче көнне кич белән король малае янына әлеге төлке килеп баскан.

— Ярдәмгә лаек та түгел инде син, тик, ярар, миннән булсын яхшылык. Бар, ят та йокла, калганын үзем кайгыртырмын,— дигән.

Иртән йокысыннан уянуга төпчек малай тәрәзәгә ябырылган. Ни күрсен, каршыдагы тауның эзе дә калмаган, ди. Егет куана-куана патша янына йөгергән, аңа әмере үтәлүен белдергән. Хәзер инде, теләсә-теләмәсә дә, патшага вәгъдәсендә торырга — кызын ят егеткә бирергә туры килгән.

Егет белән кыз бергәләп кайту юлына чыкканнар. Беркадәр ара узгач, каршыларына шул ук төлке килеп чыккан.

— Иң кадерлесе хәзер синең кулда,— дигән ул.— Ә син беләсеңме, алтын юртакның хуҗасы шушы гүзәл кыз ич инде!

— Алтын юртакны үземдә калдырырга берәр әмәл юкмы соң? — дип сораган егет.

Төлке аңа:

— Башта гүзәл кызны теге алтын сарай иясенә илтеп тапшыр,— дигән.— Кызны күреп барысы да хәйран калырлар, сөенечләреннән алтын юртакны үзләре үк чыгарып, тезгенен кулыңа тоттырырлар. Юртакка шунда ук менеп атлан, аннары барысы белән дә кул биреп саубуллаш. Гүзәлкәеңә кулыңны иң соңыннан бирерсең. Кулын сузу белән, кызны җитез генә эләктереп ал да юртагыңа утырт, аннары яшен тизлегендә сарайдан эзең суыт! Сезне берәү дә куып җитә алмас, алтын юртак җилдән дә җитезрәк оча ул!

Эш алдан уйлаганча бик әйбәт килеп чыккан. Король малае гүзәл кызны алтын юртагы өстенә утырткан да юлын дәвам иттергән. Төлке дә алардан калышмаган. Бераз баргач, егеткә:

— Булган-булган, алтын кошны кулга төшерергә дә ярдәм итәрмен,— дигән. — Алтын кош яшәгән сарайга җиткәч, кызны урман читендә калдырып торырсың, аңа үзем күз-колак булырмын. Аннары алтын юртакка атланып сарайга бар. Юртакны күреп, барысы да чиксез сөенерләр, алтын кошны үзләре үк чыгарып бирерләр. Читлекне кулыңа алуга, безнең янга җилдер, аннары кыз белән бергәләп кайтып китәрсең.

Монда да эш алдан уйлаганча әйбәт барып чыккан. Әйтеп бетергесез кыйммәтле хәзинәләр кулга төшереп, корольнең төпчек улы өенә кайтырга җыенган. Төлке саубуллашканда:

— Хәзер инде хезмәтләрем өчен мине дә бәхилләтергә тиеш син,— дигән.

— Мондый олы ярдәмең өчен ничек итеп кенә бәхилләтим икән соң сине? — дигән егет.

— Ә-ә-әнә теге урманга кергәч, мине атып үтер дә башымны, аякларымны чабып өз,— дигән төлке.

— Шулкадәр яхшылыкларың өчен мин сиңа шундый явызлык эшләргә тиешмени? Юк, юк, минем моңа кулым бармый,— дигән егет.

Төлке, уфтанып:

— Үтенечемне колагыңа элмәсәң, үз юлым белән китәм инде,— дигән.— Аерылышканчы, тагын бер киңәш бирим. Син бу дөньяда ике нәрсәдән саклана күр: асылган итне сатып алма, кое кырыена утырма! — дигән.

Аннары төлке урманга кереп киткән дә юк булган.

Егет исә, искиткеч җәнлек булып чыкты бу төлке, киңәшләре дә сәер, дип уйлап калган. Асылган итне кем сатып алсын инде? Кое кырыена утырырга да гомерендә бер башына килгәне юк.

Корольнең төпчек улы шулай уйлана-уйлана, гүзәл кәләше белән алтын юртагына атланып, сәфәрен дәвам иттергән. Юлы тагын олы абыйлары тукталып калган әлеге авыл аша үтә икән. Монда килеп кергәч, урам уртасында зур төркем булып халык җыелып торуын күргән, шау-шудан колаклары тонса да, бернәрсә дә аңлый алмаган.

— Ни булды монда? — дип сораган егет берәүдән.

— Ике кешене асарга җыеналар,— дип җавап биргән теге кеше.

Мәйдан уртасынарак керсә, ни күрсен, асылачак кешеләр — моның абыйлары икән, ди. Бар байлыкларын җилгә очырып бетергәннәр дә кеше малына кул суза, төрле җинаятьләр эшли башлаган икән алар.

Төпчек малай шундагы халыктан:

— Коткарып булмыймы соң аларны? — дип сораган.

— Ник булмасын, әгәр дә бурычларын түләүче табылса, азат итәчәкләр,— дип җавап биргәннәр аңа.— Ләкин бу эрәмтамакларны коткарырга теләгән кеше акчасын бушка гына әрәм итәчәк. Кызганырдай бәндәләр түгел алар, явызлыклары хәттин ашкан!

Әмма төпчек малай озын-озак уйлап тормаган, тиешле акчаны түләп, абыйларын азат иткән. Шуннан соң барысы бергә кайтыр юлга чыкканнар. Менә алар үзләренә беренче тапкыр төлке очраган урманга килеп җиткәннәр. Түзә алмаслык җәйге эссе көн икән, урманда исә җиләс, салкынча булган. Ике абыйсы төпчек малайга беравыздан:

— Әйдә, шушы кое янында бераз ял итеп, ашап-эчеп алыйк әле,— дигәннәр.

Энеләре риза булган. Тик ул, сүзгә мавыгып, төлке биргән киңәшләрне исеннән чыгарган. Нинди дә булса яманлык эшләрләр, дип башына да китермәгәнгә күрә, кое бурасының кырыена килеп утырган. Шул чакны абыйлары, искәрмәстән артыннан килеп, энеләрен коега төртеп төшергәннәр дә, үзләре гүзәл кызны, алтын юртак белән алтын кошны алып, өйгә, этиләре янына кайтып киткәннәр. Өйгә кайткач:

— Менә, алтын кошны гына түгел, алтын юртакны да, алтын сарайдагы гүзәл кызны да алып кайттык,— дигәннәр.

Барысы да бик куанышканнар моңа. Тик алтын юртак кына авызына бер уч азык капмый, алтын кош та сайрамыйча боегып утыра, ди. Ә гүзәл кыз бер туктаусыз елый да елый икән.

Абыйлары төпчек энеләренең һәлак булуына тамчы да шикләнмәгәннәр. Ләкин, бәхеткә каршы, теге коеның суы бөтенләй кипкән булган, егет йомшак мүк өстенә генә килеп төшкән. Бер җире дә имгәнмәгән, ди. Тик менә коедан чыгарга гына җай таба алмаган.

Аңа бу юлы да турылыклы дусты төлке ярдәмгә килгән. Егетнең коеда икәнен белгәч, биргән киңәшләрен тотмаганы өчен үзен ачуланган башта. Аннары:

— Сүз тыңламасаң да, бу бәладән коткармый булмас инде сине. Әйдә, бик ныклап ябыш койрыгыма. Тик, кара аны, ычкындырасы булма! — дигән.

Төлке, «эһ» тә итми, тарткан да чыгарган коедан егетне.

— Инде аң бул, күрәселәрең бетмәде әле,— дигән төлке.— Абыйларың синең үлгән булуыңа бөтенләй ук ышанып җитмиләр, шуңа күрә урман буена үз кешеләрен куеп, күзгә күренүең белән шунда ук үзеңне үтерергә әмер биргәннәр.

Юл буенда бер хәерче утыра икән. Егет үз киемнәрен шуның белән алмашкан да хәерче кыяфәтендә сарайга юнәлгән. Монда аны берәү дә танымаган, бары тик алтын кош чутылдап сайрап җибәргән дә, алтын юртак умыртып-умыртып ашарга тотынган. Гүзәл кыз да елавыннан кинәт туктаган. Бу хәлне күргән король, хәйран калып:

— Бу гаҗәп хәлләрне ничек аңларга икән? — дигән.

Гүзәл кыз аңа:

— Мин үзем дә бернәрсә аңламыйм. Элек миңа монда бик ямансу иде, ә хәзер нигәдер күңелем шатлык белән тулды. Чын киявем кайткандыр, мөгаен,— дигән.

Аннары сылукай юлда нинди-нинди хәлләр булганны барысын да бәйнә-бәйнә корольгә сөйләп биргән. Киявенең абыйлары, әгәр ялгыш ычкындырсаң, җаныңны алачакбыз үзеңнең, дип янауларына да карамаган, ди.

Шуннан соң король сарайдагы барлык вәзирләрен, якыннарын үзе янына чакырган. Хәерче киеме кигән төпчек малай да килеп кергән. Ләкин чибәркәй аны шунда ук танып кочаклап та алган. Аннары корольнең явыз җанлы олы улларын җәзалап үтергәннәр. Төпчек малайны гүзәл кызга өйләндергәннәр дә корольнең варисы дип игълан иткәннәр.

Инде төпчек малайга шулхәтле күп яхшылык иткән мескен төлке хәлләренә килсәк... Байтак гомерләр узгач, шулай беркөнне король малае ауга чыккан. Әлеге урман буена җиткәч, аңа төлке дусты очраган.

— Хәзер инде җаның теләгән бөтен нәрсәң бар. Ә минем бәхетсезлегемнең очы-кырые күренми. Мине бары тик син генә бәхетле итә аласың,— дигән төлке.

Аннары яңадан, ялынып-ялварып, егеттән үзен атып үтерүен, башын, аякларын чабып өзүен үтенә башлаган.

Башта бик курыкса, шикләнсә дә, ахыр чиктә егет дустының сүзен тыңларга карар биргән. Төлкене атып, башын, аякларын чабып өзгән.

Шул мизгелдә үк төлке кеше кыяфәтенә кергән. Җәнлек дигәнебез төпчек малай өйләнгән гүзәл кызның абыйсы булып чыккан. Сихер тылсымы бетүгә, ул элек-

ке рәвешенә кайткан. Хәзер инде барысына да рәхәт яшәргә мөмкинлекләр ачылган. Кадерен белеп гомер ит кенә!

ҖИДЕ КАРГА

Булган, ди, бер кешенең җиде малае. Их, кызым да туса икән, дип бик теләсә дә, хыялы тормышка ашмый килгән, ди. Бер заман моның хатыны тагын авырга узган. Бу юлы, иренең куанычына каршы, кыз бала тапкан, ди, ул. Әти кеше бик-бик сөенгән, ләкин кыз нигәдер чамасыз ябык, чамасыз кечкенә, үтә хәлсез булган. Юылмаган килеш үлеп китә күрмәсен дип, кызны озакка сузмыйча коендырырга булганнар. Әтисе малайларның берсенә коедан тиз генә су алып килергә кушкан. Әмма малайларның барысы бергә урыннарыннан купканнар. Һәркайсы суны беренче алып килергә теләп кабалана икән. Шулай тарткалаша торгач, кувшиннары ялгыш коега төшеп киткән. Хәзер инде малайлар нишләргә дә аптырашып кое тирәсендә тораташтай катып калганнар, өйгә керергә берсенең дә батырчылыгы җитми, ди. Малайлары озак әйләнеп кермәгәч, әтиләренең бик каты ачуы килгән, ул эченнән үртәлеп: «мөгаен, уенга бирелеп, бар дөньяларын оныткханнардыр әле, мәлгуннәр», дип сөйләнә икән. Ата кеше, кызым юылмаган килеш үлеп китә ләбаса дип, бик нык курыккан, ачуыннан хәтта үз-үзен белештермичә:

— Һәй, булдыксызлар, барыгыз да каргага әйләнгере! — дип кычкырып җибәргән.

Шул сүзләрне әйтүе булган, һавада, нәкъ аларның йорты өстендә, канат җилпегән тавышлар ишетелгән. Ата кеше ишегалдына чыгып караса, өй түбәсеннән күмер кебек чем-кара җиде карга һавага күтәрелеп киткән, ди.

Әти-әниләре бу каргышны берничек тә кире кайтара алмаганнар, көтмәгәндә-уйламаганда җиде улларын да югалтуларына бик каты хәсрәтләнгәннәр, бердәнбер кадерле кызларына карап кына бераз юаналар икән.

Кызлары шуннан соң бик тиз тазара, көннән-көн чибәрләнә башлаган. Озак вакытлар кыз абыйлары хакында берни дә белмәгән, әти-әнисе бу хакта аңа ни дә булса сиздермәскә тырышкан. Ләкин көннәрдән бер көнне ул очраклы рәвештә кешеләрнең үзара: кызыкай чибәрен чибәр, тик менә аның аркасында җиде абыйсы җарап булуы гына кызганыч, дип сөйләшкәннәрен ишет-

кән. Шул көннән соң кыз тирән кайгыга чумган, әти-әнисеннән әледән-әле:

— Минем абыйларым чыннан да бар идеме? Булсалар, кая китеп югалдылар соң алар? Нигә аны миннән яшерәсез? — дип сорый икән.

Әти-әнисенә серне чишәргә туры килгән.

— Күрәчәгебез булгандыр инде, син туу аркасында чыккан бәла түгелдер,— дип, барысын да сөйләп биргәннәр.

Бу хакта ишеткәч, кыз үзен өзлексез битәрли башлаган, абыйларының бәхетсезлегенә үзен генә гаепле дип санаган. Тик күңелендә өмет чаткысы да сүнеп бетми, барыбер аларны коткарырмын, дип уйлана икән. Шундый хыялларга бирелеп, көндезен дә, төннәрен дә тынгылык таба алмаган, ди. Бүтән сабыр итәр хәле калмагач, әти-әнисенә әйтмичә генә юлга җыенган да, дөнья буйлап сәяхәткә чыгып киткән. Абыйларын ничек кенә булса да эзләп табарга, каргыш җәзасыннан коткарырга сүз биргән. Юлга чыкканда әти-әнисенең истәлеге итеп бер йөзек, ачыкканда тамак ялгарга бер бөтен ипи, сусаганда эчәргә бер кувшин су, арыганда утырып ял итәргә бер кечкенә урындык алган.

Кызыкай үзенең күзе кайсы якка караса, шул якка таба киткән, туктап ял да итми барган да барган. Кирәк булса, җир кырыена җиткәнче туктамаска ниятләгән, ди. Берзаман ул шулай кояш янына килеп туктаган. Шундый эссе, шундый куркыныч икән ул, кечкенә балаларны тота да ашый, ди. Кыз аңардан качып киткән, алдына-артына карамыйча йөгергән дә йөгергән. Менә шулай ул ай янына барып чыккан. Ләкин ай да коточкыч усал, салкын, бик ачулы икән. Кызны күргәч, өнен алып:

— Адәм исе килә, адәм исе,— ди икән.

Кыз абына-сөртенә ай яныннан да качып киткән. Шулай йөгерә торгач, йолдызлар янына барып җиткән. Йолдызлар якты йөзле, үзләре бик ягымлылар икән. Һәркайсының утырган урыны үзенчә, башкаларныкыннан аерылып тора, ди. Таң йолдызы Зөһрә урыныннан торган да кызга бер таяк биреп:

— Шуңардан башка Пыялатау капкасын ача алмассың, абыйларың Пыялатау эчендә,— дигән.

Кыз Зөһрә йолдыз биргән таякчыкны алган да әйбәтләп яулыгына төргән, аннары тагын алга атлаган. Әнә шулай бара-бара ул берзаман Пыялатау янына да килеп җиткән. Тауның капкасы ябык икән. Кыз, тылсымлы таягын алырга теләп, төенчеген чишеп җибәргән, әмма

ул буш булып чыккан. Юлда килә-килә йолдыз бүләк иткән тылсымлы таякны төшереп калдырган, ди, кызыкай. Нишләргә инде хәзер? Тизрәк абыйларын коткарасы иде, Пыялатау капкасын ача алмый. Туганнары өчен җанын да бирергә әзер булганлыктан, озак аптырап тормаган кыз, пычагын чыгарган да чәнти бармагын кисеп алып капка ярыгына тыккан. Шул мизгелдә үк капка үзеннән-үзе ачылып киткән.

Тау эченә кереп бераз баргач, кызга бер кәрлә очраган.

— Балакаем, нәрсә эзләп йөрисең син монда? — дип сораган ул.

— Каргаларга әверелгән җиде абыемны эзлим,— дип җавап биргән юлаучы.

— Карга әфәнделәр өйдә юк шул әле. Аларның кайтканнарын көтәм дисәң, әйдә, өйгә кер,— дигән кәрлә.

Кәрлә каргаларга ашарга хәстәрләгән: өстәлгә җиде тәлинкә аш, җиде чынаяк ширбәт тезеп куйган. Кыз һәр тәлинкәдән берәр кашык аш алып капкан, һәр чынаяктан берәр йотым ширбәт эчкән. Соңгы чынаякка энисенең йөзеген салып куйган.

Берзаман һавада канат җилпегән тавышлар ишетелгән. Кәрлә:

— Әнә, карга әфәнделәр кайта,— дигән.

Каргалар тезелешеп килеп төшкәннәр дә, ашаргаэчәргә җыенып, һәркайсы үз тәлинкәсен, үз чынаягын барлый башлаган. Шул чак каргаларның әле берсе, әле икенчесе:

— Минем тәлинкәмдәге ашны кемдер ашаган!

— Минем чынаяктагы ширбәтне кемдер эчкән!

— Мөгаен, адәми зат эшедер бу,— дип гаҗәпләнгәннәр. Җиденче карга ширбәтен эчкән икән, чынаяк төбендә яткан алтын йөзекне күргән. Алып караса, шунда ук аның энисенең йөзеге икәнен таныган. Ул ялварулы тавыш белән:

— Әй, язмыш, мәрхәмәтле бул! Әгәр монда сеңелебез килеп чыкса, без дә бу бәхетсезлектән котылыр идек,— дигән.

Каргаларның ни сөйләшкәннәрен тыңлап торган кыз бу сүзләрне ишетү белән яшеренгән урыныннан атылып чыккан. Шул мизгелдә үк каргаларның җидесе дә кеше кыяфәтенә кергән. Барысы да иксез-чиксез куанганнар, сеңелләре белән кочаклашып күрешкәннәр дә шатланашатлана бергәләп өйләренә кайтып киткәннәр.

АЛТЫН КАЗ

Яшәгән, ди, бер ир кеше. Булган, ди, аның өч улы. Кече малайны барысы да юләргә санаганга, аңа «Тинтәк» кушаматы такканнар. Аны бер дә яратмаганнар, юк-бар өчен дә кимсеткәннәр, мәсхәрәләп көлгәннәр, җае чыккан саен рәнҗеткәннәр, ди.

Көннәрдән бер көнне малайларның олысы урманга утынга барырга җыенган. Әнисе аңа юлда ашарга йомырка сытып изгән камырдан тәмле бөккән пешергән, эчәренә бер кувшин татлы ширбәт әзерләгән.

Урманга килеп җиткәч, малайга чал чәчле бер карт очраган. Ул сәлам биргән дә малайдан:

— Кесәңдәге бөккәнеңнең бер сыныгын сындырып бирмәссеңме икән, улым? Ширбәтеңнән дә бер генә йотым авыз итәр идем! Бик ачыктым, сусадым,— дип үтенгән.

Акыллы дигән малаебыз картка тупас итеп:

— Бөккәнемне сиңа ашатсам, ширбәтемне дә эчерсәм, үземә нәрсә калыр соң? Әйдә, юлыңда бул әле,— дип җавап биргән.

Шулай дигән дә малай, картны шунда калдырып, китеп тә барган. Менә берзаман ул утын кисә башлаган. Агачка берничә тапкыр селтәнеп чабуы булган, балтасы, ялгыш ычкынып, кулына тимәсенме! Малайга, эшен эшләмичә ирексездән өйгә кайтып, яралы кулын бәйләтергә туры килгән. Аның бәхетсезлегенә элеге карт сәбәпче булган, билгеле.

Икенче көнне урманга уртанчы малай киткән. Олы улына биргән кебек, әнисе аңа да йомырка сытып пешергән тәмле бөккән, бер чүлмәк татлы ширбәт тоттырган. Уртанчы малайга да теге чал чәчле карт очрап, бер сынык бөккән ашатуын, бер йотым гына ширбәт эчерүен үтенгән. Ләкин үзен бик акыллы дип санаган уртанчы малай да картка тупас кына:

— Ник мин сиңа бирим соң әле аларны? Аннары үземә нәрсә калыр? Юк, юк, әйдә, юлыңда бул,— дигән.

Шуннан соң карт белән башкача сүз алышып тормыйча, китеп тә барган.

Бу малай да тиешле җәзасын алган. Кизәнеп берничә селтәнүе булган, агачка чабасы урында балтасын ялгыш аягына китереп орган. Шулай итеп, өйгә малайны күтәреп алып кайтырга туры килгән.

Шуннан соң Тинтәк әтисеннән:

— Әткәй, мин дә урманга бер тапкыр булса да барыйм инде, утын хәстәрләшергә рөхсәт ит! — дигән.

Әтисе аңа:

— Абыйларың барды да үзләренә бәла генә алды. Син нәрсә кырмакчы буласың инде анда? Утын кисү әмәлен бер дә белмисең ич,— дигән.

Ләкин Тинтәк ялына-ялына әтисенең тәмам теңкәсенә тигән. Карт аптырагач:

— Бар инде алайса. Бәлагә тарып, бераз акылга утырмассыңмы,— дигән.

Әнисе Тинтәккә суда басып учак көлендә пешергән бер кабартма белән бер шешә сөрсегән куас тоттырган. Урманга килеп җиткәч, аңа да баягы чал чәчле карт очраган. Ул сәлам биргән дә малайдан:

— Бер сынык кына бөккәнеңне бирмәссеңме икән, улым? Шешәңдәге эчемлектән дә бер генә йотым авыз итәр идем. Бик тә ачыктым, сусадым,— дигән.

Тинтәк аңа:

— Көлдә пешкән бер кабартма белән сөрсегән куастан башка бер нәрсәм дә юк бит, бабай. Әгәр шуңа риза булсаң, рәхим ит, әйдә, утыр. Бераз тамак ялгап алырбыз! — дип җавап биргән.

Яшел чирәмгә утырганнар да болар ашарга җыенганнар. Тинтәк учак көлендә пешкән ризыгын алган икән, хәйран калган: кабартмасы йомырка сытып пешерелгән бөккәнгә әверелгән, ди. Сөрсегән куасы исә телеңне йотардай татлы ширбәткә әйләнгән, ди. Икәү бергә рәхәтләнеп ашаганнар, эчкәннәр болар. Шуннан соң чал чәчле карт Тинтәккә:

— Күңелең киң икән, актык ризыгыңны да кызганмадың,— дигән.— Шуңа күрә мин сине бәхетле итәргә телим. Әнә теге корыган агачны күрәсеңме? Шуны кисеп аудар да тамырларын актарып кара. Нәрсә булса да табарсың, мөгаен.

Карт шулай дигән дә саубуллашып китеп барган. Тинтәк ул күрсәткән корыган агачны җәһәт кенә кисеп аударган. Тамырларын актарып караса, куышрак җирдә бер каз утыра икән. Аның йоннары, каурыйлары саф алтыннан, ди. Малай казны кулына алган да, юлаучылар туктала торган кунакханәгә юнәлеп, шунда кунып чыгарга ниятләгән.

Кунакханә хуҗасының өч кызы бар икән. Алар мондый гаҗәеп киекне күреп хәйран калганнар, казның каурыйларына бик кызыкканнар, ди. Кызларның олысы: җае чыкмый калмас әле, ничек тә берәр каурыен кулга төшерермен, дип уйлый икән. Тинтәкнең каядыр

чыгып китүе булган, ул ашыга-ашыга каз янына килгән дә бер-ике каурыен йолкып алырга дип сузылган. Ләкин каз хикмәтле икән, кызның бармаклары кош канатына ябышкан да калган. Беравыктан каз янына кызларның уртанчысы килгән, аның да бар уе бер-ике алтын каурый йолкып алу икән. Ләкин кызның апасына кагылуы булган, кулы шунда ук аңа ябышкан да калган. Күпмедер вакыт үткәч, каз янына шундый ук ният белән кызларның өченчесе килгән. Апалары аны кисәтеп:

— Зинһар безгә якынлаша, кагыла күрмә,— дип кычкырган.

Ләкин кече кыз ни өчен апаларына кагылырга ярамавын һич тә төшенмәгән, алар биредә булгач нигә әле миңа гына каз янына килергә ярамасын икән, дип уйлаган. Йөгереп килеп апаларына кагылуы булган, шунда ук ул да ябышып калган, ди. Хәзер инде кызларның өчесенә дә каз янында кунарга туры килгән, ди.

Иртәгәсен Тинтәк казны кулына алган да юлга чыккан, артыннан тагылып баручы өч кызга бөтенләй игътибар да итмәгән. Кызларга әле уңга, әле сулга — Тинтәк кая барса, шунда йөгерергә туры килгән, ди.

Кыр уртасында боларга бер рухани очраган. Тинтәк артыннан лерт-лерт йөгерүче кызларны күргәч, ачулана башлаган бу.

— Кешедән оялыр идегез, әдәпсез бәндәләр! Кыз башыгыз белән басу буйлап җиткән егеткә тагылып йөрисез, оятсызлыкның тәмам чигенә чыккансыз! — ди икән.

Аннары бу рухани, кызларны туктатырга теләп, кечесенең кулыннан эләктереп алган икән, шунда ук аңа ябышып калган, ирексездән болар артыннан йөгерергә мәҗбүр булган. Бераз баргач, боларның каршыларына чиркәү чаңын кагучы килә, ди. Ул, өч кыз артыннан лерт-лерт йөгерүче попны күреп, ни дияргә дә аптыраган.

— Әй, изге ата, кая шулай ашыгасың? Бүген бер баланы чукындырасыбыз барын онытмагансыңдыр ич? — дип, йөгереп килгән дә руханиның җиңеннән тартмакчы булган икән, үзе дә аңа ябышып калган, ди.

Менә шулай бишәүләп, җепкә тагылгандай тезелешеп барганда боларга китмәннәр күтәреп басудан кайтып килүче ике крестьян очраган. Рухани карт крестьяннарга: зинһар, безне бу бәладән коткарыгыз, дип ялвара башлаган. Ләкин крестьяннарның чаң кагучыга килеп орынулары булган, үзләре дә аңа ябышып калганнар. Хәзер инде каз күтәргән Тинтәк артыннан болар җидәүләп теркелдиләр икән.

Тинтәк берзаман үзенең иярченнәре белән бер шәһәргә килеп кергән. Анда хакимлек итүче корольнең буйга җиткән бердәнбер кызы бар икән. Тик ул үтә җитди булып үскән, үз гомерендә бер генә тапкыр да елмайганы юк икән, ди. Шуңа күрә король: «Кем дә кем кызымны көлдерә алса, аны шуңа кияүгә бирәчәкмен», дип фәрман чыгарган булган.

Тинтәк бу хәбәрне ишеткәч, үзенең казын күтәреп, иярченнәре белән бергә туп-туры сарайга юнәлгән. Король кызы җиде кешенең, бер җепкә тагылгандай Тинтәк артыннан лерт-лерт йөгерүләрен күргәч, тәгәри-тәгәри көлә башлаган, бер дә тыела алмый, ди.

Тинтәк корольдән вәгъдәсен үтәүне, кызын үзенә кияүгә бирүне таләп иткән. Ләкин корольгә булачак кияү бер дә ошамаган, кызын аңа бирмәс өчен төрле-төрле хәйләләр эзләргә тотынган, ди.

— Подвалымдагы бөтен шәрабны бер утыруда эчеп бетерерлек кеше тап башта, аннары туй турында сөйләшербез,— дип әйткән, ди, ул.

Тинтәк урманда очраткан теге чал чәчле картны исенә төшереп, менә ул миңа, мөгаен, ярдәм итә алыр иде, дип уйлап алган. Озын-озак баш ватып тормастан, Тинтәк әлеге урманга киткән. Барса, үзе кисеп аударган агач өстендә бер кеше утыра, чырае сытылган, нигәдер борчылуы, хәсрәте йөзенә чыккан, ди. Тинтәк аңардан:

— Ни булды сиңа, нинди бәлагә тарыдың? — дип сораган.

Әлеге кеше:

— Сусавым соңгы чиккә җитте, ни хәл итәргә дә белмим. Салкын суның файдасы юк, сусынымны хәмер генә баса ала. Менә бер мичкә шәрабны бушаттым инде, тик ул кызган ташка тамган бер тамчы кебек кенә булды,— дип җавап биргән.

— Алай булгач, ярдәм итим инде үзеңә,— дигән Тинтәк.— Әйдә минем белән, сусавыңны тәмам кандырганчы эчәрсең!

Тинтәк әлеге кешене сарайга алып килгән дә корольнең шәраб саклый торган нәүрәбенә алып төшкән. Тегесе шунда ук мичкәләрне бер-бер артлы авызына буша-та башлаган. Корсагы таудай кабарганчы эчкән дә эчкән. Әле көн кичкә авышырга да өлгермәгән, нәүрәптәге мичкәләр барысы да буп-буш калган, ди.

Хәзер инде Тинтәк корольдән янә кызны бирүен таләп иткән. Галиҗәнапнең яман ачуы чыккан, бердәнбер кызымны бар дөньяга «Тинтәк» дип даны чыккан бер

юләр шамакайга ничек биреп җибәрим, дип уфтанган. Аннары Тинтәккә тагын бер шарт куеп:

— Иртәгә өеп тау ясарлык ипи пешертермен. Менә шуны бер утыруда ашап бетерердәй кеше тап башта, аннары туй турында сөйләшербез,— дигән.

Тинтәк озын-озак уйлап тормаган, тагын үзе утын кискән урманга юнәлгән. Барса, шул ук ауган агач өстендә билен каеш белән кысып буган бер кеше утыра, ди. Хәсрәте йөзенә чыккан, ди. Тинтәкне күргәч үк ул:

— Мич тутырып ипи пешергән идем, шуны ашап бетердем бетерүен, тик кече телемә дә йокмады. Минем кебек гел ашамлык җитмәүдән интеккән кешегә кем генә ярдәм итә ала икән? Менә, корсагым һаман буп-буш, каешымны ирексездән кысканнан-кыса барам, ачтан үлмәсәм ярар иде,— дип зарлана башлаган.

Тинтәк моңа бик сөенгән.

— Әйдә, тор, киттек минем белән, кикергәнче рәхәтләнеп ашарсың, бер сыйлыйм әле үзеңне,— дигән.

Әлеге кеше белән король сараена килгәннәр болар. Ул арада галиҗәнап үз мәмләкәтендә булган бар онны җыйдырган да бихисап күп итеп ипи пешерткән, аны зур бер тау кадәр өеп куйдырган, ди. Ачлыктан интегүче әлеге кеше ашыга-кабалана ипи тавына ташланган. Көн кичкә авышканда таудан бер валчык та калмаган, ди.

Тинтәк өченче мәртәбә корольдән вәгъдәсен үтәвен, кызын туйлап үзенә кияүгә бирүен таләп иткән. Ләкин король, янә берәр котылу чарасы тапмакчы булып, бу юлы да киреләнеп маташкан.

— Суда да, җирдә дә йөри ала торган кораб ясa да, шуңа утырып, сарай янына йөзеп кил, кызымны сиңа шул чакта гына бирермен,— дигән.

Тинтәк яңадан туп-туры әлеге урманга киткән. Барса, утын кисәргә килгән көнне аңардан ашарга-эчәргә сораган чал чәчле карт басып тора икән.

— Синең өчен ашадым да инде, эчтем дә. Король әйткән корабны да, мөгаен, ясап бирми булмас. Мәрхәмәтле, юмарт күңелле булганың өчен эшлим сиңа боларны,— дигән ул.

Шулай дигән дә Тинтәккә суда да, коры җирдә дә йөри ала торган кораб ясап биргән. Моннан соң король кызын Тинтәккә бирмәс өчен бер сылтау да таба алмаган. Кырык көн уен, илле көн туен иткәннәр, ди, боларның.

Король үлгәннән соң, аның тәхетенә Тинтәк утырган, ди. Хатыны белән бик бәхетле, озын гомер кичергән, ди.

ӨЧ ЯЛЧЫ

Яшәгән, ди, өч ялчы. Алар бер-берсеннән аерылмаска, өчесе дә гел бер шәһәрдә генә эшләргә сүз куешканнар, ди. Күпмедер вакыт үткәч, хуҗаларының кушардай эшләре беткән. Акча килмәгәч, ялчыларның өс-башларына алырлык чамалары да булмаган, киемнәре тузыптеткәләнеп беткән, җан асрарга азыклары да калмаган, ди. Шул чак араларыннан берсе:

— Нишләргә инде хәзер безгә? Монда ятудан мәгънә юк, кәсеп эзләп каядыр сәфәр чыгарга кирәк. Барачак шәһәрдә дә күмәкләп эшләрдәй эш таба алмасак, әйдәгез, болай итик: берәр кунакханәгә керик тә, аның хуҗасы белән сөйләшик. Төрле якка таралышсак та, кайда икәнлегебезне белгертеп, аңа хат язарбыз, аның аркылы бер-беребезнең хәл-әхвәлләрен белешеп торырбыз. Шулай килешкәннән соң, аерылышсак та була,— дип әйткән, ди.

Бу тәкъдим барысына да ошаган. Менә алар эш эзләп юлга чыкканнар. Баралар, баралар икән, каршыларына байларча киенгән бер абзый килә, ди. Ул, ялчыларны туктаткан да, алардан кем булуларын, кая баруларын сорашкан.

— Без — ялчылар, эш эзлибез. Бүгенгә хәтле гел бергә-бергә яшәдек, уртак хуҗа таба алмасак, моннан соң аерылышырга да туры килер инде,— дигәннәр хезмәтчеләр.

— Аерылышуыгызның бер дә хаҗәте юк,— дигән әлеге абзый.— Мин кушканны үтәргә ризалык бирсәгез, эшкә дә, акчага да мохтаҗлык кичермәссез. Хәтта баеп та китәрсез, фаэтоннарда гына йөрерсез.

Ялчыларның берсе:

— Куша торган эшегез бәлагә юлыктырмаслык булса, намусыбызга тап төшермәсә, без бик риза инде,— дигән.

— Юк, юк, мин сезне туры юлдан чыгармам,— дигән әлеге абзый.

Ялчыларның икенчесе әлеге бай абзыйга яхшылабрак күз салган икән, ни күрсен, аның бер аягы кешенеке, икенчесе ат тоягы, ди. Ялчы, моның белән эш йөртмәвең хәерлерәк, дип уйлап алган. Шикләнүен сизеп өлгергән шайтан:

— Һич тә хафаланмагыз, сезгә бернинди зыяным да тимәячәк, монда икенче берәүнең җаны турында гына сүз бара: ул аңардан яртылаш аерылды инде, тиздән тулысынча минеке булырга тиеш,— дигән.

Ялчылар, аның сүзләренә ышанып, тәкъдименә ризалык белдергәннәр. Шуннан соң шайтан аларга үзенең шартын әйткән:

— Сезгә нинди генә сорау бирсәләр дә, беренчегез — «Өчебез дә», икенчегез — «Акча бәрабәренә», өченчегез — «Монысы да дөрес», дип кенә җавап бирергә тиеш,— дигән.

Ялчылар бу сүзләрне отып алып, берсе артыннан икенчесе кабатларга, ни генә булса да, бүтән бер сүз дә әйтмәскә вәгъдә биргәннәр. Әгәр шушы килешүне бозсалар, аларның булган бөтен акчалары шунда ук юкка чыгачак, ә инде вәгъдәләрендә торсалар, кесәләрендә акча һәрвакыт тулы булачак икән. Эшне башлап җибәрер өчен шайтан аларга күтәрә алган кадәр акча биргән дә, фәлән-фәлән шәһәргә барып, фәлән кунакханәдә тукталырга кушкан.

Ялчылар әйтелгән кунакханәгә килеп кергәч, аларны хуҗа үзе каршылаган.

— Ашап-эчеп, ял итеп аласызмы? — дип сораган ул.

— Өчебез дә,— дип җавап биргән беренче ялчы.

— Әлбәттә, мин дә шулайдыр дип уйлыйм,— дигән хуҗа.

— Акча бәрабәренә,— дигән икенче ялчы.

— Шулай булмый ни, бар нәрсә дә акча бәрабәренә инде,— дигән хуҗа.

— Монысы да дөрес,— дип җөпләп куйган өченче ялчы.

Хуҗа да:

— Дөрес булмый ни,— дип раслаган.

Өч дуска тәмле-тәмле ашлар, кыйммәтле эчемлекләр китергәннәр, кыстый-кыстый ашатканнар. Сыйланып туйгач, хуҗа ялчыларның берсенә исәп-хисап язган кәгазь тоттырган.

— Өчебез дә,— дигән беренче ялчы.

— Акча бәрабәренә,— дип сүзгә кушылган икенчесе.

— Монысы да дөрес,— дип куйган өченчесе.

— Дөрес булмый ни,— дигән хуҗа,— өчегез дә түләргә тиеш, акчасыз ашатмаган да булыр идем.

Ялчылар хуҗага сораганнан да күбрәк итеп акча түләгәннәр. Кунакханәдә утыручылар бу хәлне күреп:

— Бу мескеннәрнең акыл яклары чамалырак икән,— диешкәннәр.

— Шулайрак күренә шул,— дигән хуҗа.— Акыл яклары тегеләйрәк ахры!

Ялчылар исә китәргә җыенмаганнар, шушы кунакханәдә яши биргәннәр. Ә үзләре элеккечә: «Өчебез дә»,

«Акча бэрабэренэ», «Монысы да дөрес» дигэн сүзлэрдэн башка бер генэ сүз дэ эйтмилэр икэн. Лэкин үзлэре кунакханэдэге хэллэрнең барысын да күреп-белеп торганнар, нилэр булганны хэтерлэренэ сала барганнар.

Шулай беркөнне кунакханэгэ капчык тулы акча белэн бик бай бер сэүдэгэр килеп кергэн. Хуҗага:

— Эфэндем, минэ шушы акчаларымны ышанычлырак урынга яшереп куй эле. Бу өч юлэр бик сэер күренэлэр, ышаныч юк аларга, акчаларымны урламагайлары тагын,— дигэн.

Хуҗа сэүдэгэр эйткэнчэ эшлэгэн: юл капчыгын алган да үз бүлмэсенэ яшергэн. Капчык ярыйсы ук авыр икэн. Кунакханэ хуҗасы, алтындыр монда, мөгаен, дип уйлап алган. Аннары ул өч ялчыны астагы бүлмэгэ күчергэн дэ сэүдэгэргэ өстэге катта аерым бер бүлмэдэ урын хэстэрлэгэн. Төн урталары җиткэч, хуҗа инде барысы да йоклагандыр дип уйлап, хатынын иярткэн дэ өстэге бүлмэгэ күтэрелгэн, бай сэүдэгэрне шыпырт кына балта белэн чабып үтергэн. Аннары ирлехатынлы яңадан йокларга ятканнар.

Иртэгесен йортта шау-шу купкан. Үтерелгэн сэүдэгэр канга батып түшэгендэ ята икэн. Кунакханэдэге кешелэрнең барысы да шушы бүлмэгэ җыелгач, хуҗа:

— Элеге өч юлэрнең эше генэ бу, мөгаен,— дигэн.

Җыелган кешелэр дэ хуҗага ышанганнар.

— Элбэттэ, шулардан башка кем дэ эшли алмас моны,— диешкэннэр.

Хуҗа өч ялчыны чакырткан да:

— Сэүдэгэрне сез үтердегезме? — дип сораган.

— Өчебез дэ,— дигэн аларның беренчесе.

— Акча бэрабэренэ,— дигэн икенчесе.

— Монысы да дөрес,— дигэн өченчесе.

— Менэ, ишеттегезме? — дигэн хуҗа.— Үзлэре ук икърар итэлэр.

Өч ялчыны шунда ук төрмэгэ илтеп япканнар. Эшнең бик хэтэр якка китэ башлавын аңлаган өч дус курка калган. Лэкин төнлэ алар янына шайтан үзе килеп:

— Тагын бер генэ көн түзегез инде. Карагыз аны, бэхетегездэн колак кага күрмэгез. Борчылмагыз, башыгыздагы бер бөртек чэчегезгэ дэ зыян килмэс,— дигэн.

Иртэгесен ялчыларның өчесен дэ хөкем алдына китергэннэр. Хөкемдар алардан:

— Үтерүчелэр сезме? — дип сораган.

— Өчебез дэ,— дигэн ялчыларның беренчесе.

— Ни өчен үтердегез?

— Акча бэрабэренэ,— дигэн икенче ялчы.

— Сез явызларның да иң яманнары икәнсез,— дигән хөкемдар, — җәзадан да курыкмагансыз.

— Монысы да дөрес,— дип куйган өченче ялчы.

— Гаепләрен үзләре үк икърар иттеләр, өстәвенә эле явызлыклары белән мактаналар да,— дигән хөкемдар.— Хәзер үк үлем җәзасына тартырга үзләрен!

Менә аларны мәйдан уртасындагы җәза урынына алып килгәннәр, ди. Кунакханә хуҗасы да мәйдандагы халык арасында икән. Җәллад ярдәмчеләре ялчыларны эләктереп алганнар да ялтырап торган кылычын күтәргән җәллад янына өстерәгәннәр.

Шулчак кызгылт-сары дүрт ат җигелгән бер фаэтон күренгән. Атлар шундый шәп җилдерәләр, тояк асларыннан очкыннар сибелеп кала, ди. Фаэтон тәрәзәсеннән кемдер ак яулык болгаган.

— Гафу итү билгесе бу,— дигән җәллад.

Фаэтоннан да:

— Гафу итәргә! Гафу итәргә! — дигән тавыш ишетелгән.

Атлар туктагач, фаэтоннан зур дәрәҗәле түрә кыяфәтендә шайтан килеп чыккан, ди.

— Өчегездә дә гаеп юк сезнең,— дигән ул ялчыларга.— Хәзер дөресен сөйләсәгез дә була инде: ни күргәннәрегезне, нәрсә ишеткәннәрегезне барысын да ачып бирегез.

Ялчыларның өлкәне кунакханә хуҗасына төртеп күрсәтеп:

— Сәүдәгәрне үтерүче без түгел. Үтерүче, әнә, халык арасында. Дәлилләр кирәк, дисәгез, барыгыз да базына төшеп карагыз. Ул бәдбәхет һәлак иткән тагын байтак корбаннарны күрерсез анда,— дигән.

Шуннан соң җәллад ярдәмчеләрен кунакханә йортына тентү ясарга җибәргәннәр. Анда барысы да нәкъ менә ялчылар сөйләгәнчә булып чыккан. Дөреслекне белгәч, хөкем итүче җәза мәйданчыгына кунакханә хуҗасын китерергә кушкан, җәлладка шунда ук аның башын чабып өзәргә боерган.

Шайтан өч ялчы янына килгән дә:

— Үзем теләгән җанны менә хәзер кулга төшердем инде мин. Сезне дә биргән вәгъдәгездән азат итәм. Алган акчагыз гомер буе рәхәтләнеп яшәргә җитәр,— дигән.

Аннары үзе шул мизгелдә үк юкка чыккан.

САЛАМ, КҮМЕР ҺӘМ НОГЫТ БОРЧАГЫ

Бер авылда картаеп беткән бер карчык яшәгән, ди. Көннәрдән бер көнне ул, яшелчә бакчасына чыгып, коштабагы тулганчы ногыт борчагы җыйган да шуңардан аш пешермәкче булган. Учагын кабызып җибәргән дә, тизрәк дөрләп китсен өчен, ут эченә бер кочак салам ташлаган. Аннары җыйган борчакны чүлмәккә бушата башлаган. Менә шунда борын төрткән дә инде без сөйлисе эшләр.

Карчык коштабакны бушаткан чагында бер борчак идәнгә тәгәрәп төшкән дә шундагы салам янына килеп яткан. Нәкъ шул турыга учактан бер утлы күмер кисәге дә чәчрәп төшкән, ди. Салам алардан:

— Кайлардан килеп эләктегез сез монда, кадерле дуслар? — дип сораган.

Күмер:

— Бәхетем бар икән әле, ялкыннан сикереп чыктым. Югыйсә баш беткән иде минем, беравыктан янып көл булырга туры килер иде,— дип җавап биргән.

Ногыт борчагы да сүзгә кушылып:

— Минем дә бәхетем бар икән. Юкса, борчак иптәшләрем белән бергә мине дә миһербансыз карчык чүлмәккә салачак иде, бүтәннәр кебек мин дә анда пешеп, изелеп бетәчәк идем,— дигән.

— Минем язмыш та сезнекеннән әйбәтрәк булмас иде,— дип сүз кыстырган салам.— Әбекәй бөтен агай-энеләремне ялкын белән тотенгә әйләндерде, аларны көлтәсе белән янып торган учакка тондырды. Бәхетем булган икән, бармаклары арасыннан шуып төштем дә качып өлгердем.

— Хәзер безгә нишләргә инде? — дип хафаланган күмер.

— Минемчә, менә нәрсә эшлик,— дигән ногыт борчагы.— Бәхеткә каршы үлемнән котылып калганбыз икән инде, моннан соң, әйдәгез, дуслашыйк та бергә-бергә яшик. Киләчәктә тагын берәр бәлагә очрамас өчен тотыйк та күмәкләшеп дөнья гизик!

Борчакның сүзләре барысының да күңелләренә хуш килгән, өчесе бергәләп юлга чыкканнар, ди. Баралар, баралар, ди, болар, берзаман инеш буена килеп җиткәннәр. Зур да, киң дә түгел, ди, инеше, тик аргы якка чыгу бик читен — якын-тирәдә күпер дә, басма да күренми, ди. Инде нишләргә? Уйлана торгач, салам:

— Әйдәгез, болай итәбез: мин бер ярдан икенче яргача сузылып ятыйм, ә сез минем өстән, басма аша үткәндәй, инешне кичәрсез,— дигән.

Шулай эшләгәннәр дә. Инеш ярына килгән дә салам аргы ярга кадәр аркылы сузылып яткан. Кайнар йөрәкле күмер шунда ук кыю адымнар белән яңа салынган басма өстеннән атлап киткән, ди. Ләкин урталыкка җиткәч, аста су шаулавын ишеткән дә курка калган, юлын дәвам иттерергә батырлыгы җитмәгән, ди. Ул арада саламга күмердән ут элеп алган. Бичара салам урталай өзелгән дә инешкә әйләнеп төшкән, ди. Аның артыннан күмер дә гөмберт! Суга чуму белән чыж иткән дә җан биргән, ди.

Сак гомер итәргә гадәтләнгән ногыт борчагы саламбасмага керергә икеләнеп яр буенда торып калган икән. Салам белән күмер язмышын күреп, ул иптәшләреннән шырык-шырык көләргә тотынган. Шаркылдый торгач, шартлаган да урталай ярылган, ди. Ярый әле шунда яр буенда бер тегүче ял итеп утыра икән, югыйсә, эше харап буласы булган борчакның. Күңеле мәрхәмәтле икән останың: инә белән җеп алган да, урталай ярылган борчакны кире беректереп тегеп куйган, ди. Ногыт аңа мең-мең рәхмәтләр яудырган. Тик менә тегүченең кирәкле җебе юк икән, бичараны ул кара җеп белән генә җөйләгән. Шушы хәлдән соң ногыт борчакларының барысының да уртасы кара җөйле булып калган, ди.

БОТКАЛЫ ЧҮЛМӘК

Әүвәл-әүвәл заманда әнисе белән бер кыз яшәгән, ди. Тыйнак кына, фәкыйрь генә гомер иткәннәр болар. Бер заман ашарларына беткәч, ни дә булса таба алмаммы дип, кыз урманга киткән. Шунда җиләк җыеп йөргәндә аңа бер карчык очраган.

— Исәнме, кызый, миңа бераз җиләк бирче? — дигән ул.

Кыз:

— Мә, әбекәй,— дип җавап биргән.

Карчык җиләкне ашаган арада кыздан хәл-әхвәл дә сорашкан. Аннары:

— Син миңа җиләк бирдең, мин дә сиңа бер бүләк бирим әле. Менә сиңа чүлмәк. Әгәр аңа:

Бер, ике, өч,
Ботка, пеш! —

дисәң, ул сиңа бик тәмле ботка пешерә башлар. Ә инде:

Бер, ике, өч,
Тукта, җитте ич! —

дисәң, ул туктар,— дигән.

Кыз рәхмәт әйтеп чүлмәкне алган да сөенә-сөенә әнисе янына кайтып киткән. Әнисе дә чүлмәккә бик куанган. Ачлы-туклы яшәүдән котылып, мәшәкатьсез-нисез тәмле тары боткасын туйганчы ашый башлагач, ничек куанмыйсың инде?

Менә беркөнне кыз каядыр чыгып киткән, ди. Өйдә үзе генә калган әнисе, ашыйсы килә башлауга, чүлмәкне каршысына куйган да:

Бер, ике, өч,
Ботка, пеш! —

дигән икән, чүлмәк ботка пешерергә тотынган. Туйганчы ашагач, карчык чүлмәкне эштән туктатмакчы булган, тик моның өчен нинди әмер бирергә кирәклеген оныткан, ди. Ә чүлмәк ботканы һаман пешерә дә пешерә икән. Инде ботка белән бөтен бүлмә тулган, аннары ул өйалдына ташып чыккан. Ә чүлмәк һаман пешерүен генә белә икән! Тора-бара ботка бөтен урамны тутырган, ди. Кызның анасы, куркып, кызын эзләргә йөгереп чыккан икән дә, юлны аркылы үтә алмаган, анда кайнар ботка елга булып ага башлаган. Шулай итеп кеп-кечкенә чүлмәктә пешкән ботка бик зур бәлагә әверелгән, беркем дә бу бәладән ничек котылу чарасын белмәгән, ди.

Авылда боткага күмелмәгән бер генә өй калган, карчыкның кызы әнә шул өйдә ләчтит сатып утыра икән. Берзаман урамдагы хәлләрне күреп алган да ашыгып өенә йөгереп кайткан. Ничек кирәк алай баскыч башына менгән дә, ишекне ачып:

Бер, ике, өч,
Тукта, җитте ич! —

дип кычкырган.

Чүлмәк шунда ук ботка пешерүдән туктаган, ди.

Ә ботканы ул шул чаклы күп пешергән ки, авылдан шәһәргә баручыларга ботка ашый-ашый үзләренә юл салырга туры килгән. Тик моңа берәү дә зарланмаган, сукранмаган, ди.

УНИКЕ ЯЛКАУ

Яшәгән, ди, бер заманны унике ялчы. Алар көннеңкөн буена бер нәрсә дә эшләмәгәннәр, кичләрен дә тир түгеп артык мәшәкатьләнергә яратмаганнар, ди. Бергә

җыелып, чирәмгә сузылып яталар да һәркайсы үзенең ялкаулыгы белән мактана башлый, ди. Аларның беренчесе сүзен менә болай башлап җибәргән:

— Сезнең ялкаулыгыгыз миңа нигә хаҗәт, үземнеке дә чигеннән ашкан. Төп эшем — тамак кайгырту. Ашарга дигәндә, шәп сыптырам анысы, эчәргә дигәндә дә кимен куймыйм. Дүрт кеше ашаганны ашыйм, чама белән генә ураза тотам. Шулай иткәндә хәйран әйбәт була икән үзе. Иртә таңнан йокыдан торуны беләсем дә килми, төш якынлаша башлады исә, берәр аулаграк урынга элдертәм. Хуҗам чакырса, ишетмәмешкә салышам. Әгәр дә инде икенче тапкыр кычкырса, киерелә́м-сузылам да, теләр-теләмәс кенә урынымнан кузгалам, аннары атлар-атламас кына янына барам. Менә шулай яшәп ятам инде,— дигән.

Икенче ялчы сүзгә кушылып:

— Ә миңа ат карарга туры килә менә,— дигән.— Карыйсың инде башыңа төшкәч: авызлыгын-ниен салдырып торыш юк, билгеле. Кәефем югында печән-фәлән дә биреп маташмыйм. Хуҗам күрә-нитә калса, салган идем, ашап бетергәндер, дип кенә котылам. Ә үзем солы тутырган улакка кереп ятам да дүрт-биш сәгатьләр чамасы йокы бөкләп алам. Аннары иренеп кенә аякларымны сузып җибәрәм, торып бер-ике мәртәбә атның аркасына кагылам — чистартам, янәсе. Мине кем тикшереп бетерсен, шома гына уза шулай. Тик барыбер авыр тоела бу хезмәт миңа,— дип сөйли икән.

Өченче ялчы сүз башлап:

— Үзеңне нигә шулай эш белән интектерергә? — дигән.— Бетәсе бармыни аның? Мин үзем кояш карагая рак төшкә ятам да рәхәтләнеп йоклыйм. Болыт чыгып яңгыр сибәли башласа да, әллә ни исем китми. Яңгыр төшә дип, иренмичә нигә әле урынымнан кузгалыйм, ди? Әйдә, рәхәтләнеп тик ява бирсен. Күптән түгел бик үҗәтләнеп явып карады ул, койды гына, башымдагы чәчләремә кадәр йолкып алып агызды, сөякләремә кадәр тишкәләп бетерде. Чүпрәк ябыштыргалап куйган идем, тәзәлде тагын җәрәхәтләрем, берни дә булмады. Мондый авырлыкларга түзү җиңел түгел, билгеле, әмма бирешмим әле,— дип мактанган.

Дүртенче ялчы да аны куәтләп:

— Ә мин эшкә тотынганчы башта шактый вакыт арлы-бирле селкенгәләп йөрим, шулай берәр сәгать вакытны уздырам,— дигән.— Аннары ашыкмыйча гына кыймылдый башлагандай итәм, үзем хуҗамнан: шунда берәрсе булышсын иде, ичмасам, өлгереп булмый ич

инде,— дип ярдәм сорыйм. Ярдәмгә килүчегә, билгеле инде, эшнең иң авырын кушам, үзем шуңа күз-колак булып кына йөрим. Әмма анысы да артык авырга туры килә эле,— ди икән.

Бишенче ялчы:

— Сөйләгән буласыз тагын, шул да булдымы авырлык? — дип дәвам иттергән.— Сез менә минем хезмәтемне күз алдына китерегез әле. Әйтик, ат абзарыннан тирес чыгарырга, аны арбага төяргә кирәк. Ашыккан — ашка пешкән, диләр. Шуңа күрә мин сәнәккә сак кына тотынам. Тиресне чеметемләп кенә эләктерәм дә, яртылаш күтәргәч, чирек сәгать чамасы ял итеп алам, аннары гына арбага ташлыйм. Көнозын бер арба төясәм, җитмәгәнмени? Хәлдән тайганчы эшләргә юләр түгел лә мин! — дигән.

Алтынчы ялчы:

— Оят түгелме сезгә? Менә мин бернинди эштән дә курыкмыйм ичмасам,— дигән.— Дөрес, өстемдәге киемемне салып тормастан өч атналап урынымнан кузгалмыйча түшәктә ауныйм аунавын. Соң үзегез уйлап карагыз: кигән саен сандал бавын эләктереп азаплану җиңелме әллә? Баусыз булса, аяктан төшеп калыр иде, дисезме? Төшсә соң, аның каравы мәшәкате кими. Әгәр дә мәгәр баскычтан менәргә туры килсә, мин башта иренеп кенә бер аягымны басмага куям да тагын ничә баскыч күтәреләсем калганын саныйм, аннары кайсы баскычта туктап ял итәсемне чамалыйм. Менә шундый кыен инде ул безнең эшләр,— дигән.

Җиденче ялчы:

— Минем хәлләр сезнекеннән дә хөртирәк шул. Эшләгәнемне хуҗам күзәтеп кенә тора,— дигән.— Дөрес, көндезләрен өйдә булмый булуын, шулай да хәлемнән килгәнчә тырышам инде. Бушка киләп сарсам да, тегендә-монда йөргәндәй итәм, кайчакларда аркылыны буйга алып салам. Мине кузгатулары бик җиңелдән түгел үзе, таза дүрт ир бар куәтләренә төрткәләсәләр генә инде. Шулай бервакыт өйгә килеп керсәм, сәндерәдә кемдер йокы симертә. Көнләштем, озын-озак уйлап тормастан, үзем дә шуның янына аудым. Шунда ук гырлап та киткәнмен. Бәхетсезлеккә каршы, вакытсыз чакта хуҗам ниндидер эш кушмакчы булган миңа. Ләкин бер йоклагач кая инде ул мине уяту! Сәндерәдән күтәреп төшергәннәр дә ишегалдына алып чыкканнар. Күземне ачмакчы да булам, тик хәлемнән генә килми,— дип сөйләгән.

Сигезенче ялчы да сүзсез калмаган.

— Мин барыгыздан да җитезрәк булсам кирәк,— дигән.— Әйтик, барыр юлымны бүлеп бер таш ята, ди. Атлап чыгам дип, иренмичә аягымны күтәреп азапланмам ич инде! Саз димим, пычрак димим, сузылам да ятам шул таш янына. Күлдәвекне кояш тәмам киптереп бетермичә селкенмим дә. Кояш бераз җылытсын дип, икенче ягыма әйләнеп ятсам гына инде. Мәгәр җир кипсә, тормый хәлем юк, ашыга-ашыга кыймылдыйм — тәүлек эчендә ташны әйләнеп узарга тырышам,— дигән.

Тугызынчы ялчы мактанып:

— Искитәрлек нәрсәсе бар инде моның? Менә минем хәлләрне, ичмасам, сөйләсәң дә ярый,— дигән.— Ятам шулай бервакыт, алдымда гына мичтән яңа чыккан бөтен ипи тора. Тамак ач, тик шулай да ипине сузылып алырга иренәм бит, көчкә-көчкә ачтан үлмәдем. Янәшәмдә генә су тулы чынаяк тора, ләкин ул артык зур, иләмсез авырдыр кебек тоелды, шуңа күрә, бик каты авызым кипсә дә, шуны үрелеп алырга ирендем. Ята-ята кабыргаларым эчемә ябышып бетте, икенче ягыма әйләнергә кирәк иде, ялкаулыгым селкенергә дә ирек бирми бит, каһәр. Тәки шулай бүрәнә кебек кыймылдамыйча да яттым көне буе.

Унынчы ялчы:

— Мин дә бәлагә очрадым әле шул ялкаулыгым аркасында,— дигән.— Аягымны сындырдым, күрәсезме, ботларым ничек кабарып чыккан. Ничек булды дисезме? Шулай юл кырыенда ята идек өч ялкау. Киерелдем дә аякларымны юл уртасына сузып җибәрдем. Аннан бер олау килә икән, шул юньсез аякларымны таптап, өстемнән чыгып китмәсенме? Әлбәттә, аягымны тартып алырга мөмкин иде, тик арба килгәнне ишетми калдым, колак төбемдә черкиләр безелди иде. Борыннан керәләр дә авыздан чыгалар, ләгънәтләр. Куып кына җибәрәсе калган да бит үзләрен, ялкаулыгым кымшанырга ирек бирмәде,— дигән.

Унберенче ялчы да мактанырга оста икән.

— Кичә эшемне ташлап киттем әле мин,— дигән.— Туйдырды хуҗама китаплар биреп тору. Дөрес, укуын ул үзе укый иде, тик аларны алып бирәсе, җыеп куясы да бар ич әле. Көн саен шул хәл — очы да, кырые да күренми. Әле ярый, хуҗам карышып тормады, әйтүем булды, шунда ук чыгарып җибәрде. Беркайчан да киемнәрен чистартмадым бит мин аның, көяләр кискәләп бетергән үзләрен, каһәр төшкере! Үземнең киемнәр дә, күрәсездер, шундыйрак хәлдә. Ирендерә шул,— дип сүзен бетергән.

Уникенче ялчы иптәшләре сөйләгәннәрне болай дип йомгаклап куйган:

— Бүген ат белән басуга чыгарга туры килде миңа. Арбама бераз салам салдым да шуңа күмелеп йокларга яттым. Бара-бара дилбегәм кулдан ычкынган бит, корт чаккыры. Уянып китсәм, ат тугарылган да китеп барган. Аркалык та, камыт та, ыңгырчак та, йөгән дә юк, ниндидер юлаучы барысын бергә чәлдереп сыпырткан, күрәсең. Аның каравы, көпчәкләр калган. Пычракка кереп батканнар, кая инде аларны салдырып алу, селкетерлек тә түгел, баткан җиреннән чыгарып булыр дип тә уйлыйсы юк. Баткан икән, әйдә, тора бирсен шунда, дидем дә яңадан саламга күмелеп гырылдый башладым. Ярый әле, хуҗам үзе килгән дә арбаны баткактан сөйрәп чыгарган. Югыйсә, сезнең белән сүз куертып маташа алмаган булыр идем хәзер. Арбадагы саламга күмелгән килеш әле һаман тәмле төшләр күрә-күрә йоклап ятар идем.

ЗИРӘК ҺАНС

Әнисе улыннан:

— Кая киттең, Һанс? — дип сорый.

Һанс:

— Грительь янына,— дип җавап бирә.

— Әйбәт кенә йөр, Һанс, яме!

— Ярый, ярый, сау бул, әнкәй!

Һанс дусты янына килә.

— Хәерле көн, Грительь!

— Хәерле көн, Һанс! Нинди әйбәт әйбер алып килдең?

— Берни дә алып килмәдем. Үзең бирсәң, алыр идем.

Грительь Һанска бер инә бүләк итә.

— Сау бул, Грительь! — ди Һанс.

— Сау бул, Һанс!

Һанс инәне ала да печән төягән олауга кадап куя. Ә үзе арба артыннан кайта. Өйгә килеп кергәч, Һанс әнисенә:

— Хәерле кич, әнкәй! — ди.

— Хәерле кич, Һанс! Кайларда йөрдең?

— Грительь янында булдым.

— Грительгә нәрсә алып бардың соң?

— Бернәрсә дә алып бармадым, үзеннән алдым.

— Ә Грительь нәрсә бирде?

— Инә бирде.

— Кайда соң инәң, Һанс?
— Печән олавына кадаган идем.
— Юләрлек эшләгәнсең, Һанс. Инәне җиңеңә кадарга иде.
— Ярый алайса, икенче шулай итәрмен...
— Кая киттең, Һанс?
— Гритель янына, әнкәй.
— Әйбәт кенә йөр, Һанс, яме?
— Ярый, ярый, сау бул, әнкәй!
— Сау бул, Һанс!
Һанс дусты янына килә.
— Хәерле көн, Гритель!
— Хәерле көн, Һанс! Нинди әйбәт әйберләр алып килдең?
— Берни дә алып килмәдем. Үзең бирсәң, алыр идем.
Гритель Һанска бер пычак бүләк итә.
— Сау бул, Гритель!
— Сау бул, Һанс!
Һанс пычакны ала да җиңенә кадап куя. Аннары өенә таба атлый.
— Хәерле кич, әнкәй!
— Хәерле кич, Һанс! Кайларда йөрдең?
— Гритель янында булдым.
— Грительгә нәрсә алып бардың соң?
— Бер нәрсә дә алып бармадым, үзеннән алдым.
— Ә Гритель нәрсә бирде?
— Пычак.
— Кая соң ул пычагың, Һанс?
— Җиңемә кадаган идем.
— Юләрлек эшләгәнсең, Һанс. Пычакны букчаңа салырга иде.
— Ярый алайса, икенче шулай итәрмен...
— Кая киттең, Һанс?
— Гритель янына, әнкәй.
— Әйбәт кенә йөр, Һанс, яме?
— Ярар, ярар. Сау бул, әнкәй!
— Сау бул, Һанс!
Һанс дусты янына килә.
— Хәерле көн, Гритель!
— Хәерле көн, Һанс! Нинди әйбәт әйберләр алып килдең?
— Берни дә алып килмәдем. Үзең бирсәң, алыр идем.
Гритель Һанска кәҗә бәтие бүләк итә.
— Сау бул, Гритель!

— Сау бул, Һанс.

Һанс кәҗә бәтиен ала да аякларын бәйләп букчасына салып куя. Өйгә кайтып җиткәндә кәҗә бәтие инде тончыгып үлгән була.

— Хәерле кич, әнкәй!

— Хәерле кич, Һанс! Кайларда йөрдең?

— Гритель янында булдым.

— Гритель гә нәрсә алып бардың соң?

— Бер нәрсә дә алып бармадым, үзеннән алдым.

— Ул нәрсә бирде?

— Кәҗә бәтие.

— Кәҗә бәтиең кайда соң, Һанс?

— Букчама салган идем.

— Юләрлек эшләгәнсең, Һанс. Кәҗә бәтиенең муенына бау тагып җитәкләп кайтырга иде.

— Ярый алайса, икенче шулай итәрмен...

— Кая киттең, Һанс?

— Гритель янына, әнкәй.

— Әйбәт кенә йөр, Һанс, яме?

— Ярар, тыныч бул. Хуш, әнкәй!

— Сау бул, Һанс!

Һанс дусты янына килә.

— Хәерле көн, Гритель!

— Хәерле көн, Һанс! Нинди әйбәт әйберләр алып килдең?

— Берни дә алып килмәдем. Үзең бирсәң, алыр идем.

Гритель Һанска шактый зур төргәк тозланган дуңгыз мае бирә.

— Сау бул, Гритель!

— Сау бул, Һанс!

Һанс, дуңгыз мае төргәген бер бауга бәйләп, җир буйлап сөйрәп алып кайтып китә. Һанс артыннан бер көтү эт иярә. Юлда алар дуңгыз маеның валчыгын да калдырмыйча ашап бетерәләр. Өенә кайтып җиткәндә Һанс кулында бау кисәгеннән башка берни дә калмый.

— Хәерле кич, әнкәй!

— Хәерле кич, Һанс! Кайларда йөрдең?

— Гритель янында булдым.

— Грительгә нәрсәләр алып бардың соң?

— Бер нәрсә дә алып бармадым, үзеннән алдым.

— Ә Гритель нәрсә бирде?

— Бер төргәк тозлаган дуңгыз мае бирде.

— Кая соң ул дуңгыз маең, Һанс?

— Бауга бәйләп тартып кайткан идем, арттан килеп этләр ашап бетергән.

— Юлэрлек эшлэгэнсең, Һанс. Майны иңбашыңа асып кайтырга кирэк иде.
— Ярар, алайса, икенче тапкыр шулай итэрмен...
— Кая киттең, Һанс?
— Гритель янына, энкэй.
— Әйбэт кенэ йөр, Һанс, яме?
— Ярар, барысы да эйбэт булыр. Хуш, энкэй!
— Сау бул, Һанс!
Һанс дусты Гритель янына килэ.
— Хэерле көн, Гритель!
— Хэерле көн, Һанс! Нинди эйбэт эйберлэр алып килдең?
— Берни дэ алып килмэдем. Үзең бирсэң, алыр идем.
Гритель Һанска бозау бүлэк итэ.
— Сау бул, Гритель!
— Сау бул, Һанс!
Һанс хайванны җилкэсенэ атландырып, кайтыр юлга чыга. Бозау аяклары белэн тыпырчынып, Һансның бөтен битлэрен яргалап бетерэ.
— Хэерле кич, энкэй!
— Хэерле кич, Һанс! Кайларда йөрдең?
— Гритель янында булдым.
— Гритель гэ нинди бүлэклэр алып бардың соң?
— Бер нэрсэ дэ алып бармадым, үзеннэн алдым.
— Ә ул нэрсэ бүлэк итте?
— Бозау бирде.
— Кайда соң ул бозавың, Һанс?
— Җилкэмэ атландырып кайтып килэ идем, менэ бөтен битлэремне яргалап бетерде.
— Юлэрлек эшлэгэнсең, Һанс. Бозауның муенына муенчак кидереп, шуңа җеп тагып, җитэклэп кенэ кайтырга да абзарга ябып куярга кирэк иде.
— Ярый алайса, икенче мэртэбэ шулай итэрмен...
— Кая киттең, Һанс?
— Гритель янына, энкэй.
— Әйбэт кенэ йөр, Һанс, яме!
— Ярар, ярар, тыныч бул. Хуш, энкэй!
— Сау бул, Һанс!
Һанс дусты янына килэ.
— Хэерле көн, Гритель!
— Хэерле көн, Һанс. Нинди эйбэт эйберлэр алып килдең?
— Берни дэ алып килмэдем. Үзең бирсэң, алыр идем.
Гритель Һанска:

— Бу юлы сиңа ияреп үзем барам,— ди.

Һанс Грительнең муенына муенчак кидерә, муенчагына бау тага да җитәкләп кайта. Өйләренә кайтып җиткәч, кызны абзарга кертеп яба, муенындагы бавын, ычкынмаслык итеп, улак почмагына бәйләп куя. Шуннан соң өйгә энисе янына керә.

— Хәерле кич, энкәй!

— Хәерле кич, Һанс! Кайларда йөрдең?

— Гритель янында булдым.

— Грительгәниләр алып бардың соң?

— Бер нәрсә дә алып бармадым.

— Ә дустың нәрсә бирде?

— Берни дә бирмәде, үзе ияреп килде.

— Грительне кайда калдырдың соң?

— Муенына бау бәйләдем дә җитәкләп алып кайттым, аннары абзарга кертеп, алдына печән салып куйдым.

— Юләрлек эшләгәнсең, Һанс. Аңа ягымлы күз карашларыңны ташларга кирәк иде.

— Ярый алайса, шулай итәрмен.

Һанс кире абзарга чыга. Андагы бөтен бозаулар белән сарыкларның күзләрен чокып-чокып ала да, аңа ягымлы күз карашы кирәк, дип, Гритель өстенә ташлый. Грительнең моңа яман ачуы чыга, бәйдән ычкына да өенә йөгерә.

Менә сиңа хәлләр! Гритель Һансның ярәшелгән кәләше булган лабаса!

ӘКИЯТ-ТАБЫШМАК

Өч хатын, сихер тылсымы белән, басуда үсеп утыручы чәчәкләргә әверелгәннәр. Һәр төнне аларның берсе яңадан хатын-кыз кыяфәтенә керә дә өенә кайтып килә икән. Бер заман шулай өенә кайткан хатыннарның берсе, таң беленеп, иптәшләре янына китәр вакыты җиткәч, иренә:

— Әгәр син бүген кояш күтәрелә башлаганчы басуга чыгып мине өзеп алсаң, сихердән котылыр, бөтенләйгә яныңда калыр идем,— дигән.

Шулай булып чыккан да. Тик менә аптыраш: нәкъ бер төсле өч чәчәк арасыннан бу ир үзенең хатынын ничек таный алды икән?

ҖАВАП: Зирәк ир хатынының өйдә кунуын, шуңа күрә төне буе басуда булмавын исендә тоткан. Таң алдыннан кырдагы чәчәкләргә чык төшкән, ә аның чык

төшкәннән соң гына чәчәккә әверелгән хатынына нәни генә дым кунарга да өлгермәгән. Менә шул билге буенча ул үзенең хатынын таныган да сихер тылсымыннан азат иткән.

ГОМЕР ОЗЫНЛЫГЫ ТУРЫНДА

Тәңре дөньяны барлыкка китергәндә барча җан ияләренең күпме гомер яшәргә тиешлеген дә билгеләмәкче булган. Шул чак аның янына бер ишәк килгән дә:

— Мин бу дөньяда ничә ел яшәрмен икән? — дип сораган.

— Утыз ел,— дип җавап биргән тәңре.— Шул җитәдер ич?

— Әй, тәңрем,— дигән ишәк,— бу минем өчен артык күп була лабаса. Нинди михнәтләр чигеп яшәвемне уйла син башта. Иртә таңнан караңгы төнгәчә авыр йөк ташыйм, бүтәннәр күмәч ашасын дип, тегермәнгә ашлык тутырылган капчыклар илтәм. Ә боларның барысы өчен әрләү-кыйнаудан башка нәрсә күрәм соң мин? Менә шуны истә тотып, гомеремне кыскарак итсәң иде, тәңрем!

Тәңре ишәкне кызганган, гомерен унсигез ел итеп кенә калдырган. Озын колак тынычланып китеп барган.

Хәзер инде тәңре янына эт килгән.

— Күпме яшәргә теләгең бар? — дип сораган тәңре аңардан.— Ишәккә утыз ел бик күп булып тоелды. Сиңа шулкадәр гомер итү ярыйдыр ич?

— Тәңрем,— дип җавап биргән эт.— Сайлау үз ирегемдәме, әллә инде бу синең әмереңме? Уйлап кара әле: көн саен күпме әрле-бирле чабарга туры килә миңа? Юк, аякларым чыдамаячак андый озын гомергә. Өстәвенә, өрергә тавышым бетсә, тешләргә тешләрем калмаса, кемгә кирәгем бар минем? Бер җирдән икенче җиргә сөйрәлеп йөрү, ырылдаудан гайре ни эшкә ярармын аннары?

Тәңре маэмайның да хаклы булуын чамалаган, бичараны кызганып, гомерен унике ел итеп кенә калдырган.

Бераздан тәңре янына маймыл килгән.

— Син, мөгаен, утыз ел яшәргә риза булырсың әле? — дигән аңа тәңре.— Ишәк яки эт кебек көне-төне хезмәт итәсең юк, бар гомерең уен да көлке, шамакайлану белән генә үтә.

— Әй, тәңрем,— дигән маймыл,— читтән генә шулай җиңел күренә ул. Чынында минем хәлләр бер дә кызы-

гырлык түгел. Могҗиза белән куктән тары боткасы ява башласа, ашарга кашыгым булмый. Кешеләрне көлдерер, күңелләрен ачар өчен һәрвакыт кыланырга, авызларымны кыйшайтырга туры килә миңа. Әгәр инде аратирә берәрсе юмартланып алма телеме сузса, ул чыраеңны сыттырырлык ачы була. Шаянлык артында еш кына кайгы-хәсрәт яшеренеп тора, моны белмиләр генә. Юк, юк, утыз елга түзә алмаячакмын мин.

Тәңре маймылга да шәфкать күрсәткән, гомерен ун ел гына иткән.

Менә берзаман тәңре янына кеше килгән. Шат күңелле, таза-сау кыяфәтле, җитез хәрәкәтле икән. Килгән дә тәңредән гомеренең озынлыгын билгеләүне үтенгән.

— Утыз ел яшәрсең,— дигән тәңре.— Шул җитәдер ич?

— Тәңрем, бик аз була лабаса бу,— дип ризасызлык белдергән кеше.— Үземә аерым йорт өлгертеп башка чыкканчы, үз учагымда утымны кабызганчы, утырткан агачларым чәчәк атып җимеш бирә башлаганчы күпме гомерләр уза! Тормыштан тәм табып, куанып-сөенеп яши генә башлаганда үләргә дә вакыт җитә дигән сүз ич бу! Хәлемә кер, озайт инде бераз гомеремне, тәңрем!

— Ярар алайса, сиңа тагын ишәк гомерен өстәрмен,— дигән тәңре.

— Ул гына бик аз була шул, тәңрем,— дип кеше яңадан ризасызлык белдергән.

— Алайса өстәмә итеп эт гомерен дә алырсың.

— Алай да азрак була шул әле, тәңрем.

— Күргәч күр инде игелегемне,— дигән тәңре.— Сиңа маймыл гомерен дә кушармын тагын. Ләкин бу соңгысы, моннан тыш бер генә ел да өмет итмә, бирә алмыйм.

Кеше китеп барган, ләкин ул барыбер язмышыннан канәгать булмаган әле.

Шулай итеп адәм баласының гомер озынлыгы җитмеш ел булып калган. Беренче утыз елы — үзенеке, ул еллар сизелми дә үтеп китә. Бу чорда кеше сау-сәламәт, таза була, ару-талуны белми эшли, тормышына сөенеп туя алмый. Шуннан соң унсигез еллык ишәк гомере башлана, бу дәвердә кешегә авырлык өстенә авырлык өелеп кенә тора. Бүтәннәр тук булсын өчен икмәк үстерә, терлек карый, әмма шул мәшәкатьле хезмәте өчен аңа гел тир түгәргә, эссесенә-суыгына чыдарга туры килә. Аннары унике еллык эт гомере килеп җитә, бу елларда кеше эт кебек үзенә җылы, йомшак почмак таба

алмый, зарлана, сукрана башлый, ризык чәйнәргә тешләре дә тузып беткән була. Эт еллары үтеп киткәч, ун еллык маймыл гомере башлана. Бу вакытта кеше дигәнең әкренләп акылга җиңеләя, күзгә күренеп исәрләнә, төрле юләрлекләр эшли башлый. Бу соңгы гомерендә аңардан кайчак балалар да көлә.

ӘКӘМӘТЛӘР ИЛЕНДӘГЕ ГАҖӘЕП ХӘЛЛӘР

Әкәмәтләр заманында киттем шулай хикмәтләр иле буйлап. Карыйм, нечкә генә бер ефәк җеп белән Рим шәһәре күккә асып куелган. Рим папасының олы чиркәве әллә кайдан күзгә бәрелеп тора. Алга табарак барсам, ике аяксыз бер кешенең юртакны да узып җилдән җитез йөгерүенә шаһит булдым. Ә бер үткен кылыч зур чуен күперне урталай ярды да салды. Көмеш борынлы япь-яшь бер ишәк күрдем тагын, очкан уктан да тизрәк йөгерүче ике куян артыннан куып бара иде. Янә дә бер юкә агачына тап булдым: ярты дөньяны каплап алган ботакларында кайнар кабартмалар үсеп утыра. Аннары коры сөяккә калган бер карт, арык кәҗәне очраттым, аркасында йөз олау эретелгән май белән алтмыш олау тоз күтәреп бара иде.

Әле бик әз ялганладыммыни? Алайса тагын тыңлагыз: кителгәләп-күгәреп беткән бер сабан күрдем. Ат та, үгез дә тартмый үзен, барыбер ялгыз башы ду китереп җир сөреп йөри. Әле яше дә тулмаган сабый бала исә зур-зур дүрт тегермән ташын берьюлы күтәреп алды да башта Регенсбург шәһәренә, аннары Трирга, Трирдан Страсбург каласына чөеп җибәрде. Ә бер карчыга Рейн аша йөзеп чыкты. Чын, чын, югыйсә, елга аръягына ничек чыга алыр иде икән ул? Шулвакыт балыкларның үзара кычкырышып шау-шу куптарганнарын да ишеттем, бигрәк колак тондырырлык итеп акыралар да инде. Ул да түгел, тирән үзәннән биек тау башына таба татлы бал елгасы ага башлады. Үзе нәкъ су кебек. Менә ниндирәк әкәмәтләр дә була ул дөньяда!

Бара-бара печән чабучы ике карга очраттым. Шунда ук ике черки елга аша күпер салып ята иде. Ул да түгел, ике күгәрчен йөгереп килделәр дә бозау кадәр бүрене өзгәләп ташладылар. Ике бәбинең дәү-дәү кәҗә тәкәләрен һавага чөеп уйнауларын, ике бакаың көлтә сугып ятуларын да күрдем әле. Бара торгач, ике тычканның бер руханига епископ дәрәҗәсе биргән вакыт-

ларына туры килдем. Шул арада ике мәче бер аюның телен йолкып алдылар. Бер тәкә йөгереп килде дә ике ерткыч арсланны буып ташлады. Шунда гына бер чәчтараш та тора икән, яшь кенә бер кызның сакалын кырып маташа. Ике имчәк баласы, җитәр инде сезгә, дип, эти-әниләрен акылга утырттылар.

Бер тегермәнне судан ярга сөйрәп чыгарырга маташкан ике ау эте очраттым тагын. Бер йолкыш алаша аларны, шул кирәк сезгә, дип тиргәп тора. Тик әкәмәтнең дә әкәмәте алда икән әле: дүрт тай, тиргә батып, ындырда ашлык сугып ята. Ике кәҗә мич ягып азаплана, ә җирән сыер мичкә ипи салып тора. Шул чак дөнья яңгыратып этәч кычкырып җибәрмәсенме: әкият тәмам, ки-ке-ри-күк ди, ди.

МЕҢ ДӘ БЕР ЯЛГАН

Әкәмәт хәлләр турында сөйлисем килә әле сезгә. Кичә пешереп майда кыздырылган ике тавыкның һавада очып барганнарын күрдем. Шундый шәп очалар, үзләре корсакларын җиде кат күккә терәгәннәр, сыртлары туп-туры җәһәннәмгә орынган. Тагын... тимерче сандалы белән тегермән ташы әкрен генә дулкыннарда чайкала-чайкала Рейн елгасы буйлап йөзепме йөзәләр. Ә бер бака боз өстенә чыгып утырган да сабан төрәнен кимереп ята. Шунда дүрт егет тә бар иде. Үзләре куян куарга җыенганнар, үзләре, таякка таянып, биек агач күтәрмәләрдә йөриләр. Өстәвенә, егетләрнең берсе саңгырау, икенчесе сукыр, өченчесе телсез, дүртенчесе аксак.Ниләр булып беткәнен белергә телисезме? Басу буйлап йөгергән куянны беренче булып сукыр күреп алды. Телсез аксакка: әнә куян, дип кычкырды. Аксак исә, йөгереп барып, куянны колакларыннан эләктереп алды.

Тагын шунда берничә кеше көймәгә җилкән куеп маташа, басу буйлап йөзәргә җыеналар иде. Җилкәннәрен куюлары булды, киттеләр болар җил уңаена игеннәр өстеннән йөзеп: биек таулар аша да кичеп чыктылар, әмма коры җирдә батып үлделәр, мескеннәр. Янә дә бер кысла җан-фәрман куян артыннан йөгерә, өй түбәсендә үзе шунда очып менгән бер сыер ята иде. Әлеге мин сөйләгән илдә чебеннәр шундый дәүләр, бездәге иң зур кәҗәләр дә аларга тиңләшә алмас иде.

Хәзер инде тиз генә тәрәзәгезне ачыгыз, мин сөйләгән бөтен ялганнар очсын да китсен.

АЛТЫН АЧКЫЧ

Бөтен җир калын кар юрганы белән капланган кышкы көннәрнең берсендә фәкыйрь генә бер малай, кечкенә чанасын тартып, утын алып кайтырга урманга киткән, ди. Коры-сары җыеп чанасына төягән бу. Йөри торгач, сәләмә киемле малай бик нык туңган. Шуңа күрә ашыкмаска булган, учак ягып бераз җылынып алырга уйлаган. Учак өчен урын әзерләп, кар көри башлаган. Менә туң җир дә күренгән. Караса, җирдә бер алтын ачкыч ята икән. Ачкычы булгач, йозагы да табылырга тиеш моның, дип уйлаган малай. Аннары яңадан җирне казырга керешкән. Казый торгач, кечкенә генә бер тимер сандык килеп чыккан. Малай, ачкычы яраса, бик әйбәт булыр иде, бу сандыкта кыйммәтле әйберләр дә бардыр, мөгаен, дип үзалдына сөйләнә икән. Караштыра башлаган сандыкны, ләкин йозагыфәләне дә күренми, ди. Шулай да капшый торгач ачкыч тишеге сыман бер ярыкны шәйләп алган. Ул ярык шулкадәр кечкенә, күреп тә була торган түгел, ди. Ачкычын тыгып караган икән, таман гына булып чыккан. Шуннан борып җибәргән, ди, малай ачкычны...

Хәзер инде безгә аның, йозакны ачып, сандык капкачын күтәргәнен генә көтәргә кала. Аннары бу серле сандыкта нинди-нинди кыйммәтле, асыл әйберләр барлыгын без дә күрербез.

Йә, сабыр итик...



ЭЧТӘЛЕК

Тәрҗемәчедән . . . 3
Кызыл калфак . . . 7
Көлгенә 11
Буран патша 19
Чәнтикәй 22
Йокыга талган гүзәл . 29
Тукрансакал 33
Балыкчы һәм аның хатыны 38
Кар кызы 48
Тере суы 58
Бәллүр шар 66
Көтүче малай . . . 69
Крестьян белән шайтан 70
Унике туган 71
Урман иялəре 78
Һәнзил белән Гәрител . 84
Батыр тегүче . . . 92
Коштапкан 102
Алты ялчы 105
Күңелле музыкантлар . 113
Куян белән керпе . . 117
Мәче белән тычкан . . 120
Бүре һәм җиде кәҗә бәтие 123
Ак елан 127
Алтын кош 132
Җиде карга 141
Алтын каз 144
Өч ялчы 149
Салам, күмер һәм ногыт борчагы 153
Боткалы чүлмәк . . 154
Унике ялкау 155
Зирәк Һанс 159
Әкият-табышмак . . 163
Гомер озынлыгы турында 164
Әкәмәтләр илендәге гаҗәеп хәлләр 166
Мең дә бер ялган . . 167
Алтын ачкыч 168

Якоб Гримм, Вильгельм Гримм

БРЕМЕНСКИЕ МУЗЫКАНТЫ

(на татарском языке)

Рецензенты Р. Хафизова. Редакторлары Ф. Зыятдинова, Р. Шириязданов. Художнигы В. Малякин. Художество редакторы Г. Трифонов. Техник редакторы А. Газиззянова. Корректорлары Р. И. Расулова, Л. Ә. Нәҗмиева. ИБ № 2607. Наборга бирелде 30.06.82. Басарга кул куелды 5.11.82. Формат 84×108$^1/_{32}$. Типография кәгазе № 1. Гарнитура школьная. Печать высокая. Учет.-изд. табагы 10,0. Якынча басма табагы 8,8. Усл. кр. отт. 9,2. Заказ У-432. Тираж 30 000. Бәясе 35 тиен. Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19. ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең К. Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.

35 тиен